Ренат Харис

# Сандугачлар тынган вакыт

Шигырьләр, поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Х33

**Харисов, Р.М.**

Сандугачлар тынган вакыт : шигырьләр, поэмалар / Ренат Харис. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 527 б.

ISBN 978-5-298-02045-9

Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисның бу китабына, нигездә, соңгы елларда язылган фәлсәфи рухтагы шигырьләре, сонетлары, шигъри тәрҗемәләре тупланган.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02045-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Харисов Р.М., 2011

# СӘГАТЬ БОРГАНДА

## САЙРАУ ВАКЫТЫ

Төн. Сайрап җибәрде каен.
Җавап сайрады нарат.
Йөрәк аша дулкын үтте:
син минем кебек ярат!

Сайрауга кушылды юкә.
Тал өстәлде бераздан...
Йөрәк аша өннәр кичте:
син минем кебек назлан.

Өстә сайрау, аста сайрау,
уңда, сулда, һәркайда...
Йолдызлар чут-чутлашалар,
көмеш моң ага Айдан...

Сайрый урман... Сайрый алан...
Һава сайрый... Сайрый төн...
Сайрый йөрәк... Бу мизгелдә
Мин һәм Сөю – бербөтен!

Бөтен нәрсәдән өстен мин,
курыкмыйм бернидән дә –
көбә итеп йөрәгемә
җырлы төнне кигәндә...

*24 май, 2010*

## КЫРЫК БЕРЛӘР

1

Сугыш башлануга ярты секунд...
Самолёттан кубып, бомбалар
әле җиргә төшеп өлгермәгән...
Әле күктә утлы тонналар...

Аста әле җәннәт тынычлыгы,
офык караңгысы аллана...
Ә бомбалар оча безгә таба,
кире бора алмый Алла да...

2

Сугыш башлануга җиде секунд...
Моны әле беркем сизенми...
Бу – Вакытның кешегә карата
хыянәтчел тыныч мизгеле...

Була кайчак – дөнья тынып кала,
кайтавазлар кайтмый әйләнеп...
Хыянәтчел тынлык тудырадыр
кеше цунамиен – хәйләне...

3

Сугыш башлануга җиде минут...
Җиргә тиеп шартлый тимерләр...
Һәм илаһи булып туасы таң
Иблис күзе кебек тилерә...

Чык суында битен юган Җиргә
Һабил канына тиң кан тама...
Кояш бәйрәм итәсе урында
утлы сөрем итә тантана.

4

Сугыш башлануга җиде сәгать...
Охот диңгезеннән Балтыйкка
хәтле арадагы имән ирләр
әйләнәләр җанлы мылтыкка...

Ә Дәҗҗалның төпсез тамагына
эшелоннар ага торалар...
Яңа әти буласы егетләр
итчапкычка кереп турала...

5

Сугыш башлануга җиде тәүлек...
Җан төшенә инде чынлыкны...
Сабый ләкин белми ятимлеген,
тол әлегә белми толлыгын.

6

Сугыш башлануга җиде атна...
Кара кәгазьләрнең өере
шәһәр, авылларга каурый коя...
Бугазда – үч, нәфрәт төере...

7

Сугыш башлануга җиде айлар...
Ил исенә килә, туплана.
Сары балчыккача туфрак ашап
килгән Дәҗҗал тала, туктала...

8

Без шул секунд, минут һәм айларда
имеп туялмаган сөт аша
яу кырында булган этиләрнең
кан юлына барып тоташкан.

Кырык берләр бит без! Кырык берләр!
Без чирканчык алдык дәһшәттә...
Бернигә дә аптырамау хисе
безне Җирдә горур яшәтә!

9

Сугыш башлануга тиздән җитмеш...
Яу эзләре әкрен суына.
«Кырык беренче ел» дигән өч сүз –
утлы мөһер безнең буынга.

*7 апрель, 2010*

## САНДУГАЧЛАР ТЫНГАН ВАКЫТ

Сандугачлар сайрау чоры.
Җирдә җәннәт урнаша.
Хис белдерә җан иясе
бер-беренә җыр аша.
Сандугач сайравы тына...
Сайравының дәвамын
өзгәләнеп эзли күңел,
әҗәлләрдән дәваны
эзләгәндәй бәргәләнә...
Күк караңгы. Җир тыныч.
Сандугачлар тынган чакта
туадыр кебек кылыч,
туадыр кебек автомат,
туадыр кебек киллер...
Һәм йөрәктә бер шом туа:
нинди, нинди көн килер?
Шомлы мизгел үтеп китә...
Килә чорның яңасы –
дөньяда да, күңелдә дә
сандугач тантанасы!
Җанга ага илаһи моң,
өметкә керә чаткы...
Ләкин кичә белү кирәк
сандугач тынган чакны...

*1 апрель, 2010*

## УЯТСА ИРТӘЛӘР

Уятса иркәләп
кояшлы иртәләр,
аңда да, алда да
юыла киртәләр,
һәм атлап китәсең
тап-такыр юлдан син –
һәм матур, һәм батыр,
һәм дәртле, елдам син!

Уянсаң караңгы
бүлмәдә каранып,
ак уйлар, хыяллар
китәләр каралып,
атлаган аягың
югалта маягын...
Һәм язмыш тоттыра
сукырлар таягы...

Уят син елмаеп:
– Кояшым! Аем! – дип, –
сөюем көчәя
һәр мизгел саен, – дип,
дөрләгән учактай
ал да син кочаклап...
тормышны җәннәткә
әйләндер шулчакта!

*20 март, 2010*

## СИСКӘНӘСЕ КИЛӘ

Тыңлый-тыңлый гел файдалы,
гел акыллы, дөрес сүз,
йөрәк шундый зирәкләнә –
хәтта яшәү күңелсез.

Юләрлек эшлисе килә,
килә бер шаккатасы,
һәркемгә ачып бирәсе
акыллылык хатасын,

акырасы, бакырасы
дөньяны сискәндереп...
Ләкин һәрбер күзәнәктә
зирәклек чире тере...

*12 сентябрь, 2009*

## БИРЕШЕРГӘ ЯРАМЫЙ

Яз кояшы һәм кыш җиле...
Кар тузгый... Күз камаша...
Уяулыкны оныттыра
мондый сәер тамаша.

Күңел юеш чебеш кебек
шуып чыга тунынннан...
Җирдә әле тузганак юк –
анда кар һәм туң гына!

Күңел – шәрә... Дөнья – суык...
Тормыш – аклы-каралы...
Ләкин Җирдә – Яз кояшы!
Бирешергә ярамый!

Юк, ярамый бирешергә
куанып та, өркеп тә...
Җан чебеше көрткә менсә,
әверелә бөркеткә...

*17 март, 2010*

## ФРОНТОВИКЛАР

Фронтовиклар кими елдан елга...
Кадерләре ләкин артамы?
Аһ, какшаган гомер арканы
ил нужасын тартып барган юлда...

Елдан елга фронтовиклар кими...
Боегышып кала толлары.
Аларның да инде тыннары
яулыклары читенә дә тими...

Елдан елга кими фронтовиклар...
Картаялар ул һәм кызлары...
Коръән ашы ризык-тозлары...

Табыннарда – артык урындыклар...

*22 март, 2010*

## ВЕТЕРАН ДӘФТӘРЛӘР

Сугыштан кайткан дәфтәрләр...
Язулар инде тоnык...
Хәрефләрнеҗ төсен алган
тыныч вакытлар дымы.

Дары исе һәм кан исе,
тир исе, төтен исе
дәфтәрләрдән аңкымыйлар –
җилләнгән бөтенесе...

Солдат дәфтәрләре җанлы:
аларның һәрберсенә,
күкрәк кесәсендә йөреп,
йөрәк тибеше сеңгән...

Һәрбер хәреф – сүзгә түгел –
урнашкан патронташка,
һәр патронташ, тасма булып,
пулемётка тоташкан.

Дәфтәрләр пулемётының
тарттым кайнар тәтесен –
яла тарих язучылар
хаклык утын татысын!

Ветеран дәфтәрләр – җанлы:
аларның һәрберсенә,
күкрәк кесәсендә йөреп,
йөрәк тибеше сеңгән...

*20 март, 2010*

## ҖИҢҮ БАЙРАГЫ

1

Ватан өчен утка кергән,
безгә җиңү яулап биргән
солдатларның исемнәре
төшми телләрдән,
төшми телләрдән...

Алар безнең арабызда!
Исәннәргә рәхмәт һәм дан!
Исәннәргә рәхмәт һәм дан!
Исәннәргә рәхмәт һәм дан
бүгенге көн исеменнән!

2

Җилфердә, Җиңү Байрагы,
язгы җилләрдә.
Син тынычлык урнаштырдың
барлык илләргә.

Хатын-кыз тавышы:

Минем җаным әле һаман
газап кичерә,
күз яшьләрем әле һаман
җанны пешерә.
Минем ирем башын салды
сугыш кырында...

Кайтмый калганнар, кайтыгыз
хәтер җырына!
Кайтмый калганнар, кайтыгыз
хәтер җырына!

Фронтовиклар:

Сугыш дәһшәте хәтергә
салды җуелмас яра;
төшемдә безнең батальон
атакаларга бара.

Өстән бомба ява, аста мина шартлый,
алда пулемёт чәчрәтә үлем уты.
Адымлап-адымлап алга без барабыз,
ачы төтен һәм кара сөрем йотып.

Җиңү җырын Җир йөзенә
кан белән яза-яза,
илебезне, планетабызны
коллыктан иттек азат.

Дуэт:

Алгы сызыктан ерак булсак та,
кара тир түгеп, көрәшкә кердек –
данлы Җиңүгә без корал койдык,
киемнәр тектек, азык җиткердек.

Бергә:

Түгелгән кан белән агылган тир
берләштеләр утлы сугыш кырында.
Бөек Җиңүне данлыйбыз без
хәтер җырында!

3

Күңел тыныч түгел әле һаман –
сугыш уты һаман көйрәп яна,
очкыннары барып төшкән җирдә
дәһшәтле янгын уяна,
Җир кабат канга буяла...
Якты өметне каралап,
йөрәктә каргыш ярала:

Сугыш уе йөрткән башны
сугып ватсын яшен ташы!
Нәләт, нәләт, нәләт!

Илләргә басып керүче
татысын кешелек үчен!
Нәләт, нәләт, нәләт!

Бомба тоткан террорчының
кулында кан кайнап чыксын!
Нәләт, нәләт, нәләт!

4

Ватан өчен газиз җанын биргән,
илебезне сүнмәс данга төргән
солдатларның каберләре
төрле илләрдә,
төрле җирләрдә,
төрле илләрдә,
төрле җирләрдә.

Алар бүген бездән ерак!
Һәр кабердән бер уч туфрак,
һәр кабердән бер уч туфрак,
һәр кабердән бер уч туфрак
тыныч кырлар тамырына,
горур җырлар тамырына!

5

Җилфердә, Җиңү Байрагы,
горурлык булып җилфердә!

Җилфердә, Җиңү Байрагы,
ышаныч булып җилфердә!

Җилфердә, Җиңү Байрагы,
истәлек булып җилфердә!

Җилфердә, Җиңү Байрагы,
кисәтү булып җилфердә!
Җилфердә,
җилфердә,
җилфердә,
җилфердә,
җилфердә!

*24 ноябрь, 2009*

## СЕЗГӘ КҮЧСЕН ҖИҢҮ ҖЫРЫ

Мин – сугышта кан койган буынның
хәтер дәвамчысы, улы.
Минем адымнарым алга илтә
әтиләрнең Җиңү юлын.

Кызым, улым, оныкларым минем,
тотыныгыз кулларыма –
сезгә күчсен бөек Җиңү җыры
минем күңел кылларымнан.

*9 май, 2005*

## САГЫНЫЧ

Көннәремдә – төннәр чакыруы,
ә төннәрем минем оҗмахлы...

Таң беленгән саен шуңа җаным
синең тарафларга очмакчы.
Хыялланып яшәү – матур яшәү!
Матурлыгы аның өметтә...
Ә өметне Вакыт дулкыннары,
йөрәгеңә бәреп, ком итә.
Ә яңа таң туа һәм яңа көн...
Алар үтә... Алда тагын кич...
Хыял инде күптән өмет түгел,
өмет инде дымсу сагыныч...

*9 март, 2010*

## ТИЛЕ БЕЗ...

Җайлы-майлы, мин-минлекле
кешеләр калка бүген...
Чөйгән борнына карасаң,
төшеп китәр бүрегең.

Эш дилбегәсенә алар
ябышалар да килеп,
тормыш алпан-тилпән китә –
әйтерсең тиле-миле.

Абынмыйлар, таелмыйлар,
егылмыйлар – күрегез!..
Ә без башка кешеләрне
акыллы дип йөрибез...

Тиле без...

*7 ноябрь, 2000, 18 сентябрь, 2009*

## БЕРСЕ КАЛСЫН ИДЕ

Үзеңнән соң йөз табышмак
калдыра алсаң иде!
Шуларны табу теләген
кемгәдер салсаң иде!

Туксан тугызын тапсыннар,
ә берсе калсын иде,
җаныма кагылган кеше
бераз уйлансын иде...

*31 декабрь, 2009*

## ӘНИЕМ ИСКӘ ТӨШӘ

Үкенечкә әверелде, әни,
сиңа кайтмый торган күп чаклар...
Бермәл камыр баскан куллар белән
алган идең мине кочаклап.

Сен Ив Лоран теккән костюмымда
калган иде бармак эзләрең...
Шуны күргәч, ак он төсле булып,
йөзең-битең кинәт үзгәрде...

Затлы костюмымны мичкә терәп
киптердек тә удык камырны.
Эз калмагач, зәңгәр күзләреңнән
яуган иде шатлык яңгыры...

Ул костюмым исән. Аркасында
бер тап та юк – кипкән, коелган...
Ә шулай да, аны кигән саен,
син кочасың кебек тоела...

*17 апрель, 2010*

## ДӨНЬЯСЫНА ЮК ҮПКӘ!

*Рафаэль Фәизовка*
Еладык та,
көлдек тә,
баедык та,
бөлдек тә...
Күңелебез ник көр димсез?
Дөньясына юк үпкә!..

Без эчтек тә,
кочтык та,
сөйрәлдек тә,
очтык та...
Күңелебез ник хөр димсез?
Дөньясына үч юкка!..

Аздык та без,
туздык та,
төзәттек тә,
боздык та...
Күңелебез ник сер димсез?
Дөньялыкта кызыкка!..

*7 ноябрь, 2009*

## ҖИҢЕЛМӘС КУӘТ

Болганып куя Замана,
яшенле болыт сыман...
Күңел офыкларын каплый
эчпошыргыч күк томан.
Адым атлыйсы да килми,
тукталасы да һич тә...
Ләкин сизелер-сизелмәс
кызышу туа эчтә,
һәм ул дым тарта башлаган
җан учагын көйрәтә...
Ниндидер җиңелмәс куәт
бирешмәскә өйрәтә...
Һәм бирешеп тә тормыйбыз –
яшибез дә яшибез!
Хәтта кайчакта үзебез
яшен булып яшьнибез...

*9 декабрь, 2009*

## КӨЗЕН АГАЧ УТЫРТАСЫҢ

Көзен агач утыртасың –
коры бер чыбык-чабык.
Иртәгәсен яз көтәсең,
килер дип йөгреп-чабып.

Ышанасы килә аның
җиргә берегүенә,
күрәсе килә агачны
яшел бөре киемдә.

Гасабиланып көтәсең
һәр эшеңнең җимешен...
Гомер кыска... Ашыгырга
мәҗбүр ителәә кеше...

Ашыгасың, ашыгасың,
йөрәк тибешен узып...
Юл кыска, офыклар чиксез!
Шуңа да яшәү кызык.

*8 ноябрь, 2009*

## ҮЛЕ НАМУС ТЕРЕ ТӘНДӘ

Эзе калсын керсез намусыңның...
*Муса Җәлил*

Җанда була ут та алмый,
кан да юмый торган сызык.
Кеше булган бер Кеше дә
ул сызыкны таптап узмый.

Намус диеп атала ул!
Оялу һәм Сафлык көче
уйган аны җаныбызга
әрвах Кеше булсын өчен.

Намус керсез – без дә керсез,
намус тере – без дә тере.
Бер тапкыр адашса, Намус
кайтмый инде җанга кире.

Ләкин очрый шундый нәрсә:
үле Намус тере тәндә...
Уйлыйм шулчак: булыр микән
оятыннан үлгән бәндә?!

Моңа хөкем ителгәннәр
бар ул, бар ул – үзем беләм...
Намус сызыгы аларда
сызылган тик төкрек белән.

Җанда була шундый сызык –
саксыз кагылганнан сызлый.
Кеше булган бер Кеше дә
ул сызыкны таптап узмый.

*21 август, 2009*

## ҖӘЛИЛ КАРДӘШЛӘРЕ

Исемнәрегез – горурлык,
Муса Җәлил, җәлилчеләр!
Җир шарында сез бит безнең
иң вәкаләтле илчеләр.

Континентлар буйлап йөреп,
күтәрәсез татар данын!
Җәлил кардәшләре, дисәк,
безне бөтен дөнья таный.

Казанның биек түрендә,
дөньякүләм бер көч белән,
батырлык йөрәге тибә
бакыр тәнегез эчендә!

Тын калыйк та тыңлап алыйк
йөрәгегезнең тибешен...
Сезнең алда башын ия
халкын сөйгән һәрбер кеше!

*16 август, 2009*

## ЯНӘ БЕР КӨНЕМ ЯНА

Кояш сайрый!..
Аның җыры
иске булса да яңа...
Рәхәт...
Чү! Чү!.. Искәртмичә
янә бер көнем яна...

Алсу граммофон-гөлчәчәк...
Күбәләк кунган аңа...
Гөл түтәленә су сибәм...
Ә бит бер көнем яна.

Сискәндергеч матурлыктан
ике тамчы хис тама –
соклану белән уфтану:
тагын бер көнем яна...

*3 август, 2009*

## ЕЛЛАРНЫ САНАМЫЙЧА

Минутларны саный-саный
эшләүләр, авырсынып,
кайнар май булып яндырды
күңелнең кавырсынын.

Сәгатьләрне һәм көннәрне
уздырырга дип тизрәк
Аллага ялвармый калган
кеше дә Җирдә сирәк.

Юкса гомер дулкыннарын
куу гуждай диңгезгә
бәхет китермәячәге

билгеле һәммәбезгә...

Бары синең белән генә
җан рәхәтләнеп оча –
канатлар канасалар да,
елларны санамыйча!

*19 июнь, 2009*

## КЫЗЫКМАГЫЗ

Кызыкмагыз сез кешеләр бәхетенә –
алар өлгерлек күрсәткән вакытында:

әйтик, фәрештәләр «Амин!» дигән чакта
кирәкле сүз әйткән бер түрәне яклап;

уйнатканда зур отышлы лотерея,
Иблис тамга салганына булган ия;

тырышлыгының кулларын бик нык сузып,
бәлки, тотып өлгергәндер бер мэр кызын;

йә булмаса уздыргандыр да һәммәсен,
ялагандыр бер олигарх тәлинкәсен;

ахыр чиктә һич тә куркып тормагандыр,
бәхетне ул оста итеп урлагандыр...

Яхшы чакта уйла үзең: шулвакытта
ята идеңме йомшак мамык ястыкта,

әллә инде, аны-моны белештерми,
берәр җирдә чокындыңмы өйгә керми?

Кызыкмагыз сез кешеләр бәхетенә –
елгыр була белү кирәк вакытында!

## ТАМЫР ҺӘМ ЧӘЧӘК

Җиңел холыклы чәчәкләр!
Туймас нәфес ияләре!
Сөяркәләр ничаклы күп,
шуның чаклы бәяләре.
Юк аларны битәрләүче,
син бит затлы тамырдан, дип,
алай итмә, болай итмә –
җәмгыятьтә таныйрлар, дип,
нәфесеңне, дип, туймас җан,
үз тамырыңа карап суз...
Ә чәчәккә адәм язган
барлык кануннар яраксыз...
Тамыр эшли! Ул сут булып
барлык күзәнәккә тула...

Тамыр ләкин чәчәк атмый,
ә чәчәкләр җимеш була.

*25 май, 2009*

* * *

Нинди йолдыз булсам да мин
үз халкымсыз балкымам...
Үзәгемдәге ялкыным
халкымнан һәм халкыма!

*25 май, 2009*

## КЫТАЙ ТЕЛЕ

Латиннан син читләшәсең,
рус теленнән куркасың...
Гарәп-фарсы да күрсәтми
хакыйкатьнең уртасын.
Ә хакыйкатьнең уртасы
күз караңнан да тирән...
...Кыскасы, батып үлмәскә,
син кытай телен өйрән...

*21 май, 2009*

## ТӨПЧЕК

Күптән килгән гадәт бүрәнәгә
тезгән иртән яшен-картын да...
Җылытырга ләкин кояшы юк –
кояш һаман болыт артында.

Җил тузгыткан болытларга карап,
Җир турында алар гәп кора.
Иренгә үк янып җиткән төпчек
төтен аша бераз яктыра...

*21 май, 2009*

## САНДУГАЧ КУНЫП КЫНА

Куакның килбәтсезе дә
сирәк булса да була.
Кәкре-бөкре ботакларга
кайчак сандугач куна,
сайрый дөньядагы барлык
оркестрдан уздырып,
барлыгыңны оныттырып –
өздереп һәм кыздырып...
Аңсызлана күз карашы...
Менә сандугач тына...
Килбәтләнми ямьсез куак
сандугач кунып кына...

*20–21 май, 2009*

## ГАИЛӘСЕНӘ ҖИҺАННЫҢ

Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?
*Габдулла Тукай*

Синме ул Адәм ясалган

балчыктан кубып төшеп,
гаиләсенә җиһанның
ят булып килгән кеше?
Безгә таба юл ярганда
йолдызлар арасыннан,
кагылгалап алдың мәллә
Киек Каз ярасына,
әллә бик якын үттеңме
тапларына кояшның? –
Галәми кайнар кайгыны
йөрәгеңә койгансың...
Кемнәр бар бу гаиләдә?
Йолдызлар, метеорлар,
берьюлы җәннәт һәм тәмуг
булган бу Җир шары бар...
Әллә җиһан борчылырлык
язмыш көтәме безне,
әллә Аллаһ боерыгын
төгәл үтәмибезме?
Бәлки, син бу сорауларның
җавабын белгәнсеңдер,
метеордай янып, янә
галәмгә сеңгәнсеңдер.
Тукай, син – җавапсыз сорау,
илаһи гамәл ише...
Гаиләсендә җиһанның
ят булмый мондый кеше!

*26 апрель, 2009*

## ТУКАЙ – ҮСМЕР АКСАКАЛ

Татар Тукайга сыена,
язмышы юл көткән саен.
Һәркем белән сөйләшергә
Тукай таба рәтен-җаен.
Татарның һәр соравына
үз Тукае җавап бирә.
Һәр татарның йөрәгендә
үз Тукае шуңа күрә.
Ләкин шатлык чиктән ашса,
татар шагыйрен оныта.
Тукайны оныткан саен,
татарны өянәк тота...
Минем дә бар үз Тукаем!
Күңелемдә яши аман
өч бөек нур эретмәсе:
шагыйрь,
фәрештә,
юламан.
Өчесеннән дә һәрвакыт
киңәш-табышлар аламын –
чал башыма акыл өсти
минем үсмер аксакалым.

## ТУКАЙ «ФАУСТ»НЫ ТЫҢЛАГАЧ

«...Доктор Фауст җанын җенгә саткан
гүзәл мизгел күрү хакына...

Ә мин җанны бушлай бирер идем
бәхет китерергә халкыма.

Ә татарга андый җен кайда соң?
Ник күренми? Нигә сиздерми?
Халкыбызның нинди адымнары,
нинди эше җенне биздерде?..»

Шундый уйлар белән операдан
чыкты Тукай ап-ак Казанга...
Ә йөрәген кыйнап тырный иде,
гер(ы)быннан төшеп, сазаган...

*25 ноябрь, 2010*

## ИКЕ ОБЕЛИСК

Тукай каберенең обелискы –
Пушкин каберенең өлеше!
Ничек шулай килеп чыккан әле?!
Кемнән сорыйк, кайдан белешик?

Каберләрнең архитекторларын
бер үк кеше диеп белерсең...
Мондый охшашлыклар сирәк була...
Башка килә уйның төрлесе...

Таркау уйлар тупланган арада,
колакларда кинәт шаулый чаң:
«Даһиларның хәтта каберләре
бер-берсеннән үрнәк алучан!»

*30 март, 2010*

## ШӘРЫК КЛУБЫ

Әй, бөек Шәрык клубы –
иң уңдырышлы түтәл!
Синең яныңнан һәр татар
сынын турайтып үтә.
Мәрткә киткән рухыбызны
чыбык белән суктырдың,
коргаксыган тамырыңа
иң шифалы сут бирдең.
Сәләтлене – талантлыга,
талантлыны даһига
күтәрдең син!
Һәрбер кичәң
булды олы вакыйга.
Әй, бөек Шәрык клубы!
Тукай яшәгән чорда
опера, балет та булдың,
симфоник оркестр да...
Сине госпиталь иттеләр,
җыр-моңнан тартып алып.
Дару исе һәм кан исе
ташыңа сеңеп калды.
Ә яралылар яңадан
кайзерга каршы китте.

Ә син сафка басалмадың –
татар түтәле кипте.
Ә рухың калыкты, балкый
тук башактай, тук Айдай,
чөнки тамырыбыз Кари,
Фатих, Сәйдәш, Тукайда!

* * *

Сиңа хисләрнең җылысы,
сиңа сүзнең олысы:
син кояш булып көләсең,
яңгыр булып елыйсың,

син туфрак кебек эшлисең,
су кебек сугарасың,
беркетәсең кояш һәм Җир,
галәм һәм җан арасын.

Елларның дүрт фасылы да
яши синең йөрәктә,
һәм чиратка тезелешеп
чыга алар кирәктә.

Язлар безне чәчәк итә,
җәйдә җимешләнәбез,
көзен, кышын чын философ
җисемгә әйләнәбез...

Елдан-елга шулай була
син янәшә чагында...
Бу... Бу... – шигырь сөйләү түгел!
Бу... Мин шулай табынам!

*1 апрель, 2010*

## СИММЕТРИЯ

Симметриядә – күңелсез!..
Ялыктыра!.. Алҗыта!..
Симметрия яшәү яменең
бөтен мәгънәсен йота.

Симметриядә тартылу юк,
бары тик – этәрелеш!
Төп-төгәлдә мәхәббәт юк –
менә кайда бөтен эш!

Симметрия үзе дә бит –
әйтсәм әйтим дөресен –
һәрнәрсәнең капма-каршы
төгәл ише, киресе!

*24 февраль, 2009*

## ҮЗЕБЕЗГӘ КИРӘК ДОГАЛАР

Җирдән кичкәннәргә кирәк түгел,
үзебезгә кирәк догалар,

үзебезгә чөнки яман уйлар
яман шешләр булып йогалар.

Битарафлык белән чирлибез без...
Аңда нигә көрәш калыкмый?!
Кичкәннәрдән калган хаталарны
каргый-каргый беттек ялыгып.

Черибез бит, эчтән таркалабыз!..
Хәлебезне нигә сизмибез?
Сизгерлекне әллә каплаганмы
ваемсызлык дигән симезлек?

Дога белән генә булыр микән?!
Кичкәннәргә таба барабыз?..
Бер догалык кына калды микән
алар белән безнең арабыз?..

*8 февраль, 2009*

## БЕР ГАЗӘЛ

Дуслар! Миндәге тилелек батман-батман...
Нәкъ миндәге батманнарга дөнья баткан.

Шуңа, ахры, бара тормыш алпан-тилпән
йә ул якка, йә бу якка – җөптән такка...

Ә сез, дуслар, барыгыз да шундый уңган,
шундый дөрес һәм акыллы бөтен яктан.

Ничек алып бу дөньяны сезгә салыйм?
Кем өйрәтә, кем күрсәтә, кем аңлата?

Ә мин яшим тилелекне сүгә-сүгә...
Ник сүгәмен – аңлый алмыйм – башым каткан...

*20 гыйнвар, 2009*

## РОССИЯ

Россия, ты кормящая волчица!
*Евгений Семичев*

1

Россия, син – имезүче аю!
Кем ул имә сине йотлыгып?
Кем ул белми нәфсе бизмәнендә
бернинди дә чикләр юклыкны?!

Кем ул? Кем ул? Һәр суырган саен
түлең кими! Ходай сакласын!..
Әллә үзең инде, белештерми,
үз тәпиең имеп ятасың?..

2

Россия, син – имезүче бүре!
Көчекләрең инде җитлекте –
һәрберсенең аерым биләмәсе...

Алар сөйми гомум читлекне.

Алмагачтан алма ерак төшми –
алар горур, кыю йөрәкле.
Ач-ялангач түгел... Ачыксалар,
таба ала алар кирәкне.

3

Россия, син – имезүче ана!
Җылы, җайлы синең куеның...
Шуклыкларны кичерә белгәнгә,
рәхәт кабат сиңа сыену!
Яратасың, шикләнәсең дә син...
Һәм әйткәндә чынын-дөресен –
аерылганны ашый торган аю,
бүленгәнне буар бүре син!

*24 ноябрь, 2008*

## СИН БИТ БУ!

Тышыңда синең кыюлык,
эчеңә курку поскан...
Ә шулай да сер бирмисең –
син бит бу, Татарстан.

Бавырыңа боз сауса да,
елмаерга син оста...
Күзләреңнең нуры дымлы –
син бит бу, Татарстан.

Кем генә юк җан сутыңны
тустаган белән соскан?!
Башың бар, ник саный алмый?
Син бит бу, Татарстан!

Алтын авызлык чәйнисең,
муеныңны камыт кыскан...
Кая барганың беләмсең?
Син бит бу, Татарстан...

Тормышны шулай коргансың –
дошманың көнли дустан.
Сәламәт кенә кала күр –
син бит бу, Татарстан!

*5 апрель, 2008*

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

*Г.Сабирҗановка*

Сүзлек – алфавит тәртибендәге Галәм.
*Вольтер*

Яралган, бар булган һәрнәрсә
акылга сүз булып берегә.
Сүз генә бу фани дөньяда
бирешми януга, черүгә.

Бетәләр диңгезләр, халыклар,
үчәләр* тау-ташлар, далалар,
ис-төсләр, тәм-томнар... Ә алар
мәңгегә сүзләрдә калалар.

«Акылның ни даһи нәрсәсе?»
дисәләр, сүзлекне атармын!
Ниһаять, алфавит тәртибен
тарихың үз итте, татарым!

Егерме беренче гасырда
татарның иң бөек җиңүе –
сүзлеккә салынган тарихы!
Һәм безгә юк хәзер чигенү!

## «СӘЛӘТ»

Без – татарның теле, теше,
кулы, колагы, күзе.
Безнең аяк белән милләт
салачак яңа эзен.

Эзебездә яңа гөлләр
чәчәк атачак күкрәп.
Безгә бары кояштай сүз,
яңгыр һәм туфрак кирәк.

Туфрагы бар! Яңгыр булыр –
дымлы җилләр исәсе!..
Үзебез кояш булырбыз,
әгәр дә «Бул!» дисәгез.

*23 июль, 2008*

## НӘРСӘ ЙОТТЫМ?

Яратам яңгыр явуны!!!
Йөрәкнең сәбәпсез януын
сүндерә ул,
рәхәтлек булып, тәнгә сеңә-сеңә...
Фани ыгы-зыгының һәммәсенә
төкерәмен яңгыр яуган бөек биеклектән –
күңелдәге көеп кипкән,
өмет алмагачымның тамырлары,
тән күзәнәкләрен аралый-аралый,
янә үсә,
җанны кымырҗытып...

Мин
бер тамчы
нинди нәрсә йоттым?..

*20 август, 2008*

## ИЮЛЬ

Иртәнге чыклы үләндә
чыланып кердем әле –

яңгыр юган карлыганны
чемченеп йөрдем әле.

Кайнар яланаягыңны
алмый торсаң чак кына,
күренеп һава куера,
күтәрелә – чат томан!

Кояшта кипшенеп, чыклар
сәйләнгә әйләнгәннәр;
үрмәкүчләр пәрәвездәй
шәльяулык бәйләгәннәр.

Июль! Иртә! Яңгырдан соң!
Урман аланы! Ызба!
Рәхәт! Госел алган дөнья
тирәбез-яныбызда.

*22 июль, 2008*

## МИН

*(Триптих)*

### 1. Харис

Җәннәттән сөрелгәнгә хәтле Иблис шушы исемне йөрткән. Аллаһ, Адәмне ясар өчен, Җәбраил, Микаил, Исрафил фәрештәләргә җиде төрле туфрак алып кайтырга куша, ләкин тегеләр бу эшне башкарып чыга алмыйлар. Ә Харис фәрештә Аллаһка җиде төрле туфрак алып кайта. Шул туфраклардан Аллаһы Тәгалә Адәмне яралта. Димәк, Адәмнең һәм кешелекнең бар булуында Харис фәрештәнең дә өлеше зур.

Мин җәннәттән әле куылмаган...
Мин Аллаһка әле кирәкле –
игелекләр кылам: нур таратам,
йолдызлыклар сибәм, сирәклим.

Адәм әле – җиде аеры туфрак...
Җыелмаган Аллаһ учына...
Өч фәрештә үти алмаганны
мин ул җыйдым канат очыма

һәм кайтарып бирдем Аллаһыга
җиде туфрак җиде катламнан...
Шуннан бирле һәр кеше җанында
канат эзем минем саклана...

Минме соң ул Адәм каршысында
баш иярдә тиеш фәрештә?!
Буйсынмадым илаһи карарга,
чакыртылып алгач гарешкә...

Һәм сөрелдем... Яңа ат тагылды...
Һәр язмышка Аллаһ юл ача!..
Һәм җәннәттән хаксыз сөрелүче
һәр фәрештә Иблис булачак.

*21 июль, 2008*

### 2. Мәгъсум*

Исемнәргә яшеренгән теләк

җаныбызны тора сугарып.
Аңыбызга беркетеп, язмышны
омтылдыра алга, югары.

Ыргылабыз һәм барабыз дулап,
карамыйбыз уңы-сулына...
Уйламыйбыз – күпчелек гөнаһлар
ыргып барган чакта кылына.

Тапсыз күңел дөньялыкта юктыр –
кояшта да әнә кара тап!..
Синең күңелең, әти, керсез иде
илгә, телгә, миңа карата...

Пәйгамбәрләр генә мәгъсум дигән
катгыйлыкка һич тә кимсенмим –
гөнаһ иясе дә таба ала
кешесенә лаек исемне!
Исемнәргә яшерелгән теләк
кайвакытта аша тормышка...
Мин дә менә исемемә лаек
җисем булмаклыкта тырышам...

3. Ренат

(Renatus*)

Инде мин дә артка борылып карыйм...
Үткән юл бар – заман өлеше.
Ә башыма Киек Каз Юлының
төште инде салкын көмеше.
Сүнгән йолдызларның көле төште...
Миллион еллар элек суынган...
Терелмәсләр, дидем, терелделәр
хәтеремнең терек суында!..
Алар белән җаным, әй, сөйләште
аңлашылмый торган бер телдә...
Кайдан миндә йолдыз телен белү?
Әйтә алмас Җирдә беркем дә!..
Нигә миңа андый бөек ачкыч,
мәңгелекнең ачкач ишеген,
үзең кералмагач,
күралмагач
аң-зиһеннең ерак бишеген?
Нигә миңа андый бөек көймә –
дәверләрне урап кайтырлык –
үлемсезлек диңгезенә кертеп
үтергәчтен мине батырып?!
Ә шулай да кеше булу – бәхет!
Мин – йолдызның җанлы күмере –
кабат кайтып яшим...
Әйләнештә
хәтеремнең чиксез гомере!

## ЭШ БАШКАЧА

Бәлки, күңелем дә кайтыр
очрашкачтын тагы бер...

Бәлки, һуш алырлык яңа
әллә ниләр табылыр...
Ә җәй якынлаша бара
аткан һәр чәчәк булып,
һәрбер ботакның очына
яшел сут булып тулып...
Сандугач сайравы булып
колакка керә инде
һәм йөрәкне ымсындыргыч
хисләргә төрә инде.
Күтеп яшәү авыр, диләр...
Моны без белмибезме?!
Ә эш башка – назын алдан
сиздерсә билгесезлек...

*10 май, 2008*

## АТЛАП БАРЫШЫМ

Ике сары лалә таҗлы булды...
Шомырт исе тәмам исертә...
Куанычны бүген акыл йөртми,
куанычны бүген хис йөртә.
Ап-ак болыт үтә баш өстеннән,
зәңгәр нурга иркен юл ачып...
Ә шулай да кайбер мизгелләрдә
мин – уйларым буйлап юллаучы.
Уйларым да бүген әллә нинди
алтын нурлар белән өртелгән...
Уйлы нурлар, кара үрне тишеп,
эти-әниемә төртелә...
Язның алтын кыллы оркестры
бөек Дирижёрга карышмый –
марш уйный! Шул маршка басып,
вакыт буйлап атлап барышым.

*6 май, 2008*

## АКЫЛ КЕРҮ

*Кәрим Харисовка*

Ашыктырып кына акыл кертеп булмый
үзеңә дә, хәтта сабый башына да.
Үз вакыты белән генә керә акыл
Яшәү дигән могҗизага гашыйк аңга.
Вакыт җитә... Һәм ул керә, һәм үзгәртә
тәртибеңне, карашыңны, юлларыңны...
Аргамак та, йөк аты да түгел Акыл!
Чыбыркылап әрәм итмә кулларыңны...

*1 май, 2008*

## ЫЧКЫНДЫРМЫЙМ

Үткәнемнән киләчәк көннәргә
барлык булганымны ташыганда,
төшеп кала яздым борылышта
рулен Заман тоткан машинадан...

Артка чапкан юлны күзем күргәч,
аяк тигәч ташлы ягасына,
кулларыма бар көчемне җыеп,
ябыштым мин Заман якасына.

Үзем тере чакта мин Заманны
ычкындырмыйм әле кулларымнан,
чөнки беләм: мин эзләгән бәхет
Заманга эз уйган юлларымда!

*1 май, 2008*

## РӘХӘТ ИРЕКСЕЗЛЕК

Ирексезлегемнән мәхрүм итмә –
башка тормыш миңа кирәкми,
тышау киеп, бәхет дөньясында
рәхәт кичерергә өйрәттең.

Кайчакларда мин тышаусыз калдым,
тезген тартуны да тоймадым.
Дүрт тарафым биш кыйбла булгач,
чиксез бушлык җанны кыйнады.

Мәхәббәтнең кысаннан да кысан
зиндан икәнлеген күрәмен...
Ә шулай да, бар ирекне ташлап,
шул зинданга барып керәм мин.

## КҮЗ НУРЛАРЫ ШИГЫРЬ ЯЗА

1

Күз нурларым күзең карасына
кайнар шигырь яза, сизәсеңме?
Ник телеңә аны төшермисең –
күрмисеңме, әллә түзәсеңме?!
Ә мин көтәм синең тавыш булып
кайтавазлы сүзем яңгыравын...
Һәм ишетмим – йә син телсез, хиссез,
йә булмаса бүген саңгырау мин...

2

Күз нурларың синең шигырь яза
күзләремнең комсыз карасына –
бармакларың тузанлы тәрәзнең
пыяласы буйлап бара сыман.
Эчке яктан торып укыйм шигырь –
якты керә һәрбер хәреф-эздән...
Җан-дөньяны якты тотар өчен
тузан сөртү кирәк хистән-сүздән...

*29–30 апрель, 2008*

## КЕМ КУШКАН?

Һәрнәрсәгә Аллаһ исем кушкан,

дөнья сыйсын диеп акылга...
Мин исемсез берәр җисем эзләп
йөрим Җирдә, күктә атылам.
Аллаһ белән тиңләшергә теләп
иләсләнеп йөрү!.. Аңлыймын...
Ә Аллаһка исемне кем кушкан?
Шуңа җавап таба алмыйм мин...

*29 апрель, 2008*

## ЯЗ ТОЙГЫСЫ

Умырзая җыеп кереп кенә
язны кертеп булмый өйләргә.
Яз кергәнне тоеп кына була –
мөмкин түгел аны сөйләргә.
Тойгыны да сөйләү җиңел түгел.
Язлы, назлыларын – бигрәк тә...
Кичә генә җиһан кием иде,
бүген җиһан үзе йөрәктә!..

*27 апрель, 2008*

* * *

Хисләреңә буйсынмыйча,
алар капкасына йозак
элеп кенә тынычланып
яшәп буламыни озак?!
Күңелдәге тынычлыкны
йөз мең төрле нәфес боза...
Хисләр үзләре акылга
куя монда хәтәр тозак.
Акыл кайчак бүре булып
тозакларны урап уза...
Шуны сизенгән чакларда
акыл горур, чөнки йөз ак.
Ә күп чакта акыл – сарык...

*15 апрель, 2008*

## ГОМЕР СӘГАТЬЛӘРДӘН ТОРМЫЙ

*И.Әхмәтҗанга*

Секундларыбыз йөрәкнең
тибешенә буйсынсыннар,
алар, еллар саны булып,
минутларга сыенсыннар.
Минутлар тезелешсеннәр,
алтмыш батыр булып, сафка
һәм бассыннар йөрәкләрне
саклый торган сакчыл сакка.
Гомер сәгатьләрдән тормый,
тормый атна, ай эшеннән,
хәтта еллардан да тормый,
тора йөрәк тибешеннән!
Анда – сөю, нәфрәт, сагыш,
сокланулар, үкенечләр
әверелә безне Кеше
иткән матур, батыр көчкә.

һәм, елларга буйсынмыйча,
яшик Җиргә аяк терәп –
безнең йөрәк тибешебез
татар акылына кирәк!

*15 апрель, 2008*

## ТЕЗ АСТЫ

*(Шаян әңгәмә)*

Яз кояшы агачларны
бөредән киендергән,
хатын-кызга нәкъ киресен
эшләү уй-дәрте кергән.
Алдымнан атлаган кыска
итәкле бер чибәрнең
тез астына күзләремне
Яз такты да җибәрде...

Мин:

Тез астында ике чокыр,
уртасында шома үр.
Күз карашым, ул үр буйлап
саклык белән генә йөр –
таелырсың да төшәрсең
шул чокыр упкынына,
һәм мине әйләндерерсең
нәфесең тоткынына.

Күз карашым:

Уйларыңны ешрак буйла,
яшеңне дә онытма.
Мине өскәрәк юнәлт син,
әйтик, кошка, болытка –
сиңа философ булырга
вакыт инде бик күптән,
тирәнлекне, матурлыкны
эзләргә кирәк күктән!

Мин:

Уем Җирне үтә чыга,
күкне ала колачлап...
Ләкин сине, күз карашым,
күзләрем ачык чакта
кая юнәлтергә беләм,
син инде түбәнсенмә –
тирәнлек тә, матурлык та
тез асты тирәсендә...

## СҮЗСЕЗ ШИГЫРЬ

Дымлы керфекләрең кара төнгә
шигырь яза... Шагыйрь мәллә син?!
Сүзсез сүздән хасил шигырьнең дә
аңлашыла икән мәгънәсе.

Күзләремне йомам, керми калсын
шигыреңнең соңгы сүзләре –

мин үземчә генә дәвам итим
хисләремнең яңа эзләрен...

Кыштан чыгып янә көзгә керәм,
янә җәем, янә кайта яз...
Күзләремә тамган сүзсез шигырь –
яшьлегемнән кайткан кайтаваз...

*6 апрель, 2008*

## МАКТАЛУ ТУРЫНДА

1

Кайчак кәеф начар була –
бәгырьне нидер телә...
Шулчак сабыйдан булса да
бер мактатасы килә.
Сүнеп барган учак-утың
тергезүче җил көтә...
Бер җылы сүз шулчак җанны
очындыра-җилкетә.

2

Кайчак күңел җәннәт була –
кош сайрый, кояш көлә...
Шулчак сабыйга булса да
бер мактанасы килә.
Горурлык та авыр йөк ич! –
мин моны күптән беләм.
Мактанмасаң, макталмасаң,
җанда яхшылык үлә!..

*5 апрель, 2008*

## БЕР ТУҢАМ, БЕР ЯНАМ

Учым пешә – әллә утлы каләм,
әллә инде йөрәгемне тоттым,
әллә инде илем һавасының
хәвеф-хәтәр тулы тынын йоттым...

Җаным туңа – әллә бозлы күзләр,
әллә суык сүзләр үтеп керә,
әллә инде илем туфрагында
бозлавыклар чорын кабат күрәм...

Мин йә туңам, йә янамын һәр көн –
булып беттем кеше дигән корыч...
Киләчәктә кемдер каләм ясар,
кемдер ясар миннән булат кылыч.

*4 апрель, 2008*

## АКЫЛЫҢНАН АРТКА КАЛГАЧ

Акыл башы алга киткән була...
Илләр калган була чабуында,
данлы үткәннәрдән яңгыраган

горур кайтавазлар җырын тыңлап...

Ә акылны тарта яңа офык...
Чабуын ул кискен йолкып ала...
Акылыннан артка калган илдән
хәрабәләр өелешеп кала...

*4 апрель, 2008*

## КӨЗГӘ ЯУМА

Юк! Юк! Көзгә яума, язгы яңгыр –
көз дымында салкын кыш яши!..
Чәчәк була алмас беркайчан да
һәр тамчыңа сеңгән кояшың.
Болытыңда килеш очып кит син
Җир шарының язлы ягына –
хәтта шәүләң җанга кагылганда,
шашкын хисләр канда агыла...

*27–28 март, 2008*

* * *

Әгәр сиңа туры килсә
күктән җиргә сөрелергә,
тилгән булып атыла күр
дан калырга яки... гүргә!..

Әгәр сине, эзәрлекләп,
әверелдерсәләр үчкә,
бүре булып ыргыла күр
кимсетеп тәм тапкан көчкә!

Күрмәмеш-ишетмәмешкә
салышсалар сине бермәл,
ымсындыргыч тынлык булып,
көнчеләргә тынгы бирмә.

Кунак ашы – кара каршы,
ә бүләккә каршы – бүләк...
Ләкин булмый һәрнәрсәгә
тик яхшылык белән түләп...

Онытылу-онытылмау
тормый беркем теләгеннән –
хатирә белән кайтара
кеше синең бүләгеңә.

*10 март, 2008*

* * *

Кайчакларда мин янартау булам,
чыгырымнан ләкин чыга алмыйм –
йөрәгемдә гарше көрси тапкан
кеше дигән «тәңре» комачаулый.

«Ул» чыгарган кануннарның колы
булып яшим, шартларыма җитеп...
Һәм бәхетем, ни зурлык булса да,
тулы түгел – аның чите китек...

Кайчакларда күбекләре күккә
тигән дулкын булып ыргыламын...
Йөрәгемдә Тәңре яшәсә дә,
куплетларга сыйган җыр гына мин...

## ӘЗЕР

Ә офыклар якыная,
үзем атламый торсам да...
Кайчак ишетелеп куя
мәңгелек тынлыктан шаңдау*.

Җан курыкмый... Аң да әзер
серле шаңдау белән бергә,
офыкта офык булмаса,
тынлыкка әверелергә...

## АЧЫЙМ МӘЛЛӘ?

Ачыйм сиңа күңел ишегемне.
Үзем инде анда керәлмәм...
Язмыш юлым, кайдадыр башланып,
бусагама эчтән терәлгән.

Бәхет юлын булмый ике кичеп...
Табылмаган нәрсә табылмас...
Ә кешегә ләкин була ачып –
минем хаталарга абынмас!

Мин ул юлны тышка дәвам итәм...
Ә син эчкә керә аласың,
һәм бәхетнең кайдан башланганын
шул җиһанда күрә аласың.

## * * *

Эчке җиһан кояшы да
шәүләләр төшерәдер...
Хайванныкы – хайвандайдыр,
кешедән – кешедәйдер.

Аңнан, хистән, тойгылардан,
тәмнән, истән, төстән дә
эчке дөньям Җир шарына
шәүлә күпләп өстәлә.

Тышкы шәүләләрдәй алар
күздә югалмый, сүнеп...
Алар мине Мин итәләр,
кайнар каныма сеңеп.

Күзем йомам... Ак җиһанда
кояш кап-кара төсле...
Шул кояш сузган шәүләләр
төсле, аңлы, хуш исле...

## ФАНИЛЫК ТУРЫНДА

Ничектер ул, кайчандыр яралган да
чишмә булып тоташкан минем канга.

Сизелмәгән... Сиздермәгән ул үзен
фани мәшәкатьләр тулы көнозын...

Төшеп, кояш тиде өй кыегына...
Юк, куркытмый... Шулай да боегыла...

*7 март, 2008*

## ТӨН КҮЗЕ

Кара күзләренә карап төннең,
шигырь укыдым мин хисләнеп.
Тойган кебек булдым яшьлегемнән
бүгенгемә җилләр искәнне.

Җылы җилне чама белми эчеп,
мин исердем бугай чак кына –
үз серемне үземә фаш итеп,
уйнадылар канда чаткылар.

«Әле сөя алам!» дигән уйлар
оялдылар талган йөрәктән...
Шигырь эчеп исергән төн күзе
хискә буйсынырга өйрәтә...

*29 апрель, 2008*

* * *

Көз гөлләрдән башлана да
бетә ап-ак карларда.
Ул ничек моңлы булмасын,
йөрәгендә кыш барда?!

Яз шул кардан агып чыга
һәм әйләнә гөлләргә.
Ничек куаныч тулмасын
наз көткән күңелләргә?!

Гомер буе яз да, көз дә
миңа бердәй булышты –
берсе уйның башы булса,
берсе булды уңышы.

Язлы көз дә, көзле яз да
йөрәгемә ят түгел.
Шуның өчен җаным җылы,
ә өметем якты гел!

*3 март, 2008*

## ОЗЫНБОРЫН

Һәр сүземне кызыл кирпеч иттем –
гомер буе нидер төзедем...
Арып-талып ял итәргә ятам.
Озынборын өзеп безелди.

Йокы бирми бирән кан эчкече...
Килеп кунган саен сугамын...
Мин, ахрысы, бары озынборын
куар өчен бина корганмын!..

Җанга тынычлык юк! Кан кадерле!
Гомер буе корган бина да!..
Әйтерсең лә минем гомеремне
минем Заман тапкан зинадан...

*4 март, 2008*

## Ә СОРАУЛАР КӨЧЛЕ ҮЛЕМНӘН

Арыдыкмы? Әллә адаштыкмы?
Әллә инде мираж күрдекме?
Әллә инде хыял җәннәтеннән
реаль өйгә кайтып кердекме?

Ник атлыйсы килми? Офыкларның
ник күрәсе килми аргысын?
Җыр җырлыйсы килмәү аңлашыла,
ә ник килми менә каргыйсы?

Ә җавап юк! Бөтен-бөтен җирдә
тимер-бетон сорау эленгән...
Инша Алла, ярый сораулар бар,
ә сораулар көчле үлемнән!

*4 март, 2008*

## БӘХЕТЛЕЛӘР АРАСЫНДА

Бәхет өләшә бел тирә-юньгә,
һавасын шуның сула –
бәхетлеләр арасында гына
бәхетле булып була!

## ХАТЫНЬДА

Хатынь учаклары күптән сүнгән
диеп уйлый идем ерактан.
Туфрагына аяк тию белән
нидер куырылды йөрәктә.

Һавасында авыр көек исе...
Һәм күңелнең китте мазасы...
Ялкын, төтен күрсәтмичә генә
Нидер пешә монда... казансыз.

Күңелемнең эчкәресен багам.
Сәер табын анда корылган...
Нәфрәт дигән тулы бокал алам...
Ачу шәрабына орынам...

Янып төтен булган белоруслар
рухы яна монда, пешерә...
Ә мин башны салкын ташка терим –
кешелеклегемне тикшерәм...

*2006*

## ҮЛГӘН АВЫЛЛАРГА

Үлгән авылларга һәйкәл кирәк!
Кайда куйыйк? Койыйк нәрсәдән?
Хәтта тыныч чорда, тыныч илдә
мондый һәйкәлләргә бар сәбәп.

Мин мәктәпкә йөргән ничә авыл
арыш кырларына әйләнде!..
Кайда куйыйк, нәрсәләрдән койыйк
безнең «Хатынь»нарга һәйкәлне?

Бу шигырьне мин Хатыньда башлап
язам, язам, язам ничә ел...
Мин Россия буйлап күп йөрим шул –
шигырь тәмамларга юк җаем...

*8 май, 2006, 28 апрель, 2007*

* * *

Мин, әлбәттә, бөек шагыйрь түгел –
бөегрәкләр туган элгәре.
Мин аларның юлын гына сузам,
тирәнәйтәм генә эзләрен.

Мин шулай ук вак-төяк тә түгел –
тыгыз иләкләрдән иләнмим.
Татар йөзегендәге мең ташның
берсе буласымны беләм мин...

## ҺӘМ МИН ӘЙТӘМ

Миңа, имеш, заман фәһем салган,
аның тугры теле, имеш, мин...
Һәм мин әйтәм:
төнне җиңгән таңнар
көнгә төс бирергә тиешен.

Төнге назлашулар җимеше мин.
Төнгә тибү миңа килешми.
Ә шулай да
төнне җиңгән таңнар
көнгә төс бирергә тиеш дим!

Мин Анамнан туры акыл алган,
юктан барга таба килешли.
Шуңа әйтәм:
төнне җиңгән таңнар
көнгә төс бирергә тиешле!

## ЧИКЛЕ МИН

Ни тартуына буйсынып, йөрәк
күкрәк читлеген чыкмакчы ватып?
Тартадыр күкнең гарше көрсидән
бер катлам гына астарак каты...

Андагы тынлык, якты тынычлык,
чиксез ireккә күнеккән хисләр,
тәнсез җанымның тәнле ләззәте!..
Йөрәк – хыялый, чөнки ул – исәр:
сизми чамасын, күрми чарасын,
аермый актан төснең карасын,
шул катлам белән үзе арасын
белми ул! Белми ничек барасын...
Ни гаҗәп – үзем шатлык кичерәм,
ватса да йөрәк күкрәк читлеген...
Җир тартуыннан арына алмый
хәтта акылым!.. Чикле, чикле мин...

* * *

Тулышып килгән елга өстеннән
яңгыр болытын куып тараттым –
яусын урманга, яусын кырларга.
Ярдан чыгуны һич тә яратмыйм.
Мин тынычлыкка күнегеп беттем
табигатьтә һәм кан агышында –
хәтәр дулкыннар ярала хәтта
керфеккә керфек кагылышыннан.
Ярсу ташкыннан мин инде куркам...
Курка акылым... Әмма йөрәгем:
– Син бит шагыйрь! – дип, –
бик уйланма, – дип,
куркак акылның бирә кирәген...
...Ә яңгыр ява... Ява кайдадыр,
кемнеңдер җанын ташкынга манчып...
Ә мин утырам елга ярында
йөрәкне бикләп –
тормыштан качып...

## АКЫЛ ГАЗАПЛАНА

Җәйләр үтмәс, дидем...
Көзләр җитмәс, дидем...
Хыялыма минем
кемдер күзе тиде –

үтте инде җәйләр,
көзләр үтеп бара...
Салкын кыш белән дә
якыная ара...

Ә көн шундый матур!
Ә төн шундый татлы!
Хушлашасы килмәү
гакылны газаплый...

* * *

Көннәр узган саен, юл кыскара...
Юллар үткән саен, уй арта...
Башым инде күптән гөжләп тора,
гүя язга чыккан умарта.

Ә уйларым кырлар-болыннардан,
кара урманнардан бал ташый...

Тик тормыйлар заман чалгылары,
һәм тик тормый Вакыт балтасы.
Ач уйларга шикәр ашатырга
вакыт җитә, алып кибеттән...
Сихәтлеге кими уйларымның,
юлларымны шулар киметә...

* * *

Иң алсу таң үтәчәк,
иң якты көн китәчәк,
иң сүрән кич бетәчәк,
иң тирән төн җитәчәк.

Алсу таңның ал төсе
хыял булып саклана,
аңа кагылган саен,
күңелебез сафлана.

Якты көндә Язмышның
без йомгагын сүтәбез –
бер җебен Җиргә сузып,
тормыш юлы итәбез.

Сүрән кичтә иңдәге
ике фәрештә язган
дәфтәрләрне укырбыз...
Беравыктан... бераздан

тирән төн йотар безне,
иң-иң тыныч, серле төн...
...Шушы юлны язганда,
фантазиям сөрлекте...

Ә хәзергә – алсу таң,
ә хәзергә – якты көн,
ә хәзергә – җылы кич,
ә хәзергә – кыска төн...

*9 октябрь, 2010*

## КИРЕ КАЙТМАС ИДЕМ

Мин яшьлеккә кире кайтмас идем,
мин озайтыр идем картлыкны!..
Һәр мизгеле яшәүнең – куаныч,
озын-озак картлык шатлыклы.

Яшьлек – хыял, өмет хәрәкәте!
Күренми дә кояш яктысы...
Ә картлыкта күңел чоңгылына
төшә Айның көмеш чаткысы.

Көндезләрен кояшсыз да әйбәт.
Айсыз төнгә чыгып кара син! –
Йөрәк типкән килеш, ачык күздән,
тар ләхеткә килеп тарасың...

Мин яшьлеккә кире кайтмас идем,
хәтта кире кайтып булса да...
Ике гомер бер кешегә – артык...

Юк, кирәкми таныш бусага...

*13 декабрь, 2010*

## ҖИТМЕШ ЯШЬЛЕК ЮЛЧЫ

Нәрсә әйтим инде сезгә бүген,
күңелемнең йомшак чагында?..
Миңа бик тә рәхәт, замандашлар,
бергә булу олуг табында.
Миңа бүген мактау кирәк түгел –
күп укыдым купшы сүзләрне...
Коръәннән соң иң акыллы китап –
кешеләрнең җылы күзләре.
Күзләрем дә, йөрәгем дә ачык –
керегез дә шунда йөрегез.
Халкыбызны җанга кертсәк кенә,
вакыт йөрәгендә тере без!
Нәрсә әйтим? Мин атладым фәкать
өмет итеп җылы, яктыны.
Үзгәрмәде, борылмады юлым,
ә тоела никтер ят булып...
Әллә кая булды мәтәлгәнем,
биеклеккә булды ашканым –
табынырлык нәрсә табалмадым
намус сафлыгыннан башка мин.
Карыймын да җитмеш минут сыман
узып киткән еллар ягына,
күздә йөрәк күренерлек булып,
әти-әниемне сагынам.
Нәрсә әйтим? Бер чың калсын диеп,
чәчем көмешенә чиртәмен.
Ләкин ул чың кичә алыр микән
вакыт чукраклыгы киртәсен?!

*15 гыйнвар, 2011*

## НИНДИ МӘХӘББӘТТЕР

Нинди мәхәббәттер йөрәгемдә –
бөтенләем белән яратам...
Давылланган хисләр диңгезендә
күзем йомып йөзәм корабта.

Бер убылам упкын төпләренә,
бер чөеләм дулкын сыртына...
Чоңгыл карасыннан кояшкача
зәңгәр дөнья шаулап ертыла,

ташкын-ташкын булып, шуннан ага
җәннәт суы – эчеп туйгысыз...
«Йөрәк» дигән рульсез корабымны
шунда бора сөю тойгысы.

Һәм ачыла миңа күк капусы...
Фәрештәләр җырлый тезелеп...
Бу дөньяга инде кергән идек
синең белән бергә без элек...

Кышкы буран төсле чәчләремә

язлы кулың синең кагылгач,
мин кабаттан шул дөньяга очам...
Мәхәббәтем минем тагын ач...

*24 декабрь, 2010*

## ОРЫП БӘРӘБЕЗ

Чакрым саны белән үлчәнми юл,
адым саны белән үлчәнә.
Адымнар да төрле... Кайчакларда
яланаяк бастык билчәнгә...

Океаннар, таулар, ком чүлләре,
карурманнар аша атладык...
Хозыр-Ильяс, Илья-пророклар
бүгенгәчә безне яклады.

Көннәр саны белән үлчәнми ел,
юллар саны белән – төшендек.
Кайгы бизи кайчак, шатлык боза
үзен санламаган кешене.

Әй, йөрәгем! Күрәсене – күрдек...
Киләчәккә карап пошынма!
Гомер көзе белән куркыталар!..
Орып бәрәбез без кышын да.

*17 октябрь, 2010*

## ТАР ОЯДА

Колачларның киңлегендә
юк иде безгә тиңнәр...
Тар ояда тора-тора
тараеп калган иңнәр...

Күзелдерек* киеп йөреп,
күзнең чокыры кипкән –
вак ташларга абынабыз,
йолдыз күрмибез күктә.

Үз-үзебез белән генә
сөйләшеп яши-яши,
акылыбыз бакчасында
помидор һаман яшел.

## УЙ ҺӘМ КОДРӘТ

Тәре – уйлап чыгарылган –
кеше аңының үре!..
Кояш һәм Ай – яратылган!
Алар Кодрәт күк тере.

Биш, алты, җиде нур белән
балкыган йолдызлардан
әллә күпме халыкларның
рухына иңә ярдәм...

Йолдызлар да уйда туган
һәм мәгънә алган уйдан...
Ай белән кояшны Кодрәт
үз барлыгыннан койган.

## БЕЗ БАР!

Эпир пулна, пур, пулатпар!
*Пётр Хузангай*

Без булганбыз, бар, булырбыз –
нинди генә җил исмәсен!
Кәфен итәргә бирмәбез
салкын Заманалар бәсен.

Вакыт аккан, ага, агар! –
Җиһан аңарга улактыр...
Без булганбыз, бар, булырбыз!
Эпир пулна, пур, пулатпар!

Афәт – үтәр, хәтәр – китәр,
арынырбыз яралардан
һәм үрчербез, ирдә – ирлек,
хатында хатынлык барда.

Диңгез, кайнап, тамырларга
мәңге бирә торыр дымын...
Без булганбыз, бар, булырбыз!
Мы были, есть, и вечно будем!

Көн белән төн чиратлашыр...
Бәлки, буталыр да кайчак.
Ләкин бездә яшәү рухы
бирүче сүз табылачак:

без булганбыз, бар, булырбыз!
Һәм кайтыр кайтаваз булып:
Эпир пулна, пур, пулатпар,
мы были, есть, и вечно будем!

## НИЧӘ ҮРДЕР ШУПАШКАРДА

Ничә үрдер Шупашкарда –
санаганым булмады.
Кайсы үр дә шәһәр өчен
биеклеккә бер адым.

Идел ярыннан карасаң,
ул болытка кагылган...
Ә карасаң тәрәзләргә –
акчарлаклар чагыла.

Урман, яшел келәм булып,
эленгән текә ярда...
Нигәдер рәссам буласы
килә бу Шупашкарда.

Ләкин дуслар минутка да
мине ялгыз калдырмый,

янәсе, рәсем ясатып,
күзләремне талдырмый.

Ә соклану тынгы бирми –
ул дулкын, давыл, газап...
Шуңа күрә хисләремне
мин шигырь итеп язам...

## ИЛҺАМ ШАКИРОВ

Исеңдәдер, Илһам чордаш, бергә-бергә
барган идек «Ваһаповка» без, Сембергә,
аңа хәтле – Шупашкарга һәм Ижкарга,
аңа хәтле – кызыл кальгалы Нижгарга –
Аллаһ шунда Ваһаповка җыр иңдергән,
җырчы булып тормыш итәргә күндергән.

Тавыш барда җырламау ул – гөнаһ, дидең...
Тавыш синдә – әле һаман көзге Идел
дулкыннары кебек ярсу, тирән, куе,
әйтерсең лә гомер буе дәрья уен,
шик-шөбһәсен, дәрт-дәрманын сеңдергән ул,
ә дәһшәтен ярга бәреп сүндергән ул.

Сембер сәхнәсенә үзең чыкмас борын
исемеңне ишетүгә, халык торып
басып алкышлады сине – дәррәү купты...
Һәм син чыктың кечкенә бер китап тотып:
– Ренат Харис китабына кереш сүзне,
бик сорагач, язып бирдем, – дидең, – үзем, –

эзли-эзли ниндидер кирәкле битне...
Җилсез урман булып, халык синнән көтте
хикмәтле сүз Рәшит Ваһапов турында.
Һәм син әйттең: – Кыскасы, аның җырында –
татар, татар тавышы һәм дә гүзәле! –
әллә нинди сынауларга да түзәрлек...

Буран тулы урман кебек шаулады зал...
Пегас-атта тарих чиген уза-боза,
уем китте фикерең мәгънәсен эзләп...
Төшенәм дә, төшенмим дә – синең сүздә
сизелеп тә күренмәгән нәрсәдер бар!
Аңлар өчен, ахры, минем маңгаем тар...

Мин Казанга кайткач та озак баш ваттым...
Аннары соң үзеңә үк шалтыраттым.
Син аңлаттың... Мин аңлаган кебек булдым
һәм тымызык тынга чумдым, онытылдым –
әллә нинди дөньяларда очып йөрдем,
Таудан җырга узды Дала – шуны күрдем.

Җырны тапты, юды җылы сөткә салып
һәм корытты җилләреннән сөлге алып,
йолдызлы төн иләгендә нурлар иләп,
барысын кемгәдер сузды: – Ал һәм билә!
Уй-хисләрем үземә кайтты чабышып...
Телефоннан яңгырый татар тавышы.

*25–26 ноябрь, 2006*

## КАМИЛ ЗЫЯТДИНОВ

Исеңдәдер, Камил, мин нык чирләп киткәч,
җылы тәнгә пычак орыр вакыт җиткәч,
карап торгач тере кояш, үле Айга,
киңәшеңнән булыр диеп җанга файда,
йоклаттым да корвалол биреп оятны,
төн берендә сине йокыңнан уяттым.

– Абзый, – дидең, – сөйләп торма, хәлне беләм,
иртәнге сәгать җидегә синә киләм,
һәр бөерне ясаган ул Ходай белеп,
җиде уйлыйк бер тапкыр кисүдән элек...
Шулай дидең. Шулай иттең... Иң көчлесе –
алып килдең хирургның да зәркәнчесен.

Иртәгәсен көзнең кар катыш яңгырын,
эз югалтыр өчендер, эзгә яудырып,
мине олы, кадерле зат итеп, зурлап,
башка дәваханәгә илттерден урлап.
Караклыкның берсен дә китап мактамый –
нәкъ шундый фикердә идем ул чакта мин.

Хәзер мактыйм, чөнки аңлыйм, чөнки беләм –
кайчак кеше дан өчен корбан ителә
юлбашчы йә гаскәр башы тарафыннан...
Ә син, Камил, мине язмыш тарагыннан
шундый куллар белән тараттырмагансың –
йөрәгеңдәге Табибны тыңлагансың.

Син, министр башың белән, кече булып,
бер дә меңне күрә белгән кеше булып,
карагансың ул чак минем каләмемә,
ә каләмем татарымның әләменә
күпме чигеш өсти алды шуннан бирле
һәм җырымның юлы иттем синдәй ирне!

## БЕРӘҮНЕҢ ЮБИЛЕЕННАН СОҢ

Мактадылар: җебе – алтын, энә – көмеш!..
Димәк, бөек бер чигеш булырга тиеш.
Җөйләре бар – күз камаша ялт-йолт, ялт-йолт,
ә акылны яктыртырлык яктылык юк.

*26 ноябрь, 2006*

## СОҢГЫ УТ

Гарьлек утын күз яшенә ташлап,
ташкынында аның сүндерә...
Шулай кеше җаны ханлыгының
тәхетенә Тынгы менгерә.

Яшәп китә матур, тыныч кына...
Ләкин күрә – кемдер уздыра!
Ниндидер җил, йөрәгенә кереп,
утка өреп, канын кыздыра.

Дөрләп китә ялкын Хөсетлеге!
Яна тәхет, яна Тынгысы...
Башына да килми: мондый яну –
хурлыклысы утның,
соңгысы...

## КӨНЧЕЛЕК ТУРЫНДА

Көнчелегең җаныңа ут салган –
йөзләреңдә ята сөреме.
Елмаюны ефәк пәрдә иттең
һәм йөрисең шуңа төренеп.

Көнчелегең каш астында яна –
күз нурларың инде кап-кара
кисәү булып, җаным кояшында,
ләззәтләнеп, таплар актара.

Көнчелегең синең юк итәчәк
кешелеклелегең тамчысын...
Йөрәгеңдә яхшылык та бардыр?!
Ник син шуның юлын ачмыйсың?

## УРАМ

Күңел дөньясы гаҗәеп! –
үзгә анда вакыт, үлчәм...
Тамчы кадәр бер уңыш та
диңгез-шатлык китерүчән.
Яңгыр тамчысыдай шөбһә
убырлы дулкын кузгата,
ышанычны талкып тетә,
тынычлыгыңны боз вата.
Һәм китәсең уең буйлап
берәр ышык эзли-эзли...
Урамга килеп чыгасың!..
Һәм урам коткара безне.

* * *

Суладык та, су да алдык,
тау юлын да таптадык.
Җәннәтләрдә яши-яши
җанга сихәт тапмадык.

Әлегә туган илләрдән
җәннәт ягадарак шул...
Һаман аңа җитеп булмый –
юлы текә, җил каршы...

Туган илнең тузаны да
кунар күк кершән булып...
Таулар башыннан кул изи
фәрештә төсле болыт...

## СЕЗ КҮРСЕН ДИП...

*Гөлнара Сергеевага*

Шигырь кайчан, ничек килә димсең?
Күргәнем юк аның килгәнен.
Мин мең күрәм кеше елаганны,
гөл үскәнне, сабый имгәнен,
ялгыш өскә чыккан тамырларны,
аска киткән агач табутны,
байрак җилфердәвен, кар явуны,
төн карасын җиңгән таң утын,
орлык көткән туфрак җемелдәвен,
кысыр хатыннарның аһ-зарын,
чигәләрдә чәчләр агаруны,
түрәләрнең төшкән базарын...
Шигырь килми миңа...
Киресенчә,
кайчак күпләп, кайчак әз-әзләп,
чыга миннән миндә талган шигырь,
барып ята ап-ак кәгазьгә –
сез күрсен дип...

## БЕЗ ӘЛЕ ҺАМАН УЗАМАН

*Фоат Галимуллинга*

Тора торгач, килеп җиттек
«алтмыш биш» дигән ызанга,
ләкин тормыш уенында
без әле һаман узаман.

Безнең әле һәр әгъзабыз
Ходай ясап куйган төштә,
пенсионер түгел әле,
үзенә тиешле эштә.

Кайсыбызның чәче көмеш,
кайсыбызның башы такыр...
Акылыбыз бакыр түгел,
чөнки тел – без, ә сүз тапкыр.

Теләсәк – телеп алабыз,
ямап куябыз теләсәк...
Мактансак та ярый, чөнки
ике дөнья – бер күләсә.

Тәхетләр-креслолардан
куркып тору калды ерак...
Алтмышкача – егет кенә,
менә хәзер без – чын ир-ат!

Кайгыларны күтәрәбез,
шатлыкларны үткәрәбез,
гайбәтләрне түнтәрәбез:
күңел – иң сизгер пәрәвез!
Тора торгач, килеп җиттек
менә без дә алтмыш бишкә.
Шөкер, әле һәр әгъзабыз
Ходай ясап куйган төштә!

*Март, 2001*

## КОМПОЗИТОР КЛЮЧАРЁВ

Илгә нинди көйләр бүләк итте!..
Һәрбер көйдә гөлле, көләч рух.
Ул – Казанның җырлы бер символы,
Александр ага Ключарёв!

Ялган тарих белән сугышканга,
төрмәләргә кереп, кыелып,
безне якладылар, батып канга,
рус Худяков һәм рус Гумилёв.

Татар җырларының тынын буып,
көлке-мәсхәрәгә чыгарып,
кимсеткәндә безне, калкан булып
калкып чыкты, басты Ключарёв:

«Яшь киленнең төн яменнән талып
тын алуын ап-ак мендәрдә,
мендәр эчендәге мамыкларның
кыштырдавын матур төннәрдә,

бөек гарасатлар гөрелтесен,
аң буйлата уйлар агышын,
чәчәк исен һәм дулкыннар төсен,
шатлык, кайгы, сагыш, каргышны

сурәтләргә көче җитә, – диде, –
татар җыры, татар көенең!..»
Бу шулай ук каһарманлык иде,
татар өчен русча көенү!
Һәм шуңа да
без – рәхмәтле милләт –
җаныбызга аны керткәнбез,
гүзәл моңнан хасил гөлгә тиңләп,
безнең Гөлчарёв дип йөртәбез.

## ЯНДЫРГЫЧ КАТНАШМА

Булган кадәр акылымны
тулган кадәр канымда
болгатам да яза торган
учак булып кабынам.

Ул учакта ялкын түгел,
җилфердәшә сүзләрем...
Дәфтәремдә шул сүзләрнең
шигырь булган эзләре...

Мин – яндыргыч катнашмадан
хасил булган коралдыр!
Мине дошманга бәрегез! –
янмый озак торалмыйм...

Бәлки, дусларга кирәкле
дарудыр мин, дәвадыр...
Бәлки, мин – сез сизми генә
сулый торган һавадыр...

*21 декабрь, 2005*

## КАЗАН – ҖИЛКӘН КИРГӘН КОРАБ

Мин шашынып шатланамын
яңарган Казанга карап.
Син дә, дустым, башкаланы
минем кебек ихлас ярат!
Гомер буе, яз да, көз дә,
карлар һәм яңгырлар аша
күңелеңне үсендерсен
Казан дигән бу тамаша.
Ләкин сызланып сагынам
мин элекке Казанымны,
гәрчә кичә генә күрдем
искесенең азагын мин:
тәрәзә йөзлекләрендә
тавис кошы балаларын;
пәйгамбәрләр таягыдай
куш капка баганаларын;
җамигъ мәчет минбәредәй
челтәрләнгән болдырларны;
энҗе-мәрҗән тартмасыдай
мезониннар, балконнарны;
күккә төбәлгән сорнайдай
яңгыр суы торбаларын;
император таҗы сыман
кәпрәешкән морҗаларын
мин сызланып сагынамын,
яшьлегемне сагынгандай,
ә бүгенгем кадерлерәк –
тамырларда аккан кандай!
Шуңа да шашып шатланам,
өр-яңа Казанга карап.
Бусы да бер сагындырыр
тора-бара, тора-бара –
Вакыт җиле туктый белми.
Казан – җилкән киргән кораб!
Дәверләр дулкынын ярган
бу корабны син дә ярат!
Җилкән җилне яраткандай,
бу корабны син дә ярат!

* * *

Хатын-кызсыз өйләр – тәм-тозсыз,
учак – утсыз, суыткыч – бозсыз,
сыер – сөтсез, күңел – үксез,
шигырь – юк сүз!..

*4 апрель, 2008*

## СӘГАТЬ БОРГАНДА

Күзне ачып, «Мин Галәмне күрәм!» димен.
Мин алданам...
Мин алдыймын сәләтемне.
Күзне ачып, тик Дөньяны күреп була,
күзне йомып –
бар Галәмнең галәмәтен!..
Дөнья – тышта,
Галәм эчтә икәнлеген

мин аңладым борган чакта
сәгатемне.

*22 июнь, 2003*

## КЕМДЕР ЧАБА

Озак чаптым, сөйрәп Замананы –
үзебезнең «татар заманын»...
Юк, әле дә туктап калганым юк!
Мин әле дә булса чабамын...

Алда, мине узып, кемдер чаба.
Якынлашам кайчак мин аңа.
Һәм күрәмен: мине дәртләндереп,
минем алда чаба Замана...

*26–27 гыйнвар, 2004*

## МӘЙДАН ЭЗЛИМ

...Чыктым да җиңелеп кердем...
Ник утырамын көлеп?
Мир каршында җиңелүгә
гарьләнә идем элек.

Гарьләнү – дәртне кузгата,
үзеңнән көлү – уйны!
Хәзер моның турында мин
тик көлә-көлә уйлыйм.

Җан канәгать җиңүләрдән...
Ә горурлык ач күзле –
дөнья билен ала торган
лаеклы мәйдан эзли...

*4 май, 2004*

## «ИЖМИНСУ»

Бүген миңа бик тә моңсу –
ерак кала «Ижминсу»,
Чулманның биек ярлары,
урманлысы, комлысы.
Шагыйрь маңгаедай текә
ярларына басып, мин
аңлагандай булган идем
бер көрәшнең асылын –
Чулман дулкыннары белән
болытлар орышканны...
Хәтердә – араларына
керергә тырышканым.
Җир белән Күк сугыша дип,
йөрәгем яраланды...
Кинәт салават күпере
аларны аралады...
Күрәм: күкнең гүзәллеге,
төс булып, Җиргә күчә!
Табигатьтә юк сугышу,

бар аңлашу төрлечә...
Беләм, сизәм «Ижминсу»ның
исләремә төшәсен –
өстәлемдә бик еш «кайный»
«Шифалы су» шешәсе.

*22 февраль, 2004*

## ИКЕ ОТЫШ

Бәйге данын иң беренче килгән
атлар тота.
Гомер финишына соңлап килгән
кеше ота...

*8 гыйнвар, 2005*

## СЕРГЕЙ ЕСЕНИН

В Хороссане есть такие двери...
*Сергей Есенин*

«Ник Казанга килеп чыкмадың син,
ник какмадың безнең ишекне?» –
дип уфтанам инде гомер буе...
Рухың мине һаман ишетми...

Казан ишекләре – бакыр тупса,
ачылалар җырлап-шыгырдап,
ишекләрдә йозак булмаганга
сизелсен дип керү-чыгулар.

Син кергәндә алар җырлар иде.
Һәм, ишетеп ишек тавышын,
татар кызы килеп чыгар иде –
булыр иде нинди танышу!

Хорассанның чадра томаннары
хәтта җенне пәри иттерә...
Ә Казанның алсу гүзәлләре
күзләреңә күзен үптерә...

Ни өчендер синең шигыреңдә
һаман эзлим татар кызларын...
Казан кызы пәри генә түгел,
ул эретә сагыш тозларын.

Ник Казанга килеп чыкмадың син,
эшләреңнең ташлап кайберен?
Чакырусыз кунак, шагыйрь булса,
чакырулы кебек кадерле!

## ОЧКЫН

Бу шигырьне бик тартынып язам...
Язмый кала алмыйм – шул чыны.
Мостай Кәрим учагыннан, чатнап,
минем башка төшкән очкыны.

Күн кәпәчем көйри үк башлаган...
Көек исен сиздем үзем дә.

Бирәү, көлеп: «Әй, бүреге яна!» –
дип кычкырды, бәреп күземә.

Кем бүреге яна – беләбез лә –
без аңлыйбыз мәкаль асылын.
Мостай шигырьләре Агыйделдәй,
ә кем аны, ничек урласын?!

Эчеп була йотым-йотым гына!
Ә Агыйдел кипми, кыскармый.
Һәм мин эчәм Мостай дәрьясыннан
тустаганлап акыл, осталык.

«Мостай ага, синнән яңа бүрек –
алып бирми кая барасың?»
– Миннән очкын җитә! – диде Шагыйрь, –
ә калганын үзе карасын...

*28–29 сентябрь, 2005*

## ИКЕ ТАКТАШ

Ике тапкыр үлгән... Бер үлемен
үз күзләре белән баккан ул.
Һәм күрми дә калган ят бер Такташ
чын Такташны утка атканын.

Бунтарь йөрәк ялкынында ләкин
шәһит Такташ шундый чыныккан, –
кызыл кирпеч кебек янмас булган
һәм бирешмәс булган чынлыкка.

Газазилне нинди ялкын алсын?!
Фәрештәләр ничек үлсеннәр?!
Әкълимәнең* күз яшьләре тисә,
Галәмдә дә барлык ут сүнәр...

Зәңгәр күккә утлар кабамыни?!
Пәри кызы яна аламы?!.
Күктән төшеп, Җирдә җилфердәде
ул Такташның яңа әләме...

Юк, үлмәде Такташ!.. Ике шагыйрь
яши бүген бер үк аһәңдә...
Җир йөзендә юк ул шагыйрьләрне
көл итәрлек андый җәһәннәм!..

*12 февраль, 2011*

## КАЗАНДА АЛТЫН КӨЗ

Алтын-сары яфрак ява
Казан юкәләреннән.
Өстенә алтын сипсәләр,
кемнәр үпкәләр икән?!

Кояш нурларында дөрли
көзнең салкын ялкыны...
Алтын ялкын бетералмый

күзнең җирән салкынын.

Нигәдер җырлыйсы килә
саф алтын тавыш белән...
Нигәдер җылыйсы килә
көмешле сагыш белән.

Күңелдәге көзге сагыш
үзәкне ала өзеп...
Әллә яңа бер фасылмы
Казанның алтын көзе?!

*12 октябрь, 2005*

## ТУЛПАРНЫҢ ХИКМӘТЕ

*Газинурга*

Пегасның аягын тышаулау –
патшалар хатасын кабатлау!
Тулпарның бар көче-куәте,
хикмәте илаһи канатта.

Канатлар богауга бирешми
гәрештән фатиха булганга...
Тулпарны ауларлык лачыннар
адәми дөньяда тумаган.

Буладыр канатны каерып,
сындырып буладыр, каныксаң...
Буладыр... Буладыр, әмма тик
гәрештән дә биек калыксаң.

*20 декабрь, 2005*

## НАМУС ЯРАЛУ

Чатнап торган күмерләрне
учлап-учлап чөйдем күккә,
җанымның бимазалары
ташый торып, киткәч күпкә.

Һәр очкыны әверелде
ерактагы бер йолдызга...
Кими барды, кими барды
җанымдагы утлы сызлау.

Утка карап торган саен,
керле җаным чистарына...
Күрәсең, намус ярала
Ут-Ананың карынында...

*10–11 ноябрь, 2005*

## РЕЦЕПТ

Маңгайны Җиргә тидереп,
җыймакчы булдым акыл...
Ләкин Җир миннән сорады

һәр хатам үзе хакын.

Кул белән Җирне актардым –
алмакчы булдым дәрман.
Туфрагына тамып кипте
кан тамырымда дәрьям.

Күз белән Җирне назладым –
матурайтмакчы булдым.
Күңелемне әчеттереп,
үземә нәҗес тулды.

Йөрәкне Җиргә терәдем –
җылытмак булдым Җирне...
Шагыйрь булдым. Һәм мин Җирнең
һәр чире белән чирле.

Диңгезләрне кара итеп,
каурыйдан каләм ясап,
шигырь язмыйм, ә Җир өчен
дару кәгазе язам.

*12–14 декабрь, 2005*

## АЛАЙ КАРАМА МИҢА

Алай итеп син карама миңа –
яшер инде бераз хисеңне...
Уйлыйсыңмы әллә кайнар дулкын
боз җанына моның тисен дип?..

Бозмы анда, сүнгән күмерләрме –
күптән белмим инде үзем дә...
Бар акылым эреп бетте бугай
бәхет даулап очкан сүземдә.

Бал тапмаган бал кортлары сыман
кайтып гөрли алар җанымда.
Алай итеп син карама миңа
гаеп эзләп көчсез чагымнан.

Була, була гомер агышында!..
Мин бетмәдем ләкин, үтмәдем...
Мин бар әле, мин бар – тоя алгач
күзең белән әйткән үпкәңне...

*14 декабрь, 2005*

## ЯШЕРЕН ПОЧМАК

Мин, кояшка карап, күз бетердем,
төнгә багып, күзем очладым –
фәкать күрер өчен күңелемнең
үземә дә яшерен почмагын.

Әллә ниләр бардыр кебек анда:
мине үзем итә торган көч,
мине үзем итә торган сөю,
мине үзем итә торган үч.

Чиксез итәр идем һәркайсын мин,
гомеремне шуңа багышлап...
Күреп булмый ләкин...
Алар һаман
минем өчен серле табышмак.

Үз-үзенә кеше сер булмас дип,
уйлап йөрим мәллә артык күп?!
Асылымны ачыклыйсы килә –
үлемсезлек сере шунда күк!

*22 декабрь, 2005*

## БАЗМЫШ

Кешене йөртә язмыш,
язмышны төртә азмыш...
Азмышлык язмышын башлый
бер юләрлеккә базмыш!

*7 апрель, 2006*

## ТАР ТАМАК

Сүзләре – тыгыз тешләр күк –
арасына уй керми...
Тешли – өзә,
тешли – өзә
бөтен төрле фикерне.

Күрәсең,
тамагы тардыр –
йота алмый капканын...
Шулай инде:
тамактан зур
була кайбер мактану...

*26 сентябрь, 2007*

## ЯЛАГАЙЛЫК ЭТАБЫ

Уйлап куйдым, дус-ишләрнең
күргәч яңа китабын:
шагыйрьлекнең
була икән
ялагайлык этабы!

*24 октябрь, 2007*

## ГРЮНВАЛЬД

Гасырлар хәтере саклый
вакыйгаларның төрлесен...
Илләргә җиңү яулашу –
шуларның иң кадерлесе...

Алтын Урда җайдаклары,
вакытында, кирәгендә

килеп җитеп, әйләнгәннәр
Ягайлоның терәгенә.

Җәләтдиннең кайнар эзе
Польша кырларында тере...
Шул эзләргә бастым, ахры –
чал тарихка киттем кереп:

Грюнвальдка, Полтавага,
Бородино кырларына...
Кергән саен минем рухым
мескенлеләрдән арына.

Минем ерак бабаларым
дус була белгән дусларга:
полякларга, литваларга
һәм – тарих буе – русларга!

Без бүген дә Грюнвальдта!
Дошман эзләмибез һич тә...
Тарихның кылыч чаңнары
безгә дуслык булып күчкән.

*7 июнь, 2010*

## СӘЕР ЛЕГЕНДА

Краковта борынгы манара...
Быргы уйный, менеп, быргычы –
офыкларда дошман күренүне
хәбәр итү аның бурычы.

Быргы хәбәр салган... Моңа чаклы
яшәп яткан халык тынычлап,
кинәт сугышчыга әверелгән,
куллар тотынганнар кылычка.

Ничә гасыр һәр көн үзегендә,
бураннарны җиңеп, яңгырны,
быргы тавышына сеңгән гадәт
сузып-сузып шомлы яңгырый...

Һәм киселә кинәт! Әйтерсең лә
кемдер буа быргы бугазын...
Сер бар икән... Теләмәстән генә
ул сер ачты миңа йозагын,

акылымны минем шашындырды,
йөрәгемә ярсу төяде –
татар угы уяу быргычының
ярган булган чалу сөяген!

Югыйсә бит татар полякларга
яу кырында ирек табышкан!..
Аһ, быргычы! Татарны ул никтер
дошман диеп белеп ялгышкан.

Аһ, быргычы! Минем ерак бабам,
төзәтергә синең хатаңны,
ялган хәбәреңне өзәргә дип,
изге угын сиңа аткан ул!

*11–20 июль, 2010*

## ПАРИЖДА

Париж урамнарын таный аяк!
Таныш нәрсә тапмый күзләрем...
Гасыр катламнары аша сизәм
татар аты тояк эзләрен.

Бабаларым, Наполеонны куып,
Париж урамнарын таптаган.
Дөнья башкаласын ала алган,
ә үзенә дәүләт тапмаган.

Сена суын ерам яхтада мин...
Тарих дымы канны сугара...
Горурлыгым гөле Парижларда
татарчалап бөре чыгара.

*26 октябрь, 2007*

## ЗАМОКТА

Уникенче гасыр замогында,
искелектән яңа ямь табып,
утырабыз төрле уйлар уйлап:
икътисадчы*, шагыйрь һәм табиб**.

Готик түшәм, төсле витражлардан
саркып торган сәер яктылык
күкрәгендә дала җиле искән
кешеләргә ага ят булып.

Кемлегебез тәмам онытылды.
Борынгылык тәмам исертте –
өчебезне өч тарафка ташлап,
романтика дигән хис йөртте.

Уникенче гасыр замогында,
үсмерлектән гаҗәп ямь табып,
утырабыз батыр рыцарьлардай –
икътисадчы, шагыйрь һәм табиб.

## ИСТАНБУЛДА

Әй, Истанбул!
Азаннарың!
«Капулы чаршы»*ларың!
Син мине кан кардәшемдәй
сөенеп каршыладың.
Айа-Софияне ачтың,
керттең «Туп капысы»**на.
Мин йөрдем Муса таягын***
йоткан пәйгамбәр сыман –
сулышым өрергә куркып,
бетәр бу мираж диеп...
Тарихың минем күзләргә
карады назлап, сөеп –
җаныма үткәрде нурын,
каныма калды сеңеп,
төркилеккә куәт бирде –

ул бара иде сүнеп.
Әй, Истанбул!

*10 октябрь, 2000*

## КАРЛОВЫ ВАРЫ

Кайнар магмаларның серен, сосып,
безгә алып чыккан суларның
җылы сихәтлеге бәдәнемнең
яшәү тамырларын сугарды.

Яшьлегемнең яшел болынында
гөлләр терелгәнне тойдым мин.
Шул гөлләрнең чыгын диңгез итеп,
зәңгәр дулкыннарда коендым.

Җиңел, рәхәт булып китте шулчак –
әйтерсең лә минем иңемнән
яза белгән ике фәрештәнең
егылып төште берсе – кимендә.

Мин савап та, мин гөнаһ та кылмыйм,
гаепләмим, ярлыкамыйм да –
күз алдымда җәннәт почмагы ич,
галәм тынычлыгы – канымда...

## ЯРА – ГОРУРЛЫК

Телем минем сырхауламый...
Сырхауламаячак та! –
Юкса күпме утта пеште
һәм эләкте пычакка,
тозакларга күпме капты,
законнарга алданды.
Канлы яралар алса да,
баһадир булып калды.
Яра бит ул сырхау түгел,
яра кайчак – горурлык.
Күкрәктәге кайбер яра
һәйкәлләргә торырлык!

*14–15 декабрь, 2007*

## ФОРМУЛА

Ашыктырып, акыл кертеп булмый
үзеңә дә, сабый башына да.
Әнә көннәр ашыгып чабалар –
Һәм ни файда андый ашыгудан?!

Акыл, асылда, ул – озак яшәү,
ләззәт татып, матур эзләр салып.
Ур-ра! Ур-ра! Бүген мин Акылның
формуласын таптым: «Акыл – саулык!»

*7 октябрь, 2008*

## «ГӨНАҺ»

Гөнаһ, гөнаһ, гөнаһ, диләр.
Гөнаһ нинди сүздер ул?!
Ул сүзне белеп яшәүләр
бик тә күңелсездер ул!

Башны артка борып куеп
алга чабу шикелле...
«Гөнаһтан курку – гөнаһтыр!»
дигән якты шик килде.

Әлбәттә, изге гөнаһтан!
Җылыдан һәм тәмледән!
Шундый «гөнаһ»тан башланган
һәм башлана һәр адәм.

*7 октябрь, 2008*

## ФУТБОЛ

Йөрәк яна бүген... Кәеф сынган...
Футбол янгыннары ут төртте:
Казан негрлары капкасына
Мәскәү негрлары туп кертте...

*19 ноябрь, 2009*

* * *

Караңгы төн җиттисә,
йолдыз һәм минем арада
ят уйлы җилләр исә...

Яп-якты көн җиттисә,
кояш һәм минем арада
ак уйлы җилләр исә...

Ак кәгазь алдым исә,
җанымны җилләр иркенә
бирерлек канат үсә...

*27 сентябрь, 2010*

## ТЕЛ ҺӘМ ХӘТЕР

Беркемгә дә берни әйтми Вакыт.
Вакытның юк теле, хәтере.
Бар нәрсәне ләкин белә Вакыт,
әзер тота һәрчак әйтерен.

Хәтерле һәм телле Вакыт – Тарих!
Бернине дә Тарих югалтмый,
беркемгә дә анык янамый ул,
беркемне дә ачык юатмый.

Күз төшәрлек төштә тотмаса да,
беркемнән дә берни яшерми...
Ул эчкерсез, ул битараф, аңа
ак һәм кара, кызыл, яшел ни...

Вакыт белән берни кылып булмый!
Ул курыкмый, бөлми, сатылмый...
Тел һәм Хәтер булу – менә хәтәр!
Тел, Хәтерсез халык – «акыллы»...

Ә Вакытны кеше Тарих итә,
бар кылганын аңа бирә дә...
Һәм аннары Тарих хәтереннән
Вакыт туктатырга өйрәнә...

*25–27 сентябрь, 2010*

## БУСАГА

Үлем белән яшәү арасында
үтеп чыгалмаслык бусага...
Туган кеше туганлыгын белми,
аңлы-җанлы булып туса да,
үлгән кеше үлгәнлеген белми,
җаны бездә тере булса да...

*15 август, 2010*

## КИЧӘГЕ КӨН ТАРИХ ТҮГЕЛ

Онытыгыз...
Онытыгыз мине...
Сагынырлык булып...
Онытыгыз...
Еллар үтәр... Китабыма ялгыш
күз төшерер, бәлки, оныгыгыз...
«Нәрсә бу?» дип, берәр җөмлә укыр...
Күз шудырыр, бәлки, күршесенә...
Йә беркатлы булып күренермен
миңа чит-ят заман кешесенә,
йә катлаулы булып...
Һәм ул минем
сүзләремдә берәр мәгънә эзләр...
Тау, диңгезләр үзгәрәләр, әмма
мәгънәләрен мәңге саклый сүзләр...
Онытыгыз,
онытыгыз бүген...
Тарих түгел әле кичәге көн...
Сүз сафында шагыйрь хәреф булса,
шигырендә заманасына тиң...

*12 август, 2010*

* * *

Юмарт диеп мактатырга теләп,
ул ыштанын салып биргән...
Аның шәрә тилелеген
дөнья күргән.

*30 июнь, 2010*

## ОЗЫН ЮЛ

Озын юллар каршы ала

безне якты дөньяда.
Шул юллардан, ташкын булып,
гомер дәрьясы ага.

Озын булсын, матур булсын
кешенең гомер юлы!
Сиңа, миңа, аңа, моңа –
барыбызга, барыбызга
телимен шуны!

Озын юллар озын булмый,
тугры юлдаш булганда,
сөйгән ярың һәм дусларың
куәт биреп торганда.

Озын булсын, матур булсын
кешенең гомер юлы!
Сиңа, миңа, аңа, моңа –
барыбызга, барыбызга
телимен шуны!

Озын юллар озын була,
адымлап санаганда.
Без адымнар санамыйбыз
җаныбыз сайраганда!

Озын булсын, матур булсын
кешенең гомер юлы!
Сиңа, миңа, аңа, моңа –
барыбызга, барыбызга
телимен шуны!

## ӘНИЕМ ХАТИРӘСЕ

Күңел күтә – бозлар китә –
язлар җиткән, күрәсең.
Кар сулары тергезәләр
әнием хатирәсен.
Күңел юшкыннарын юа
әнием хатирәсе!

Чиккән алъяпкычың төсле
безнең авыл тирәсе.
Җылы яңгырлар яңарта
әнием хатирәсен.
Сагынычлы җыр җырлата
әнием хатирәсе!

Кырлар – алтын, урман – ялкын! –
кояш чиккән бер рәсем.
Киткән кошлар кузгаталар
әнием хатирәсен.
Үкенечләрне дәвалый
әнием хатирәсе!

Салкын һава, карлар ява –
акка төрә төрәсен.
Мамык шәлләр яңарталар
әнием хатирәсен.
Тагын бер кат җанны җылыт,
әнием хатирәсе!

*2006*

## СИНЕ КҮРГӘННӘН БИРЛЕ

Көннәрем язга чыктылар,
сине күргәннән бирле.
Назлы сүзләр бөреләнә,
язга кергәннән бирле.

Сиңа әйтәсе сүзем бар,
әйтә алмыйча торам,
күзләрең белән булса да,
йә, сора инде, сора.
Йә, сора инде, сора,
йә, сора инде, сора –
телемдәге сандугачым
сайрарга теләп тора.

Көннәрем яктырып китте,
сине күргәннән бирле.
Ачасым килә, ачасым
бөрегә качкан серне.

Көннәрем җылынып китте,
сине күргәннән бирле.
Язгы хисләр күңелемә
тынлык-тынгылык бирми.

Сиңа әйтәсе сүзем бар,
әйтә алмыйча торам,
күзләрең белән булса да,
йә, сора инде, сора.
Йә, сора инде, сора,
йә, сора инде, сора –
телемдәге сандугачым
сайрарга теләп тора.

## КАЗАНДА – УНИВЕРСИАДА!

Хак ярышта җиңгән Шатлык
уйный серенада.
Аңа кушылып җырлыйбыз:
Универсиада!
Россиябездә, Казанда –
Универсиада!

Яшь көчләрнең үзәге син,
Җир шарының бизәге син,
Универсиада,
Универсиада!

Хак ярышта яуланды бу
Универсиада!
Дәрткә дәрман өсти торган
уен сере анда!
Россиябездә, Казанда –
Универсиада!

Яшь көчләрнең үзәге син,
Җир шарының бизәге син,
Универсиада,
Универсиада!

Хак ярышка җыйды безне
Универсиада.
Яшьлеккә хас хисләр, көчләр
китмәсләр заяга.
Россиябездә, Казанда –
Универсиада!

Яшь көчләрнең үзәге син,
Җир шарының бизәге син,
Универсиада,
Универсиада!

## БУА ҖЫРЫ

Без җыелдык, Буа, кабат сиңа.
Онытылмый җылы кочагың!
Ничек саклый алдың сүндермичә
балачакның якты учагын?!

Зөя тугайлары – зәңгәр рәшә,
Бола ярларында – керәшә,
Карлы буйларында күңелебез
сандугачлар белән серләшә.

Һәрвакытта, Буа, кадер-хөрмәт
күрсәтәсең безгә мулдан син.
Әткәйләребездәй囂 эштә булган,
әнкәйләребездәй уңган син!

Зөя тугайлары – зәңгәр рәшә,
Бола ярларында – керәшә,
Карлы буйларында күңелебез
сандугачлар белән серләшә.

Дәртебезгә, Буа, дәрман өстә –
һаман шулай безне сагындыр.
Синдә чаклар искә төшкән саен,
бәхет кошы канат кагыныр.

Зөя тугайлары – зәңгәр рәшә,
Бола ярларында – керәшә,
Карлы буйларында күңелебез
сандугачлар белән серләшә.

*27 декабрь, 2009*

# ӘЛМӘТ МОЗАИКАСЫ

*Өч миллиард тонна нефть
чыгаручыларга*

## КҮП ИКӘНЕН ГЕНӘ АҢЛЫЙМ

Өч миллиард тонна нефть!..
Күз алдыма китералмыйм
моны сыйдырган савытны,
күп икәнен генә аңлыйм...

Сыярмы Кабан күленә?!
Әллә Зәйнең йөз ел буе
аккан суы чамасымы

ташлы ярлар уеп-уеп?..

Эшкә җигәм балачакның
әкияти хыялын мин...
Хыял койган савытка да
ул өч миллиард сыя алмый.

Нефтьче чигәсендәге
бүртенгән кан тамырына
карап торам ышанычта
санга образ табарыма.

Миемнең һәр күзәнәге
киерелгән – чыда гына!
Ләкин бары шаккатудан
хасил шигырь генә чыга...

## СӨЮ ШАГЫЙРӘСЕ

Эх, бер балкып калсын әле яктым! –
Балта сабын салдым учакка.
*Саҗидә Сөләйманова*

...Ә ул учак сүнми әле бездә –
иртәләрен, көнен, кичләрен
дөрли анда гашыйк йөрәгеңнең
сүнми торган уты-хисләре.

Аның җылысында мин дә кайчак
канда каткан бозны эретәм...
Синең нурың, Сөю Шагыйрәсе,
җырларыма минем береккән.

Мин үзем дә хискә ярлы түгел –
җыр итәм дә меңгә өләшәм...
Кешеләрдән һич тә көнләшмәдем...
Сөю шигыреңнән – көнләшәм.

## УРСАЛ-ТАУ БЕЛӘН АҢЛАШУ

«Усал» булып ишетелә идең
хәтта җырларда да, Урсал-тау.
Үзем күреп, шигем таратырга
таба алмый йөрдем бер сылтау.

Ничек инде шундый исем белән
матур җырга барып кергәнсең?!
Еراклардан торып күренмәгән
берәр ямең бардыр, күрәсең!

Әлмәтеңдә күп тапкырлар булдым,
итәгеңә хәтта тотындым...
Ни алайга, ни болайга, Урсал,
кузгатмадың шулчак котымны.

Бу килүдә мендем... Күңел үзен
Алып батыр кебек хис итә:
аста җем-җем килә кичке Әлмәт –
орденнардан хасил хәситә,

әйтерсең лә Ходай бүләк иткән
тырышлыкны безнең сөепме?!
Син – Әлмәтнең эшчән матурлыгын
гүзәл сурәт иткән биеклек.

Һәм шуңа да җырларга керәсең,
матур яңгырыйсың, Урсал-тау...
Синнән дөнья ямьлерәк күренә...
Кабат кавышырга бир сылтау.

## КЕЛӘМ

*Венера һәм Фикус Закировларга*

Әллә нинди булды бу бусага
һәм келәме аяк астында!..
Яшьлегемә кайтып кердем кебек,
шул келәмгә аяк бастым да...

Ярты гасыр элек булган бәйрәм
әле булса якын, тере, үз!..
Курсташым филфак егетенә
физмат кызын туйлап бирәбез.

Стипендиядән шәбрәк акча
дөньяда юк – хәзер беләбез...
Җырлап туган матур гаиләгә
бүләк иткән идек келәм без.

Саклаганнар!.. Аны безнең теләк
тузмас-таушалмаслык иттергән.
Бу келәмгә аяк баскан һәркем
шушы өйгә шатлык китергән.

Изге келәм белән тоташтым мин!..
Җаным якты нурга төренгән...
Мин кунакта яшьлек дусларымда,
мин яшьлектә – оҗмах түрендә!..

*26–28 апрель, 2007*

## ГАМИЛ АФЗАЛЛАРДА КУНАКТА

Барып чыккан саен Әлмәткә без
Гамил Афзалларга керәбез...
Үзебезне анда мәзәк катыш
философиягә төрәбез.

Ул чакта да гадәтне бозмадык –
Каршы алды шагыйрь сөенеп...
Һәм шунда ук чишеп үк җибәрде
чичәнлекнең юмарт төенен:

– Икебезгә менә дүрт аяк бар –
берсе аксак, берсе яраксыз...
Йөгреп йөреп сыйланыгыз әле,
суыткычны иплә карап сез...

Гамил Афзал шулай кунак итте –
теле белән! Моңа ул оста.

Хатынының бер аягы сынган.
Ул утыра иде гипста.

Ә кулында айлык кызы елый –
беребезнең күзе тигәндер...
Шагыйрь әйтте:
– Галия дип куштык –
елак булып чыкты нигәдер...

– «Бану» җитми аңа, «бану» җитми!..
Көтмәгәндә шундый сүз чыкты...
Һәм әнисе «Галиябану!» дигәч,
елавы да бетте кызчыкның.

...Иртәгәсен яңа таныклыкны
алып кайтып салган өстәлгә!..
«Галия»се – Афзаловлар эше,
ә «бану»ы – безнең өстәмә...

## АЛАРНЫ ЯКЛЫЙСЫ КИЛӘ

Әйе, монда яши байлар.
Әйе – байлар! Алар – лаек!
Ничек тозлы булмасын ди
тозлы диңгез кичкән каек!

Ничек баллы булмасын ди
бал ташыган төклетура!..
Әйе, матур бу өйләрдә
байлар матур тормыш кора!

Биредә яши тырышлар!
Алар тапкан хәзинәдән
һәр кешегә өлеш чыга!
«Күп» җыела «әз генә»дән.

Яшиләр монда горурлар –
табышлары белән алар
Җирнең бер меридианын
алтыннан коя алалар!

Монда яшиләр гадиләр!
Алар җырлый, елый, көлә...
Һәм нигәдер көнчеләрдән
аларны яклыйсы килә...

## ЗӘЙ БЕЛӘН ЗӨЯ

Хатирәләр... Хатирәләр...
Балачакның эссе җәе...
Минем телдә – йөгерек Зөя,
синең телдә – ямьле Зәең.

Каз көтүләр, балык тоту
сусыннарда көя-көя...
Башны тыгып эчкәнбез бит –
саф булганнар Зәй һәм Зөя.

Кем ул елгаларыбызга
гайбәт чөя, пычрак өя?!

Хатирәдә әле дә саф
синең Зәең, минем Зөям!

## НЕФТЬЧЕЛӘРГӘ ОДА

Нур өстенә нурлар өстәп,
илдә кара алтын чыга –
Әлмәт, Баку, Төмән, Сибай,
Мангышлактан алтынчылар.
Җир шарының үзәгенә
юллар салдылар алар.
Девон көчен кояш яктысына
ялгый алдылар алар!

Ватанның абруе зурдан –
барлык илләр исәпләшә.
Кара алтынга да бәйле
Җирдә сугышларсыз яшәү!
Җир шарының үзәгенә
юллар салдылар алар.
Девон көчен йөрәк җылысына
ялгый алдылар алар!

Мең рәхмәткә лаеклылар
кара алтын табучылар –
ил бәхете китабына
сүнмәс сүзләр язучылар!
Җир шарының үзәгенә
юллар салдылар алар.
Девон көчен йөрәк җылысына
ялгый алдылар алар!

## УРАМНАН РЕПОРТАЖ

Мин Әлмәт буйлап йөримен...
Бәлки, бу бер чит-ят илдер?!
Төрле төстәге флаглар –
язгы җилдә җилфер-җилфер!

«Все флаги в гости будут к нам»
дип язган Пушкин кайчандыр.
Бу сүзләр бүген Әлмәттә
һичшиксез раска чыккандыр.

Алты-җиде баш хәрефле
аббревиатуралардан
баш әйләнә, аңламыймын:
– Хәсәныч! – дим, – күрсәт ярдәм.

Дусым миңа ачып сала
баш хәрефләрнең мәгънәсен –
бик кирәкле оешмалар,
файдалы икән һәммәсе!

– Хәсәныч, – дим, – кайда Чупай
ташыннан салынган урам?
Ул көзгеләнгән урамнан
миңа карап көлеп тора.

– Чупай күптән үз бурычын

үтәде өйләр каршында,
хәзер ул матур иттереп
гаражлар сала ташыннан...

Олпатлыкта калышса да
башкалалардан ул әз-мәз,
Әлмәт күптән Әлмәт инде –
дөньякүләм данлы мәркәз!

## ТЫЕЛГАН СҮЗ

Ике миллиард бәйрәменә
ил Әлмәткә җыелды.
Орден, медаль... Әйтерсең лә
күктән йолдыз коелды.

Сүз алды Госплан-Байбаков...
Без көттек дежур котлау...
Ул сафсаталарсыз гына
әйтте һәр сүзгә туктап:

– Сугыштан соңгы елларның
илкүләм төзелеше –
цензураны бозып әйтәм –
Татарстан нефте эше;

сугышта илебез алган
яраларны беләбез –
илне дәваладык фәкать
сезнең нефть белән без;

илне космоска чыгарган
ракеталар – нефтьтән;
сезсез горурлана алмас
ни киләчәк, ни үткән!..

Зал тулы орден-медальнең
чыңлавын йотты тынлык...
Беравыктан искә килеп,
кул чабарга тотындык...

Шулай дөньяга таралды
йозаклап тыелган сүз...
Ә бүген мәһабәт һәйкәл –
нефтьтән коелган сүз.

# БАКЫЙ УРМАНЧЕ ТАШЛАРЫ

## УРМАНЧЕ КҮЗЛӘРЕ

Күзлек пыяласын тишеп чыгып,
күзләренең ачык күк төсе
якын йолдыз булып сирпи иде
тылсым тулы серле яктысын.

Уйнаклык һәм чак-чак ирония,
җылылык һәм кырыс катылык
әзер иде күзләр галәменнән
бире чыгар өчен атылып.

Назлылыгы сүзсез аңлашыла,
үткерлеге тора күренеп…
Ләкин кайчак чатнап китә иде
үкенечнең утлы сөреме…

Җан-җиһанга кайчак килә минем
аның күзе белән карыйсым…
Һәм йөгерәм аның музеена!
Аны эзләп кая барыйм соң?..

## УРМАНЧЕ КУЛЫ

Кул бирешеп исәнләшкән чакта,
күзләремә чәнчеп күзләрен,
кыса иде учны,
керфек какмый
карап тора сынап: түзәрме?!

Мин дә кысам башка чара юктан,
белгән догаларым кабатлап.
Тураялар ләкин бармакларым
эскәнҗәгә эләккән кадактай.

Сиксән яшьлек күзләрендә – алкыш!
Елмая да белә иде соң –
әйтерсең ул Җиргә электрлы
балкыш биргән Томас Эдисон!

Һәм елмаю катыш әйтә иде:
тоттыңмы – кыс,
кыскач, тор каты –
кәкре язмышны мин шулай итеп
шыгырдатып тотып турайттым...

## «КОЛ ГАЛИ»

Баш түгелдер моның, таштыр, диеп,
күпме кимсетәбез ташны без.
Зиратларга барып, шундый ташны
күз яшебез белән ашлыйбыз.

Таш бәгырьле, дибез...
Бәгырь һәм таш
ничек бер үк була ала соң?!
Бәгырь шаша мондый охшашлыктан,
таш күтәрә бәгырь яласын.

Таш ул җанлы.
Таш фәһемле-аңлы!
Тылсымлы кул гына кагылсын –
ул Мәрҗани, Тукай, Сәйдәш була,
сөйли илнең шатлык-кайгысын...

Кол Галигә кара – утлы тарих,
җәя итеп, уен киергән!
Әле булса мәрмәр яңагында
уйнап тора тере төерләр.

## «МӘРҖАНИ»

Шиһаб хәзрәт, нинди тирән уйлар
дулкынлана чалмаң астында?
Мин «җилкәнен киргән кораб» булдым,
балкышыңа кереп бастым да.

Син күрмисең мине. Уйларыңның
чоңгыллары сине йоткандыр...
Якынлаша алмыйм өметемә –
җилкәнемнениләр еккандыр?..

Мин бу җайсыз ярга берекмәскә
тиеш идем! Нигә беректем?
Җавабың бар! Ләкин сине ничек
мин Пигмальон булып тереltим?..

## «ТУКАЙ»

*(Кырлайда)*

Эскәмияң озын булмаса да,
тагын берәү өчен урын бар.
Кемне көтәсең син Кырлаеңда?
Уйлыйм менә шуның турында.

Әңгәмәдәш булыр идек сиңа...
Мохтаҗ түгел татар кыстауга,
буш урында ләкин пальтоң ята,
язмыш авырлыгы постаудан.

Уйда гына аңа кагылабыз,
хәтта карыйбыз да этәреп,
ә пальтоңны авыштырып булмый,
бездә көч юк моңа җитәрлек...

Һаман урын биләп яткан пальтоң
тын тисә дә үзе кузгала,
әгәр чыга алса шигыреңнән
Зәйтүнәкәй дигән кыз бала...

## «ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ»

Күзләреңә синең кереп була...
Үзгә дөнья анда...
Чакыра!..
Күз нурымны күз караңа терәп,
синнән йотылмыйча чак торам.

Табигатьнең мин дә бер баласы.
Ярыш дәрте кинәт тияр дә,
чамамны да белми кунаклармын
аеллары өзек ияргә.

Үзең кебек!
Син дә шундый җилдең!
Тик белмәдең нәрсә киләсен –
Алмачуарыңдай, иң беренче

бәйгедә үк
җиңеп
үләсен...

## «СӨЕМБИКӘ»

Нугай кызы моңлы Сөембикә!
Татар казанында кайнап та
язмышыңның синең ак-пакь сөте
әйләнмичә калды каймакка.

Казан ауганчы ук түгелде сөт
һәм агымга каршы агылды...
Динен, исмен алыштырды улың,
түшәгеңә хаин кагылды...

Патшаларны бәхет көтеп тормый,
хатыннарын инде – бигрәк тә...
Синең язмыш безне әле булса
бик күп нәрсәләргә өйрәтә...

Тәхетемне саклый белмәдең шул!..
Ялгамадың никтер ялгыйсын...
Тарих аша, мине кызганыпмы,
күз күтәреп карый алмыйсың.

Күтәр күзең! Сине гаепләү юк!
Керфекләрең утлы сөңгедәй –
тәнне тишеп, минем кайнар канны
салкын заманага сеңдерә.

## «МУСА ҖӘЛИЛ»

Йолдыз булалмыйча калган булса
дәфтәрләрең, илгә кайтмыйча,
«ил дошманы» дигән яманатны
мәңгелеккә кире какмыйча,

син мәрмәргә яки бронзага
әверелә алыр идеңме?
Куеп кулым, мәрмәр күкрәгеңә
утлы сорау белән тидем мин...

Таш эченнән йөрәк җавап бирде...
Сүзсез генә... Һәм мин төшендем –
башын чабып үтерепләр булмый
шагыйрь дигән бөек Кешене!..

Ирешмәсә илгә шигырьләре?
Архивларны тарих актарыр!..
Ни кызганыч, җырдан кадерлерәк
була кайчак үлем карары...

## «КАЮМ НАСЫЙРИ»

Геродот та сукыр булган диләр...
Бәлки, дөрес, бәлки, ялгыштыр...
Күзле күрә су агышын гына,

сукыр күрә Вакыт агышын.

Сукыр Каюм дисәләр дә сине,
үтә үткер булган бер күзең...
Ансы белән су агышын күрсәң,
икенчесе белән – сүз эзен...

Борынгыдан бүгенгегә җиткән,
киләчәккә таба юл алган
татар сүзләренә, фикеренә
булгансың син туры юламан!

Татарларны урыс телле итеп,
урысларны татар теленә
тарткан тарих юлы маңгаеңда,
таш булса да, ачык беленә...

## «ФАТИХ ӘМИРХАН»

Татар белән узышырга чыгып,
син алгарак китеп карадың.
Пенснеңне мин дә алып кидем,
һәм ни гаҗәп, миңа ярады!

Бездән алда, ай-һай, халыклар күп!
Андый тизлек кайдан алганнар?!
Әллә инде без татарда гына
«Без – иң алда!» дигән ялган бар?!

Мә, үзеңә булсын пенснең дә,
мәрмәр борыныңны шатландыр...
Минекенә – бүгенгемне күргән
диоптрий менеп атланды.

Синең төшкә кергән биеклекләр
безнең өчен баскан баскычтыр...
Халык азат диләр, ләкин милләт
һаман эзли йозак ачкычын...

## «ГАБДУЛЛА КАРИЕВ»

Театрга нигә татар кирәк,
ә татарга нигә театр?..
Гадидән дә гади бу сораулар
бүген, бәлки, көлке уятыр...

Бу сорауны ул үзенә биргән,
татар театрының атасы...
Көлкедерме, түгелдерме, ләкин
җаваплары аның хатасыз.

Тормыш – театр, дип әйткән кемдер,
артист роле – һәрбер кешегә...
Һәрбер халык үзенең язмышын
уйнап караганда төшенә.

Гомер бакый җитди булды татар
тарих куып керткән кысада...

Шәт, бүген без уйнап карыйбыздыр
бераз гына соңлап булса да...

## «ДӘРДЕМӘНД»

Кая китте синең алтыннарың?
Кемнәр беләгендә беләзек?
Кемнәр кесәсенә нәрсә булып
ягылганын бераз беләбез.

Кемнәр авызына үткер тешләр
булып тезелгәндер затлы ком...
Бәлки, шулар хәтта исемеңне
чәйнәргә дип торды атлыгып...

Чәйнәделәр... Йота алмадылар –
шигырь һәрчак зуррак алтыннан...
Алтыныңны син режимга бирдең,
шигырьләреңне бирдең халкыңа.

Алтыныңнан сының кояр идем,
син бүгенгә фәкать гипстан...
Кара алтын бездә диңгез-диңгез,
шуны «саргайтырга» юк оста...

## «ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ»

Ул Иблиснең чакыруын алган...
Ә белмәгән кая барасын...
Күңел дөньясына төбәгән ул
күзләренең уйлы карашын.

Күңел дөньясында ыгы-зыгы,
туганына туган ут ата...
Кайда барып сыгыну хәерле?
Ни хакыйкать илдә? Ни хата?

«Үз илеңнән син вәкил бул...» дигән...
Мондый тәкъдимне ул көтмәгән,
чөнки вәкаләтләр бирерлек ил
ул чакларда туып җитмәгән...

Бөек күчеш хөкем сөргән вакыт
фани дөньяда да, аңда да...
Аллаһ белән Иблис арасында
иң әүвәле шагыйрь алдана...

## «ШАМИЛ УСМАНОВ»

«Мин – шпион, «халык дошманы» мин...»
Ул каләмен манган карага...
Һәм бар көчкә үткер корыч белән
сул күзенә китереп кадаган.

Һәм миенә кадәр үтеп кергән
җан назларлык сүзләр язасы
корыч каләм... Йа Ходаем, алда
мондый язмыш илгә язмасын!..

Кул куймаган ялган кәгазьләргә –
үз-үзенә яла якмаган!
Һәм, гомерен шулай корбан итеп,
меңнәр киләчәген яклаган.

Заман гөнаһысын кадаклап ул
үз миенә, халык аңына,
язучының каләм карасын да
тиң иттергән шәһит канына...

«САГЫШ»

Җир өстенә бәреп чыгып, тамыр
фани дөнья хәлен күргән дә,
хисе, кайнап чыгып, әверелгән
ерым, төер, үзән, үрләргә...

Шул хәлендә аны Оста күргән...
Тамыр хисе, йогып Остага,
иҗат көчен аның тугарылып,
дулап карарга бер кыстаган.

Һәм тотынган Оста кырык гамен
сиксән якка ташлап-таратып...
Пәйда булган ниндидер кыяфәт –
әллә Нәфрәт, әллә Ярату...

Әллә бөек Борчылу микән ул,
язмышының күреп ялгышын?..
Бәлки, тирән ую кирәкмидер –
тирән уйның төбе сагышлы...

«ЯЗГЫ МОҢ»

Курай тавышына шүрәлеләр
җыела торган булган кайчандыр...
Соңгысы да күптән урманына
мәңге чыкмаска дип качкандыр.

Язгы моңның сынга әйләнүен
карап торып шаклар каттым мин,
әйтерсең лә курай тылсымыннан
бала чакларыма кайттым мин!

Сылу кызның нәфис бармаклары
тибри башларлар күк бераздан...
Мин дә онытылган яшьлегемә
якынлаштым бугай бер язга...

Агач түгел, юк, юк, агач түгел –
җанлы,тәмле тәнле, уйлы сын...
Яшьлегемә кайтып, бу сын белән
кети-кети килә уйныйсым.

УРМАНЧЕ ТЕЗЛӘРЕ

Бакый Урманченың Казмада* да
байтак калды таяк эзләре…

Ул елларда инде йомшак иде
сөрген дымы сеңгән тезләре…

Ул Казмада таба иде бугай
кара мунчаларның файдасын…
Ак мунча да яга иде әти –
ошаганын үзе сайласын.

Ул карасын сайлый. Кызган ташлар,
тамчы тисә, шартлап ярыла...
Тезләрен ул карт кычыткан белән
чаба иде хәле барында.

– Соловкины баштан, кулларымнан,
хәтта йөрәктән дә чыгардым,
ә тезләрдә сызлый, – дия иде, –
горур булсаң гына чыдарлык…

Шуның өчен дә мин, – дия иде, –
сарыф итә-итә күз явын,
ташны чокып, бүрәнәне уеп,
Горурлыкка һәйкәл куямын…

# Сонетлар

ҮЗГӘРЕШЛӘР СОНЕТЫ

Үзгәрешләр генә, үзгәрешләр
күрсәтәләр Вакыт агышларын.
Ә кешедә – мәңге бетмәс эшләр:
югалтуын барлый, табышларын...

Кышның язга авышканын күрә,
бозның елап үлүенә карап...
Җәйләр уза... Сары җилләр өрә,
Җир шарының бәсле чәчен тарап.

Ә йөрәктә елның фасыллары
юкка чыга, эреп кайнар канда...
Һәм күрәләр шагыйрь асыллары:
Сөю дигән фасыл гына анда!

Шул фасылда асыл шагыйрь эри –
үз канында үзе агып йөри...

*27 февраль, 2005*

ЧИКСЕЗЛЕК СОНЕТЫ

Чиксезлек һәм Хыял гына чиксез.
Хисләр чикле. Чикле уйлар да!..
Хыял гына ярый тышау-биксез –
чиксезлекне аңа буйларга.

Аны олы шартлау итәмен дә
чиксезлеккә чәчрәп таралам...
Һәм сизәмен: балкып, аң-тәнемдә
галәм зурлык Ана ярала,

күкрәк бирә, сораганны көтми...
Бу – акылдан шашу димәгез.
Без, шагыйрьләр, шулай – Җирдән китми –
чиксезлекнең сөтен имәбез.

Безнең телдә шуңа чит сүзлек –
җаныбызда чөнки чиксезлек.

*1 март, 2005*

## РЕФОРМАЛАР СОНЕТЫ

Яз түгелдер... Язга әле ерак.
Җылы дулкын килде кайдандыр...
Могҗизаңны күптән көтеп торам –
Җирне, Аллаһ, тизрәк әйләндер,

ил аркасын кояш җылысына
тизрәк ура, озак чыгарма...
Кала яздык утсыз учак сыман,
куәт тә юк артык чыдарга.

Могҗизаңның үзәгенә керт тә
аччы тыныч күчеш серләрен.
Реформалар канын сөртә-сөртә,
ничә буын инде керләнде!

Юа алмый керне ташулар,
Һәр су ташу – бәхет башына...

*19 март, 2005*

## ҖАВАБЫ ЮК СОРАУ СОНЕТЫ

Тән туа да үлә... Ә җан кала...
Ул үлемсез рухтыр, күрәсең.
Җанны, димәк, башка нәрсә ала!
Нәрсә икән? Ничек беләсе?

Чиксез Галәм микән? Бер йолдызмы?
Берәр көмәндәге баламы?
Аллаһ каршында, аһ, әхлак боздым –
сорауларны кире аламын...

Кире алып буламы соң аны?
Сорау бит ул уебызның җаны...
Җавабы юк сорау – үлемсез!

Җан һәм Сорау әллә тиңдәшләрме?
Гареш төбендәге бу эшләрне
аңлый калсак, булыр... күңелсез.

*19 март, 2005*

## ХАТА ҺӘМ ИГЕЛЕК СОНЕТЫ

Кем ясады Җирдә иң зур хатаны?
Кайсы илдә, нинди телдә, гасырда?
Җавап эзләп, әле дә баш ватамын...
Һәм бөекләр күз алдыма бастылар.

Мөхәммәдме? Иисусмы? Буддамы?
Адәм? Ленин? Чыңгыз ханмы?.. Әле дә
бар кешелек, ниятендә буталып,
бәхетенә юл табалмый һәр илдә!..

Ә кем кылды Җирдә иң зур игелек?
Шул ук затлар искә төшә иң элек,
чөнки алар – планетар аң үзәге.

Бу сорауны күп буыннар кабатлар.
Нигә кирәк соң сорауга җаваплар?
Әллә дөнья берәр фетнә сизәме?..

*23 март, 2005*

## ТУЛГАН АЙ СОНЕТЫ

Ай тулышты төн нурыннан, өрелеп...
Ераклашты вак йолдызлар аңардан...
Ярканатлар канат җәйде иренеп
һәм киттеләр күктән хаклык дауларга.

Лунатиклар, буйсынып нур-әмергә,
уяу төшләр дөньясына чыктылар.
Һәм алар да очышларга әзерләр...
Ә мәләкләр айный алмый йоклыйлар.

Үзе шомлы, үзе серле яктылык,
гаҗәеп үз һәм коточкыч ят булып,
үле күздәй карап тора күшегеп,

аннары соң сеңә башлый сүзләргә,
аларның да җылылыгын үзгәртә...
Кеше тизрәк яба йөрәк ишеген...

*23 март, 2005*

## КӨН ҺӘМ ТӨН ТИГЕЗЛӘШҮ СОНЕТЫ

Күкрәген Җир яктыгарак бора...
Таңнан төнгә шәүләм сузам да
кояш сәгатедәй басып торам
көн белән төн тигез ызанда.

Бүген Җиргә инде язгы хаклык –
ак төс белән кара балансы!
«Гадел» кояш ләкин көннәр яклы –
куш минутлар көнгә ялгансын!..

Ә күз күне күзге хаклык килә.
Ул чакта да кояш эшне белә –
көн вакытын төнгә имезә!..

Күңел тынычлыгы бизмәнемнең
берәр кылын, ахры, өзгәнмендер –
ике «мин»не булмый тигезләп...

*5–7 апрель, 2005*

## КҮЛӘГӘ СОНЕТЫ

Тәңре кырын кичкән болытларның
җир өстеннән шуган күләгәсен
мин туктатып тормак булып карыйм,
миннән узгач... Көчсез ләкин әфсен...

Күләгәдә калган урман, дала
кайгы-хәсрәт күмгән күңел төсле.
Шул вакытка җанда сут туктала,
җирдә – чәчәк, тәндә күңел үсми.

Күләгәдә яшәп караган бар,
йөрәгемдә кояш йөртсәм дә мин!
Бу шигырь дә шунда яралгандыр...

Ләкин Җил бар – мәләк хәрәкәте!
Һәм мин эчәм терек нуры тәмен –
күктән иңгән дога бәрәкәтен...

*17 июль, 2005*

## ПЛЕТЦЕНЗЕЕ СОНЕТЫ

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла...

*Муса Җәлил*

Башлар чапкан балта урман кисми,
агач юнмый, бура бурамый...
Сап булырга аңа агач үсми –
сөйми агач палач коралын...

Балтага сап була кеше кулы!..
Шул үтергеч итә корычны.
Җырны өзгән һәрбер корыч улы
шагыйрь каршысында бурычлы.

Бу балтада, абау, шигырь каны –
аңа төшкән корыч үткене!..
Һәм агыла Җиргә каләм җаны,
шаңдавына кушып Күк өнен:

«Җыр туа да үлми, димәгез...
Шагыйрьләрегезгә тимәгез!»

*20 август, 2005*

## МАЯКСЫЗЛЫК СОНЕТЫ

Ходай безгә гомер юлы бирә,
маяк-фәлән куеп тормыйча...

Әллә кая аяк алып керә,
әллә кая таба уй оча...

Күзне бәйләп, безне кемдер йөртә –
үз адымын бирә аякка,
сүзгә әллә нинди бәлзәм сөртә,
әйләндерә хисне таякка...

Гөнаһларга батып бетәбез дә
тырышабыз өскә калкырга...
Анда Иблис керә безнең күзгә –
якты маяк булып ялтырап...

Чын маяк та бар бит! Ул кайда?
Ә үпкәләп булмый Ходайга!..

*23 декабрь, 2005*

## ШИКЛӘНҮЛӘР СОНЕТЫ

Көчле микән рухым? Үзем белмим.
Сынамады бугай беркем дә...
Мин үземне һич тә эзләмимен
баһадирлар йөргән төркемдә.

Ымсынулар, көнләшүләр көче
кайларгадыр тартып карады.
Сынау булды микән бу рух өчен?
Тарткан якка никтер бармадым.

Бәлки, курку гына булгандыр ул –
рух дигәннең боламыклыгы...
Ә шик салып җанны уйландыру
күрсәтмиме рухның ныклыгын?..

Шикләнергә гаҗәп яратам,
җиңәм аны чөнки, таратам...

*24 декабрь, 2005*

## ЙОМШАК ТӘРТИП СОНЕТЫ

Без әле урлап туймадык,
гәрчә карак булмасак та.
Тыштан канун, әдәп саклап,
нәфесебезне тыймадык.

«Бай ил ул – бай кешеләр» дип,
без халыкны ышандырдык.
Һәм баюга план кордык,
урнаштырдык йомшак тәртип.

Кыйпылчык алырга таштан
чокчынасың тирләп-тирләп...
Мамыктан була җеп эрләп –
чеметкәләп бертоташтан...

Урлап булмый үзеңнекен...
Безнең илебез кемнеке?

*28 декабрь, 2005*

## ПУШКИН СЕРЕ СОНЕТЫ

Пушкин умер в полном развитии
своих сил и бесспорно унёс с собою
в гроб некоторую великую тайну.
И вот мы теперь без него эту тайну
разгадываем.
*Фёдор Достоевский*

Син нинди сер алып киттең анда –
агач тамырлары арасына?..
Шушы сорау, Пушкин, яна канда...
Синең кургаш миндә эри сыман.

Һәр шагыйрьнең, әлбәт, була сере,
йә нәфрәтләре зуррак, йә сөюе,
Яки үкенечле бер көенү...
Серле шагыйрь гомер бакый тере!..

Ачылган сер – ачык сандык кебек –
теләгәнчә актар, тикшер түбен.
Күз туйдымы – күңел гамьсезләнә...

Синең кургаш белән минем каләм
арасына сыйган чиксез галәм
уртасында ул сер... Мин эзләнәм...

*3 март, 2007*

## АВАЗ СОНЕТЫ

Бер-беренә берегергә әзер торган
авазларга нинди серле җилем кирәк?!
Аны җанда буранлаган хаос-буран,
канга сеңгән хәтер эретмәсе бирә!

Оеша Сүз! Туу – Үлем аралыгын
төгәл дөнья итеп туплый, оештыра
һәм аңлата бу дөньяның яралуын,
һәр яңага милли исем биреп тора.

Бер-беренә сискәнешеп берегергә
әзер сүзләр ялганалар нәрсә аша?
Андый җилем җанны милли итеп үргән
язмышыбыз каны дымында укмаша.

Канның дымы халык тынына тоташтыр!
Һәрбер аваз халык тыны өчен аштыр!

## ИХЛАСЛЫК СОНЕТЫ

Мәкерле бәхәскә тартма –
ачтырма ачу ишеген,
анда керпе сырт кабарткан –
сөңге урманы ише гел!

Нужарма баллы телләнеп,

мин балга да, җилемгә дә
кунакларга һич теләмим
хәтта ахыр чигемдә дә.

Ләкин кирәк икән нидер,
әйт турысын – ихлас бул син,
намусыңа җаның тидер.

Ихласлык иң бөек тылсым –
ул илаһи көчкә тиңдер.
Шул тылсым юлдашың булсын!

*26 февраль, 2007*

## ҖӘЛИЛ КАНЫ ТУРЫНДА СОНЕТ

Һәр августның мин егерме бише көнне,
хәтер кошы булып очып җыр артыннан,
җан сәгате суккан чакта уникене,
Җәлилнең баш каны тамган ташка кунам...

Һәр февральнең унбишенче якты таңы
илһам дәрте өстәр әле диеп, юрап,
канатланып, мин Мусаның кендек каны
тамган изге тарафларны кайтам урап...

Һәм горурлык хисе миндә чиктән аша –
ул шагыйрьнең шәһит канына тоташа,
батырлыкка матурлык кушылган кебек;

ул ялгана Мусаның кендек канына –
йөрәгемдә мәхәббәт булып кабына!
Һәм яшимен үз халкымның күзен үбеп!

*Август, 2006*

## АНЫҢ КҮЗЛӘРЕ ТУРЫНДА СОНЕТ

Кем ул безгә кояш-күзе белән
карап тора икән көндезен?
Җаным аны, ахры, яхшы белә...
Беләм микән аны мин үзем?

Мин чамалыйм гына... Ләкин чамам
мин белмәгән Аңнан туена...
Ә төннәрен яңа утта янам,
салкын суда гүя коенам –

Ай-күз нуры җанга сихәт яга,
пакьлек иңә сүзем, кулыма...
Ай батмаган, кояш калыкмаган
чиктә күп чак гөнаһ кылына...

Һәр төштә бар ул күзләрнең нуры.
Барлык почмак нурлар өчен туры!

## АК КӘГАЗЬ СОНЕТЫ

Ак кәгазьнең эчке чиксезлеген

кем ишетә, ә кем күрә дә!..
Әллә кая барып юк эзлисе –
кәгазь эчендә ул, тирәндә...

Булдыралсаң – көй-җыр тартып чыгар,
булдыралсаң – төсләр саркыт син.
Тышкарысы нәрсәгә дә чыдар,
эчкәресен ләкин ярсыт син –

шигырь, рәсем, көй нотасы итеп
ак битенә беркет барысын –
һәр кемсәнең, исе-һушы китеп,
ишетәсе килсен, карыйсы...

Кәгазь чиксезлеге – тылсымчы...
Ә син – шагыйрь, җырчы һәм сынчы!

## КАЗМА ЗИРАТЫ СОНЕТЫ

Уйга батып, зират буйлап атлыйм...
Җан башларым монда күмелгән.
Пакьләнергә башка чара тапмыйм –
эчкәрегә аккан яшь белән.

Әни киткән чакта яз кояшы
төшкән иде салкын гүренә...
Һаман җылы аның кабер ташы –
чыкка яки бәскә төренә.

Әти киткән чакта көзге болыт
кабер диварларын чылатты.
Шул дым, тыштан күзләремә тулып,
йөрәгемә таба юл тапты.

Җанны юа бары күз яше.
Һәм җиһанда бу су – тиңдәшсез...

*8 март, 2008*

## КЁНИГСБЕРГ СОНЕТЫ

Мин сагынып бардым, килеп бастым,
Шиллер, синең һәйкәл төбенә.
Чәнчеп-чәнчеп алды күкрәк асты... –
сизәм – анда шигырь тибенә...

Яза алмый тордым аны никтер,
кәгазь-каләм кулда булса да...
Акылымда, белмим, нинди биктер,
тоткарлыйдыр нинди бусага.

Юк, каләмем минем күзекмәгән,
ләкин җаным ят бер калыпта –
туфрагыңны безгә үз итмәгән
Фатих Кәрим каны тамып та...

Өйгә кайткач туды бу шигырь,
туган туфрак җаны булышып...

*22 гыйнвар, 2009*

## АРАЛЫК СОНЕТЫ

Озынайды кебек метрлар...
Кыскардылар кебек минутлар...
Шуңа микән әллә мин утта?
Ә җаныма бозлар утырган...

Юллар белән керфек арасы
якынайды... Ә юл томанда...
Гомер! Кая алып барасың?
Көтеп тора мине кем анда?

Җәннәт сакчысымы?.. Әлләме?..
Кайсы ачкан миңа ишеген?
Мин үкенмим, берни җәлләмим,

мин курыкмыйм, чөнки бар шигем...
Җәннәт – тәмуг аралыгында
тукталырга разый кеше мин...

*23 ноябрь, 2009*

## ТИЛЕ СОРАУ СОНЕТЫ

Мин үземә үзем яшьтәшме соң?
Нинди сорау? Нинди авыздан?
Гомеремне уйларымда кысып,
елларымның маен агызам.

Исем җисемемнән аерылмады,
адымыма адым ялганды.
Җиңел җиңүләргә яб(ы)рылмадым,
күтәралмас данга алданып.

Булганыннан акыллырак булып
мин тиештер, бәлки, яшәргә?!
Ә йөрәгем тилелекләр тулы,
һәм уйларым минем шәп-шәрә...

Бәхеттерме, бәхетсезлектерме –
мин үземә тиле сорау бирдем!

*29 ноябрь, 2009*

## ДОГА ТУРЫНДА СОНЕТ

Үз-үземә әйттем инде ничә:
нигә бер дә дога кылмыйсың –
кылган саен, диләр, җанга күчә
догаларның сихәт-тылсымы?!

Күңелемне тыңлыйм, йомып күзем:
нинди җавап аннан яңгырар?!
Ә җавап юк... Әллә инде үзем,
әллә инде күңел саңгырау?!

Әллә инде шулай ерагайган

үзем белән күңел арасы?!
Кыска юл барында, әллә кайдан
бәхеткә ник урап барасы?..

Җанда безнең дәвер ярасы!
Дәваларга бармы чарасы?

*2 февраль, 2010*

## ЯШЬ САНЫ СОНЕТЫ

Кем булганмын яралганга чаклы
бу галәмдә, нинди күзәнәк?
Шушы сорау белән мин кайчакны
иң илаһи сергә кизәнәм.

Бернәрсә дә бар булмаган юктан...
Чиксез үзгәрешләр чылбырын
башлаган соң кайда нинди нокта?
Һәм ул нокта матди-чындырмы?

Һәр атылган саен күктә яшен,
сорыйм тизрәк кешелекнең яшен...
Тик җавап юк Бөек Сердәштән...

Мин чамалыйм бугай яши-яши:
Идея һәм матдә берләшкән –
галәм белән кеше бер яшьтә!

*16 февраль, 2010*

## ЕЛАУ ТУРЫНДА СОНЕТ

Елау күңелне чистарта...
Елыйсылар килгән саен,
җан дәрьясында су арта,
җилкәнен күтәрә каек.

Керле дөнья артта кала,
син – сафлыкта һәм иректә!..
Син гүяки сабый бала,
сине хыялың йөретә.

Күз яшеңдәге каектан
тизрәк чыгу ягын кара –
күздә дә дәрья саега –

ташлар өскә калка бара,
сине хыялыңа илткән
каегыңның төбен яра...

*27 гыйнвар, 2010*

## ВАК-ТӨЯКЛЕК СОНЕТЫ

Нидер тота кош буласы килгәндә...
Җир тартуы гына түгел, әлбәттә.
Мин – мин түгел, ахры, һаман, ә бәндә –
үз-үземне җигә алмыйм һәйбәтләп...

Акыл көчем күтәрелгән үрләрнең
мин, асылда, итәгендә казынам,
һәм җанымның канатларын күралмыйм –
бата барам вак-төяклек базына.

Ә югыйсә атом-аң реакторы,
буш куәткә җанымда кайнап торып,
үземне үк эчемнән харап итә...

Ә гомерләр, сиздереп, сискәндереп,
юаткычлы рәхәт җилләргә төреп,
күзләремә битәрләп карап үтә...

*28 март, 2010*

## КАРАҢГЫЛЫК СОНЕТЫ

Яктылыкның үзәгендә кояш тора!
Караңгылык үзәгендә нинди җисем?
Кайчакларда күңелемне шушы сорау
бик хәвефле хәнҗәр булып китә кисеп.

Һәм мин эзлим караңгылык чыганагын.
Нигә эзлим? Ниемә ул минем кирәк?
Һәм кайдадыр үзәгемдә чыга янгын,
һәм сулкылдап үрсәләнә башлый йөрәк.

Мин кояшны күк йөзеннән сөртеп алам,
йолдыз, Айны офык артларына салам,
ә яктылык һаман-һаман күзгә керә.

Мин аптыраш чоңгылына тәмам чумам,
каш җыерам, теш кимерәм, күзем йомам
һәм... караңгылык үзәген шунда күрәм...

## ЯЛГЫШ ТИҢЛӘҮ СОНЕТЫ

Лалә гөлгә тиңли сине кемдер...
Лалә гөлләр көнгә ачыла.
Кояш нурларына әнә сеңде
төн серләрен җыйган тамчылар.

Син ачыла торган вакыт – төндер.
Төндә – тышаусызлык тылсымы!
Бәлки, җәннәт назларына тиңдер
шул тылсымга бергә буйсыну?!
Каршымыни мондый тиңләүгә мин?
Бу тиңләүдә – минем теләгем:
дәрт ялкыны дигән ут аша

синең көнең минем төнем белән,
минем көнем синең төнең белән,
һич югында, уйда тоташа...

## АҢЛАРГА ТЫРЫШУ СОНЕТЫ

Нәрсә соң без иксез-чиксез җиһанга?
Иксез-чиксез Вакытның без нәрсәсе?
Ни ачты соң анда шәфкать пәрдәсен –

Чирканумы һаман аккан чи каннан?

Кайдан иңгән безнең аңга каберләү?
Кайдан сеңгән күңелләргә кадерләү
Үлгәннәр йә тумаганнар кайгысын?
Җиһан өчен терерәк соң кайсысы?

Безгә җиһан – сораулардан хасил җөй,
Һәм без җөйне сүтә алмый йөдибез.
И Кеше, син башың и йә кашың чөй –
бар сорауны тудырабыз үзебез.

Без сорауга җавап булып туганбыз,
Вакыт белән бер үк ярга тулганбыз.

## Лирик пейзажлар

### КОДРӘТ ТАВЫШЫ

Болытларны җилләр куа.
Җилләрне кемнәр куа?
Болытлы елгага карап,
дулкынлы сорау туа.

Уйлар айкый күк гөмбәзен,
айкый сулар чоңгылын.
Әкияти хисләр күңелгә
урнашалар чын булып.

Әллә судан, әллә күктән
иңә кодрәт тавышы:
бар нәрсәне алга куа
бөек Вакыт агышы!..

### ТАРИХ ЕЛГАСЫ

Актарылып төшкән тамыр
су буйлап агып бара...
Нәрсә тамыры икән ул? –
чәнчелебрәк кара!

Кәүсәсез калган тамыр ул –
кешесез калган исем.
Миңа шундый бер уй килде.
Ә син аны ни дисең?

Ә елга да гади түгел –
Тарихтыр әле, баксаң...
Нишләр икән безнең исем,
вакыт дулкыны какса?..

### ИКЕ СЕР

Елга аңламый урманны –
ник шаулый да ник сайрый,

ник маңгай сырына охшаш
җыерчык баскан кайры?!

Урман аңламый елганы –
үз ярларын ник ашый,
ник бетми өзлексез суы,
ул аны кемгә ташый?

Ике бөек сер иясе
тора минем алдымда...
Алар миндә... Мин аларны
аңламыйм да, аңлыйм да...

## КҮЗ БУЯР ӨЧЕН

Көзләргә алып керәләр
сукмаклар безне кинәт,
гәрчә күңелнең мәңгелек
җәйдә каласы килә...

Үләннәр суты суынган,
гөлләрдә хуш ис беткән...
Шушымы, «Бәхет алда!» дип,
без зарыгыплар көткән?!

Шулар бәрабәренә көз,
күз буяр өчен генә,
алтын диеп бүләк итә
алтынның төсен генә...

## ДУЛКЫНЛАНА БЕЛМӘГӘЧ

Тынчу суларда – тынычлык.
Ләкин бу тынычлыкта
суның иң гүзәл сыйфаты
ята ваемсыз йоклап –

алга таба ашкынуы!
Ә бу теләк оюга,
суга чәчәк кебек матур,
тик хәтәр афәт йога.

Су әверелә баткакка –
хәшәрәт оясына,
дулкынлана белүләрен
оныткан күңел сыман...

## ГАЛӘМНЕҢ КҮЗ КАРАСЫ

Эңгер әле килә генә,
ә җил тынып өлгергән...
Һава да, су да шәмәхә
тылсым имә эңгердән.

Су куера, әйтерсең лә
гипнозлы күз карасы.
Шомлы суга тартыласың,
килмәсә дә барасы.

Куркуны җиңеп, керәсең
камышлар арасына,
тәвәккәллисең – чумасың
Галәм күз карасына.

## КЫЗЛАР СУ КЕРӘ

Елга таллар арасына
поскан җирдә, иркенләп,
кызлар су керә. Ә безнең
күзләр шунда береккән.

Беренче тапкыр кызларны
шулай күреп соклану!..
Беренче тапкыр хисләргә
кан тула дулкынланып...

Күзне уч белән каплыйсың...
Ләкин учлар пыяла...
Булган икән тиле чаклар –
хәтта күзләр оялган!..

## ЯШЕЛ ӨМЕТ

Көз – агачларның җитлеккән,
Сократ күк тирән чагы.
Ябалдашта – кара уйлар,
тамырда – уйның агы.

Һәм кәүсәдә тоташалар
өмет һәм өметсезлек...
Икесе дә бер үк төштә
яшәү дәвамы эзли.

Карлы уйга чума агач,
кыш буе уйда яши...
Язга чыккач сүзен әйтә –
сүз өмет кебек яшел.

## ТҮГӘРӘК КҮЛ

Гүзәл йөзгә дә кайвакыт
тылсымлы миң сер өсти.
Миң шикелле түгәрәк күл
ямьле итә җир өстен.

Суына карап торасың –
агач, гөлләр чагылган.
Зәңгәр казанында кайнап,
ап-ак таулар агыла.

Суга керсәң, шул тауларның
тотарсың кебек карын...
Судагы сурәт уята
балачак хыялларын...

## ХОДАЙ ЭЗЕНДӘГЕ СУ

Бер шук малай су эчкән дә
юлда кәҗә эзеннән,
кинәт кәҗә бәтиенә
әверелгән үзе дә.

Диңгезләр – убылган таулар...
Диңгез күргәч, туңкаеп
ятып тозлы су эчкәндә
Аюдаг булган аю.

Без, кешеләр, – илаһилар!
Бездән көчле тик Вакыт...
Әллә без Ходай эзеннән
су эчтек микән ятып?

## ТӘҖРИБӘ, ТӘҖРИБӘСЕЗЛЕК

Тәрәзәнең аръягында
Кыш дигән комсыз патша
безнең якның яшеллеген
бетергән инде ашап...

Бирге якта өй гөленең
әле дөнья күрмәгән
ботаклары, яктыга дип,
хәтәр якка үрләгән.

Яшәп-яшәп гыйбрәт алган
ботаклар, киресенчә,
афәттән котылмак булып,
кояшсыз нурлар эчә...

## МИЛӘШ ҺӘМ КЫРАУ

Һәр бөртеге тулы, шома,
йомры мәрҗәнгә тиңдәш.
Чәчәк белән ярышырлык
кырау тимәгән миләш.

Кызыгасың һәм өзәсең...
Тешлисең дә сытасың...
Ләкин килми матурлыкның
ямьсез тәмен йотасы.

Һәм беренче кырау төшә –
бөрешеп кала миләш.
Ә кыраулар тигән миләш
хәтта йөземгә көндәш.

## БАЛЫКЛАРГА ЯЛВАРЫЙК

Керфекләр саклый күзләрне,
урманнар – елгаларны.
Сөрү җирләре артсын дип,
күпме кистек аларны?!

Урманнар урынын алды
кукуруз басулары...
Төрле бик «файдалы» агу
агулады суларны.

Туфрак акты елгаларга,
котырды суүсемнәр...
Балыкларга ялварыйк без:
үсемнәрне киссеннәр...

## САЛКЫН УЧАКЛАР

Кояш кайчак якынлаша
кибән-кибән көртләргә.
Көртләр инде әзер кебек
ялкын булып дөртләргә.

Кулны җылытасы килә
карларның ялкынында...
Ләкин юлыгасың бары
табигать салкынына.

Күңелнең дә була шундый
үтә сәер чаклары –
кышкы кояш кебек матур,
тик салкын учаклары.

## СУГА ЕГЫЛГАН ТИРӘК

Су буенда тал-тирәк.
Күләгәсе су кәрә.
Тал-тирәк су-көзгедә,
ниһаять, үзен күрә.

Ул әнә нинди яшел!
Ул әнә нинди куе!
Болытларга тиярлек
булып үскән ич буе!

Ник бары күләгәсе?
Гәүдәсе дә теләде...
Көнчелек хакын тирәк
артык кыйммәт түләде...

## ӘЛСЕРӘГӘН КӨН

Эсселектән әлсерәгән
көн капланган елгага.
Тал ышыгына елышып,
куерган җилләр ага.

Ул да җылы – кояш нуры
суга тамып эрегән.
Тәнең дәрман ала алмас
бу суда су керүдән.

Җәй челләсе. Су күкләргә
күтәрә алсу рәшә.

Җан, үзе дә теләмәстән,
дөньяга көзне дәшә.

## КҮЛӘГӘ КАГЫЛУДАН ДА...

Җир җиләкләре җемелди
болыннар-тугайларда...
Чалгычылар керештеләр
чалгыларын кайрарга.

Күләгә кагылудан да
кузгала күбәләкләр,
әйтерсең лә куркып оча
аллы-гөлле чәчәкләр...

Болыннарда җиләк исе,
елгада балык исе...
Күңел сәрхушләнеп ала,
бутап эчкәч икесен...

## ИМӘН БОТАГЫНДА – КАРГА

Җылы якта сыерчыклар
чыкканнар инде юлга.
Кар сулары, сут булыйк дип,
уйсу җирләргә тулган.

Урманнар гына кыш белән
хушлашырга ашыкмый!
Әллә андагы каеннар
ак карларга гашыйкмы –

китәргә ашкынган карның
басканнар чабуына?!
Күрше имән ботагына
кара каргалар кунган...

## КЫРГЫЙ АЛМАГАЧ

Ничек килеп чыктың кырга?
Нигә монда төпләндең?
Шушыдыр,ахры, тормыштан
бәхет өмет иткәнең?

Син купшы да, син куе да –
барлык ботагың исән!..
Аларда тик балан зурлык
ачы алмалар үсә...

Күзәтәсең киңлекләрне,
син саф һава сулыйсың...
Сиңа карап килә никтер
бүре булып улыйсым...

## КАРА КӨЗ КАРАСЫ

Кичә кара торган җирләр

калды бүген кар астында...
Туйган иде инде күзләр
кара күзләр карасыннан.

Кичә кургаш кебек күкләр
җирдән якты иде күпкә.
Бүген инде җир яктырак –
күк калган хәтта аптырап...

Без, кешеләр, шаккатмыйбыз –
без күнеккән утка-суга,
безне Җир дә, Күк тә талкый,
аяз көнне яшен суга...

## КЕМ КҮЗЕ?

Җилләр сулап яшәгәндә,
йөрәктә дулкын тора:
мәхәббәт булып иркәли,
нәфрәт булып котыра,

агымга каршы куалый
уйларны, хыялларны,
хәтта искә дә төшертми
куркыныч кыяларны...

Вакыт еллар фасылына
бүленми генә ага...
Көзге дулкын арасыннан
кем күзе миңа бага?..

## КОЯШ БАЙЫЙ КЫЗАРЫП

Иртәгә буран булыр күк –
кояш байый кызарып...
Биш-алты кар бөртеге дә
бездә эшне бозарлык.

Иксез-чиксез илебездә
кыш күбрәк хөкем сөрә.
Кырыслыкка күнеп булмый
хөкем сөргәнгә күрә –

катырганга күрә канны,
сындырганга шартлатып...
Аһ! Кояш кызарып байый –
без торабыз шаккатып...

## ЗӨЯ ЯРЫНДА ТУДЫМ

Өянкеләр, өянкеләр,
тамырыгыз судамы?
Мин Зөя ярында тудым –
Зөя суының дымы,

каным тамырлары буйлап
вакытны ташый-ташый,
күңелемнең болыннарын

сугара, җимли, ашлый...

Тамырым судан курыкмый –
мин бит нәкъ синең кебек:
ябалдашым күкне капшый,
тамырым – дәрья төбен...

## СУНЫҢ ДАҺИ КӨЗГЕСЕ

Көнне җайлы кичкән өчен кояш
шатлыгыннан төсләр өләшә.
Алтын нурлар җыйган өянкедән
кичкә кергән елга көнләшә –

кояш нуры аңа калмый кебек,
китә кебек әллә кемнәргә!..
Ә суының даһи көзгесендә
тапкырлана һәр төс меңнәргә.

Көзге үзен ни күз белән күрсен?!
Ничек күрсен елга үз төсен?!
Даһилыгын белмәгән даһидай
даһилана елга көзгесе.

## ӘКИЯТЕМНЕ СЫНАМЫЙМ

Урман күленә чумсам мин
тапмамын кебек төбен
һәм Җирнең теге ягына
барып чыгармын кебек.

Юкса беләм: күлләр түгел,
хәтта диңгезләр төпле –
әкият яши хыялда
картаймыш көнгә тикле!

Алам көймә, керәм йөзеп
күлнең уртасына мин...
Ләкин чуммыйм – әкиятемнең
дөреслеген сынамыйм...

## КҮЗЛӘРЕМНӘН КЫЗГАНМА

Тизрәк чум да чык яныма,
алтын чәчле кыз бала!
Гәүдәңдәге тамчыларны
күзләремнән кызганма!

Һәм күлнең рәхәтле дымын
кызганма кочагымнан –
сөлгедәй урап киптерим
йөрәгем учагында.

Юк! Куркытуым ихтимал...
Туйганчы йөз... Мин китәм,
күзләрем мондый бәхетне
күрмәсә дә бик күптән...

## ШАГЫЙРЬ КӨЗ

Көз – гомернең иң бай чоры,
барлык нәрсә анда бар:
язгы ташкын, җәйге гөлләр,
алтын алма, кышкы кар!

Көз – кушымталы җыр кебек:
иң әүвәл уйландыра,
аннары йә суга сала,
йә утларда яндыра.

Көзләрне без юкка гына
сагышлы дибез, сүрән...
Көз шагыйрьләр күңеленә
бай шигырь булып керә.

## ҖЫРЧЫ КАРЛАР

Ыңгырашмыйм, сыкрамыйм да –
аңлый күрегез берүк, –
карым җыры менә шундый!
Ә җырлыйм күңел биреп.

Сагышларым үземнеке...
Үземнеке һәр көртем...
Мине башкача җырларга
өйрәтә алмый беркем.

Минем карым осталыкта
иң югары баскычта –
һәр кешене җырчы итә,
көртләремә баскач та...

## ВАЕМСЫЗ ҖӘЙ

Күңел җәйге елга кебек –
дулкынланмый, кымшанмый.
Шулай булып булуына
хәтта үзе ышанмый.

Ә югыйсә чоңгылларда
балыкны балык аулый,
һәм һавада керәшәләр
черки дәүләтен яулый...

Ә күңел җәйге елгадай –
һәм ваемсыз, һәм тыныч...
Керәшәләрне күрдем дә,
булып китте куркыныч...

## КАР БАСКАН ӨЙ

Кайчакларда мин кар баскан,
утлары сүндерелгән
өй итеп тоям үземне...
Һәм куямын дерелдәп.

Тәрәзәмне бәс каплаган –
керми дөнья яктысы...
Әллә ничек булып китә –
хәтта яшәү ят төсле...

Һәм ишекне кемдер кага...
Җаным куя дерелдәп...
Бер җылы сүз ишетәм дә
мин яңадан тереләм...

## ШАР ЭЧЕНДӘ УЧАК

Җир шары эчендә кемнәрдер
ут яга еракта-еракта –
җылына башлады җир өсте,
су төште кар тулы ермакка.

Талларның очлары кызарды,
сут алды каеннар кайрысын.
Егетнең дә килде, ниһаять,
бер кызга сүз катып карыйсы.

Ә төнгә кергәндә кар өсте
мең төрле төсләргә буянды...
Табигать һәрвакыт акыллы,
ә хәзер хисе дә уянды.

## ТУГАН ҖИРЕМ

Һәрбер чишмәң синең көй чыгара,
һәр инешең җырга әйләнгән.
Үләндәге һәрбер чык тамчысы
әверелә нурлы сәйләнгә.

Һәр сукмагың синең шигырь юлы,
зур күмәк хор һәрбер урманың –
гомер буе күрәм мин аларның
мәдхияләр җырлап торганын.

Алар – сиңа, сиңа, туган җирем!
Лаеклыга тиеш лаеклы!
Ничек кенә гасырлар юлында
саклап калыйк мондый байлыкны?!

## СОРЫ КӨН

Күренерлек болыт та юк,
ә һава никтер соры.
Кошлар үлеп сайрар вакыт,
ә кайда тургай җыры?!

Җил искәне дә сизелми,
суда юк сыңар шадра.
Керәшәләр дә күренми
кәрәздәй сары ярда.

Вакыт та тукталган кебек,

аптырап әллә нидән...
Торгынлык барлык нәрсәгә
сихере белән тигән...

## ТАШ ҖИТӘ

Тын суларның тынычлыгын
алыр өчен таш җитә...
Җанны дулкынлатыр өчен
бер сикергән каш җитә...

Кайнар комнан да кайнаррак
гашыйк кочак кызуы...
Суда – дулкын, җанда – ялкын
яшь гомернең узуы...

Тын суларның көзгесендә
чагыладыр бар җиһан...
Чалкан ятып күккә бакса,
күзендә мин чагылам...

## КАЛӘМДӘ КАРА ТУҢДЫ

Каен кайрысына кайнар
шигырь язасым килә –
җаным язларны өзелеп
көткәнен аңа сөйләп.

Кар астында умырзая
бөреләнә шикелле...
Ә бит вакыт кышка бара –
сау калуы икеле.

Тик шигырь яза алмадым –
каләмдә кара туңды...
Ләкин ут булды җанымның
язларны яратуы.

## БОЗ АСТЫНДА ҖӘЙ ТАВЫШЫ

...Ә өянке суга кереп бара,
кар өстенә яфрак сибәләп...
Җәйнең эссесеннән кача идек,
ышыгына аның килгәләп.

Ботаклары суга тигән иде –
балык тота диеп уйларсың.
Йөзеп килеп аңа каба иде
ап-ак казлар койган кавырсын.

Хәзер инде бөтен елга ап-ак.
Боз астында аның агышы...
Ә өянке ярдан суга атлый,
ишеткәнгә җәйләр тавышын...

## ГАЛӘМИ ХӘТЕР

Су ул – Җир шарының мие!
Суда галәми хәтер!
Сөйләшә белеп сөйләшсәң,
яралмыш серен әйтер:

җанның барлыкка килүен
һәм хәрәкәтен аңның,
Җир шары йөзен үзгәрткән
бөек афәтләр санын...

Каргарга ярамый суны,
ярамый рәнҗетергә –
һәр сулу саен ул дару
йә агу булып керә...

## ТУКАЙ БАКЧАСЫНДА

Гаиләсенә җиһанның
ник китердең ят кеше?
*Габдулла Тукай*

Тукай бакчасында кар сибәли,
вак һәм җылы – яңа он сыман...
Тегермәнче кебек, телгә салып,
әвәләргә хәтта ымсынам.

Ә кар эри керфегемә тиеп –
төшкән чагында ук чыланган...
Әллә ул да нәни Тукай кебек
ят булганмы чиксез җиһанга?..

Тукай бакчасында кар сибәли...
Ак япмада тора бар агач...
Әллә нишли күңел, керфектәге
тамчы аша күккә карагач...

## КӨМЕШ ПАРЧА ЮРГАН

Кичә генә кара-көрән җирләр
көмеш парча юрган ябынды,
ә парчаның барлык җепләрендә
миллион сәйлән лампа кабынды.

Җан җылысын югалтмаган елга
ак ярларга карый аптырап –
алар көмеш төсле чабаклардан,
судаклардан күпкә яктырак!

Ялтыравык һәрнәрсәгә гашыйк
саесканны гына карагыз –
көмеш Җирне урламакчы тизрәк!
Көче җитми – тора чарасыз...

## ТӨСЛЕ КАРЛАР

«Ак кар» дип башлап, шигырьне
«ал кар» дип дәвам итәм.
Күзне ачыбырак баксам,

ал карым зәңгәр икән.

Зәңгәр – иң яраткан төсем,
зәңгәргәдер күзләрем.
Күз алдында зәңгәр карым
шәмәхәгә үзгәрде.

Офык артларына чумды
рәссам кояш – югалды...
Карым, шатлыктан арыган
күңелдәй, төссез калды.

## ОЯЛЧАН ИНЕШ

Оялчан инешләр була –
агалар яшеренеп,
ярларында шаулап үскән
таллыкларга төренеп.

Сулары бик сай булудан
инешләр ояладыр...
Бәлки, алар яшерәдер
сандугач ояларын!

Таңда алар тынып тыңлый
сандугач чут-чутларын...
Оялчан инешләр алар –
сандугач сөйгән яры.

## ШӘРӘ ТАЛЛАР

Яфрак шавын тыңлап сокланамын –
тормыш җыры өмет кабыза...
Ә бу таллар яшел яфракларын
дулкыннарга сибеп агызган.

Таллар белән, алар шәрә калгач,
сөйләшергә тели күңелем.
Моңлы чакта алар юмарт бирә
гасырлардан килгән гыйлемне.

Тиздән елга бозга камалачак,
тал суты да туктап калачак...
Икесе дә, тормыш җыры итеп,
язлар шавын каршы алачак.

## ӘЗЕРЛӘНҮ

Су төбендә алтын кәрәкәләр
кереп чумган җылы дуенга.
Күл өстендә йөзгән яфраклар да
яр читенә килеп сыенган.

Күл өстеннән төнлә исеп үтте
көзге җилнең шадра хәбәре.
Җәе буе ләззәт эчкән дөнья
уйлап куйды шунда хәтәрне.

Бөтен нәрсә әзерләнә кебек
адым атларга дип чик аша...
Һәм күңел дә Җирнең әйләнеше
тизлегенә ныграк тоташа...

## ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Шулчаклы көмеш пәрәвез!..
Кайдан килә икән ул?
Әллә аны бушлай гына
җибәрәме бүтән ил –

бездән бераз хәллерәге,
юмартлыкта узганы?
Ни булса да, хәерлегә
булсын безне кызгану...

Без дә бай! Без күнекмәгән
бүләк алырга бушка –
әзерлибез җибәрергә
башка илләргә кошлар!..

## КҮЛ БУЕНДА УЧАК ЭЗЕ

Күл буенда – учак эзе.
Кемнәр яндырды икән?
Бәлки, төркемдер, ә бәлки,
пар каен кебек икәү?

Учакның уты чәй генә
кайнатып калды микән?
Әллә бөтен кайнарлыгын
кочакка салды микән?

Әллә очкыннар сүндеме
суга төшеп кочактан?
Күпме генә тырышсам да,
сер чыкмады учактан...

## ҖИЛӘС ТАҢ

Җәйләрнең дә шундый чагы була –
суларына чыга каз тәне.
Таллар, камышларны бизгәк суга,
әйтерсең лә алар хасталы.

Вертолёттай энәкараклары,
күбәләкләр әле ангарда –
моторында майлары суынган.
Кояш нуры көтә алар да.

Менә җайлап кояш күтәрелә,
су шомара нурлар назыннан...
Кичәге җәй кабат безне били,
сискәндереп алгач аз гына.

## КИСЕЛГӘН ЧӘЧӘКЛӘР

Кызганмагыз өзелгән дип,
уфтанмагыз сула дип –
без дөньяда яшәп калдык
шаулатып һәм дулатып.

Кешеләрнең бәйрәменә
төсебезне өстәдек –
бизәп тордык нурлы туйлар,
туган көннәр өстәлен...

Матурлыкмы коткаручан?
Кем әйтә шулай диеп? –
Матур чәчәкләр иртәрәк
үлә, пычакка тиеп...

## ҖИЛ ӨРДЕ

Салкын иртә...
Салкын су...
Йөрәгем дә
ялкынсыз...

Бикле күңел
ишегем –
утырамын
күшегеп.

Сайрады кош...
Җил өрде...
Җанда ялкын
терелде...

## САЛКЫН АКЫЛДАЙ АЛТЫН

Хисләргә бай булсалар да,
көзләр күңелне баса...
Бәлки, рух сытылыр иде,
алтын көзләр булмаса.

Әбиләр чуагы килеп
өсти көзгә җылысын –
бер мизгеллек наз хакына
алданасың, чыдыйсың...

Офык өстендә болытлар
куерган саен, көзнең
салкын акылдай алтыны
бераз юата безне...

## ЗЫКЫЛЫ ЮЛЛАР

Яңгырлы кичләр һәм
томанлы иртәләр
уйларны зыкылы
юлларга кертәләр...

Дөньяның кояшын,
табынның ашлысын,

кочакның кайнарын
сагына башлыйсың...

Җил-давыл тетрәтә
күңелең кыясын...
Һәм томан тарала...
Һәм калка кояшың...

БӘХЕТЛЕ МӘШӘКАТЬЛӘР

Була ул, була кайвакыт
дөньядан туйган чаклар...
Нинди дә булса корабта,
кайсы да булса якка

китеп барасы килә бер,
бернәрсә уйламыйча,
күзне йомып, җанны ачып,
давыллар коча-коча...

Ашкынып чыккан буласың...
Ни диңгез юк, ни кораб...
Ә бәхетле мәшәкатьләр
тора күзеңә карап...

# Поэмалар

## КАДРИЯ

Кемгә сөйлим серләремне?..
*Фатих Кәрим*

Мин хат белән артык мавыкмадым –
ялкау булганмындыр
йә мәнсез...
Каникулда өйгә кайткан саен,
күп ашадым хаклы яман сүз:
«йөрәгеңә синең мүк үскәндер...»,
«мин студент булдым дигәч тә...»,
«әниеңнең монда җаны көя,
кайнар майга кергән дегәчтәй*...»

Әтиемнән калган папкалардан
килеп чыга кайчак үз хатым,
төрле-төрле кызык хатирәләр,
тозлы үкенечләр кузгатып.
Нигә, нигә җылы сүзгә шулай
саран булганмын дип сызланам...
Сирәк хатлар алып, сирәк язып
үткән яшьлегемне кызганам.
Интернетлар, SMSлар хәзер
үтеп үтеп кералмаган чик калмый...
Һәр хәрефен үбеп,
яшьтә юып
язган хатка берни җиталмый...
Һәм хәзер дә, кадерен белсәм дә,
читкә куеп кәгазь-каләмне,
телефонга барып ябышам да

Җир читенә юллыйм сәламне...
Хатлар үлә хәзер җир йөзендә!..
Бетеп бара аның базары...
Ә Казанда әле бер хат яши –
бәет итеп ташка язарлык.

Менә ул хат учым минбәрендә!
Тылсым тулы серле сүзләрен
колакларым әле ишетмәгән
һәм күрмәгән әле күзләрем.

Миңа аның барлыгы турында
Фатих Кәрим кызы сөйләде.
Йөрәгемдә түземсезлек булып
типте хатны күрү теләге.
Һәм мин Ләйлә ханым фатирында...
Һәм папкадан теге хат чыкты...
Һәм, штамплар арасында йөреп,
гомер юлын хатның ачыклыйм.
Кем язганы, кемгә язылганы,
кайчан язылганы билгеле...
Ачылмаган хатның серләре күп,
сер сөйләргә ләкин юк теле.

Хат хуҗасы Кадрия апа да
кайтып булмый торган якларда...
Күз яшьләре генә һаман исән –
хатта калган тозлы тапларда.
Кайберләре түгәрәк күл кебек –
хат тезләрдә, бәлки, өстәлдә
чалкан яткан чакта, ут тамчылар
бер-беренә кат-кат өстәлгән.
Игән башын учларына кысып,
күзен төбәп хатка, еш кына
утыргандыр ханым, яшькә кушып,
түгә-түгә күңел юшкынын.
Фатихын ул үлеп сагынганда,
алып аның фронт хатларын,
елый-елый укый торган булган,
бар эшләрен читкә аткарып.
Һәм тураеп китә торган булган...
Димәк, аңа хаттан көч кергән.
Хатны артык таушатмаска диптер,
ул алардан нөсхә күчергән...
Ә үзләрен еракка яшергән –
бала-чага кулы җитмәсен...

Мин «куллар»ны, сүз иярә генә,
бала-чага белән чикләдем,
юкса әле шагыйрь хатынының
хәтеренә кереп карасаң,
тентү эзләренә ул елларда
саркып яткан чактыр кара кан.
Юкса әле хәтер колагында
ике кызы – Ада, Ләйләнең,
командировкага диеп белеп,
«Әтием, кайт тизрәк әйләнеп!»
дигән тавышлары яңг(ы)рагандыр...
Тынамыни андый тавышлар?!
Балаң сүзе җаның сагындагы

үтә сизгер кылга ябыша...
Җил кыштырдау, ишек шакуларны,
тәрәзәдә фара яктысын
иң беренче шушы кыллар сизә,
хәбәр бирә:
сакла саклыйсын!
Утыз сигезенче дәһшәтле ел
«командировкасы» иренең
сугыш белән тоташып киткәч тә,
бушаймаска кыллар ки(е)релгән.

«Бәлки, дөнья үзгәрер дә бермәл,
бу хатларның чыгар кирәге»
дигән ышанычсыз ышанычка
ышангандыр аның йөрәге...
Шул ышану аңа көч биргәндер
өзелергә җиткән чакларда...
Һәм Кадрия һәрбер хатны үзе
рухи нөсхә иткән – ятлаган,
Коръән аятьләрен,
законнарның
арестантлар яклы төшләрен
күңеленә ныклап беркеткәндәй...
Татыганга орган эшләрен,
ышанмаган җансыз кәгазьләргә, –
кәгазь сата,
кәгазь яна ул!
Ә йөрәккә сеңгән сүзгә тентү,
конфискацияләр янамый.

Ләкин учым минбәрендә яткан
нечкә генә зәңгәр сызыклы
бу хат
Фатих Кәримнеке түгел,
аның башка гыйбрәт-кызыгы.
Язган аны
шагыйрьнең хатыны,
көтә башлап сугыш азагын.
Ә Җиңүгә әле нәкъ йөз көн бар!..
Шатлык көтүләрнең газабы
әҗәл газабыннан газаплырак,
җәннәт назларыннан назлырак...
Якын мираж кебек ерак шатлык
бик еш кына аңнан яздыра.
Шундый газапларга түзә-түзә,
сагынудан җитеп шартларга
язылган хат,
Ф.Кәримне эзләп,
күпме штабларны актарган,
күпме йөргән ул окоплар буйлап,
сугыш почтасында каңгырып,
пешә-пешә алгы сызыкларда,
кичә-кичә пуля яңгырын...
Ул айларда, кайнар магма булып,
көнбатышка фронт агылган
тукталышсыз...
Ләкин Кёнигсберг
киртәсендә ул да абынган...

Утыз еллап вакыт үткәннән соң,

ул җирләрдә мәхшәр эзләрен
мин дә күрдем*.
Фотоаппараттай
отып калды аны күзләрем:
алты метр калынлыгындагы
бетон капонирлар**,
ватылган
гигант чикләвекләр кабыгыдай,
җир астыннан өскә атылган;
анда-санда рыцарьлардан калган
ташпулатлар тора кызарып,
якынгарак барсаң, һәр кирпечен
була аерым тартып чыгарып –
канонада шундый көчле булган,
кирпеч купкан известь измәдән...
Исем китә: шундый шартлауларга
кеше түзгән, ә таш түзмәгән.

Шул җирләрдә февраль уртасында
әлеге хат Фатих Кәримне
эзләп тапкан,
аны күмгән чакта...
Үкенеч һәм кайгы әреме
исән калган взводташларының
тыннарына кереп тыгылган...
Хәрби номер йөрткән биеклектә
шигырь йөрткән шагыйрь егылган...

Кабер инде казылып та беткән...
Табып алып дюраль кисенте*,
старшина, пычак очы йөртеп,
уя Фатих Кәрим исемен.
Кыр почтасы белән килгән солдат,
шушы хатны алып биштәрдән,
бер Фатихның җәсәденә карый,
бер взводка карый –
нишләргә?
Бәлки, Фатих Кәрим белән бергә
күмәргәдер шушы хатны да?..
Шагыйрь аны шуның хәтле көтте...
Берсен-берсе менә таптылар...
Һәм ятсыннар Ләйлә белән Мәҗнүн,
Фәрһад белән Ширин шикелле...
Ә «адресат выбыл» хатларының
кирәклеге Җирдә икеле...
Солдат хатны шагыйрь күкрәгенә
куя чәчәк итеп, кадерләп...
Берәү әйтә:
– Укылмаган хатлар
күмелмәскә тиеш кабергә,
алар якты дөнья белән тоташ,
алар көтә белә, көенә...
Без шагыйрьнең дәфтәрләре белән
бу хатны да салыйк өенә...

Март кояшы зәңгәр күләгәләр
сызган чакта елак юлларга,
әлеге хат кайта да егыла
үзен язган җылы кулларга...
Һәм Кадрия таный үз язуын,

үз кәгазен таный, үз хатын.
Һәм йөрәге әллә нишләп тибә,
ялкын катыш буран кузгатып...
Буыннары кинәт йомшап китә...
Һәм Кадрия яза һушыннан,
кавышулар көткән өметенә
кире кайткан
хаты кушылгач.

Ә аңына килсә, күзләр коры,
эчкәрегә аккан Иделе –
йөрәк тәмугларын сүндерергә...
Ә ул шуны көтә идеме?!
Күңелендә инде аның күптән
бәйрәм маршы уйный патефон...
Һәрбер хаты тәмамлана иде:
«Күзләреңне үбеп, Фатихың...»
Үптерәсе килә иде аңа
куанычтан яшьле күзләрен...
Һәр шундый хат килеп төшкән саен
китә иде бераз үзгәреп,
тизрәк килә иде көзгесенә,
тузгыта да чәче өемен,
«Картаям бит, Фатих, кайтып күргәч,
суынмасмы инде сөюең?»–
дип уфтанып озак басып тора,
үз йөзендә үзе байканып
әйтеп куя:
«Ташласаң да мине,
кичерермен,
исән кайт, җаным...»

Ә үз хатын ачып укымаган...
Нигә укымаган?
Билгесез...
Бәлки, аны яттан белгәнгәдер...
Бәлки, бардыр берәр хәтәр сүз...
Егерме өч елы шулай узган.
Укытмаган хатны беркемгә...
Гомер кошы иярергә иткәч
китеп барган көзге төркемгә,
хатны кызы Ләйләгә тапшырган:
– Кирәк тапсаң, ачып укырсың,
әтиеңә көч бирәсе хисләр
гомереңне синең тутырсын...

Ул хат менә учым минбәрендә...
Нечкә-нечкә зәңгәр сызыклы...
Тотуга ук, аны тизрәк ачып,
укырга мин шундый кызыктым,
Ләйлә ханым әллә нишләп китте...
Күреп аның куркып калганын:
– Ә син нигә укымадың? – дидем, –
ничек түздең – шуны аңламыйм...
Һәм ул әйтте,
минем чынаякка
агызды да кайнар агымсу:
– Әти күзе тимәгән сүзләргә
ничек минем күзләр кагылсын?!
Әниемнең әтиемә генә

диеп язган серле сүзләре
ачылыр да, «Фатих Кәрим» дигән
реаль дөньям минем үзгәрер!..
– Укылмаган хатлар үле бит!.. – дим, –
күмеп булмый торган кабердә,
алар яши, хәтта алар эшли
миңгә тапкырланган хәтердә.
– Бик теләсәң, ач та укы, – диде, –
миннән рөхсәт, синнән – калганы...
Ләкин мин дә
хатны укымадым –
никтер аны
ача алмадым...

Хатлар үлә бүген, хатлар үлә
компьютерлар хаким заманда.
Ләкин бер хат һаман исән әле,
исән әле,
яши Казанда,
дөньясына каргыш булып микән,
мәдех булып микән сөюгә?..
Ә хәрефләр түземсезләнәләр,
күз нурлары хатка тиюгә –
сүзләр булып тизрәк тупланасы,
ачыласы килә аларның!
Хатларда да – тарих,
ул тарихны
йөрәк белән генә аңларлык...
Хатны әле беркем укымаган,
беркем кагылмаган серенә...
Ул Кадрия дигән әүлияның
сулмас сагышына төренгән.
Ә сагыш ул
тәрәз пәрдәсе дә,
ишек чаршавы да түгелдер...
Кагылырсың...
Ул ачылыр...
Аннан
ташкын булып нәрсә түгелер?..

Үлә, үлә,
аһ, үләләр хатлар...
Кайгырмаска, бәлки, кирәктер...
Хатлар белән әмма каләм язган
матурлыгы үлә йөрәкнең...

*28 ноябрь – 4 декабрь, 2006*

## НАРСПИ ЭЗЕ

*Чуваш әдәбияты классигы Константин Иванов язган «Нарспи» поэмасының100 еллыгына багышлыйм.*

Кемнәр кушаматсыз яши?
Кемнең адымы эзсез!..
Кушамат ул, асылында,
орден кебек саллы сүз.
«Урыс башлы татар» дигән
кушамат та йөреттем.
«Чувашҗан Харис» дигәне

ипләп-сипләп беректе.
Берсеннән дә баш тартмадым,
һәм тартмам да, бигайбә, –
икесе ике канаттай,
икесе дә бик әйбәт.
Татарпәрварлык шундый ук,
хәзер хәтта киңрәк тә –
яңа орденнар тагарга
киерелгән күкрәктәй!

Бик Үти – татар авылы.
Шушында ике Бола*
чувашча җырлап килә дә
татар көенә тула.
Күмәк җыр ага Зөягә,
чишмәләр җыя-җыя...
Һәм, Турхан* пиччә** әйтмешли,
Зөя Иделгә коя.
Ә Идел-су – кан тамыры
дистәләгән халыкның.
Кем кимсетсен тамырында
Идел аккан алыпны?!
Кушаматым күп булудан
мин тамчы да гарьләнмим –
яңаларына да байтак
шәп сәбәпләр бар әле...

Бик Үтидә – рус классы!
Тирә-юньдә бу сирәк!
Килә чуваш авыллары
Тимәш белән Байдирәк...
Су тегермәне бар иде –
тора иде күренеп.
Салам башлы ялгыз йорттан
бер кыз укыды йөреп.
Алтынчыда укыганда,
яп-якты алтын көздә,
чуваш кызы Мариана
килеп кушылды безгә.
Ул кыз инде җиденчедә
укырга тиеш булган,
ә бездә җиденче сыйныф
бары киләсе елга!
Без бер партада утырдык...
Рус-татар-чувашчалап
кадәри хәл белем җыйдык
мәктәп дигән бакчада...
Сүзләр сораша-сораша,
без якынаеп беттек.
Ял көннәрдә дә күзләрем
Мариананы көтте...
Кыш көне су тегермәне
эшләмәгән, ахрысы, –
юл юк иде, Мариана
йөри иде кар сосып...
Туңа-туңа аны көтәм...
Ул әллә нинди иде...
Бер дәрестә кайнар тыны
минем колакка тиде:
«Укырга яратасыңмы

син мәхәббәт турында?..»
Ә кайнар ярымшарлары
беләгемә орынган...
«Нарспи атлы бер кыз булган,
Сәтнәр атлы бер егет...
Укыйм – елыйм, укыйм – елыйм
нарасый бала кебек.
Алар шундый яратышкан –
сөйләп бирерлек түгел...
Әйдә, дәрестән соң калып,
сиңа да укыйм бүген...»
Ә кайнар ярымшарлардан
миңа дулкыннар күчә.
Оялып читләшкән булдым,
сыендым әллә ничә...
Миндә дә инде кабынган
татлы хисләр учагы –
мәхәббәтне кыяр-кыймас
аңлый башлаган чагым.

Тәрәзәдән март кояшы
тын юлларыма тулды.
Әллә ниләр өмет итеп,
шунда ук риза булдым.
Чираттан тыш дежур булып,
классны җыештырдык,
эшебезне бик тиз тоттык –
нидер булышып торды.
Ниһаять, безнең класста
вакыт талды-тукталды...
Букчасыннан Мариана
иске бер китап алды.
Ачты аны, ачкан кебек
серле дөнья ишеген...
Һәм мин үзем аңламаган
серле сүзләр ишеттем...
Ә ул укый, укый, укый,
китаптан күзен өзми...
Ә мин, сихерләнгән кебек,
өзәргә кыймый түздем.
Тын алырга тукталды ул...
Һәм мин куйдым йөткереп...
Аңламавымны аңлады,
минем күзләрне күреп...
Беравык аптырап торды:
бу нинди сәер кеше?!
Аннары көлеп җибәрде,
үз хәленә төшенеп.
Маңгаена учы белән
суккалап ала кызып
күмер кашлы, зәңгәр күзле
бик матур чуваш кызы.
Нарспи язмышына ул
җаны белән кергәнгә,
нинди телдә язылуга
игътибар да бирмәгән.
Наздай назлы, көйдәй моңлы,
җыр кебек чуваш теле
сихерләгән, әсир иткән
язга чыккан күңелен...

Кемдер аңлый алмас дигән
уй аңарда тумаган...
Ә монда күз тәгәрәтеп
утырам мин – томана!
Ипи-тозлык тел белү дә –
мактаулы эш, әлбәттә...
Шигырь аңлау өчен телне
белү кирәк һәйбәтләп,
чөнки шигырьдәге сүзгә
бергә кушылып сыя
хисләрдән хасил океан,
уйлардан хасил дөнья.

Мин «Нарспи» белән шулай
кызык кына кавыштым...
Укып чыгасы килүем
теләгемә ябышты,
кыздырып дәвалый торган
гәрчичле кәгазь булып...
Тәүге утлы түземсезлек
җан үзәгемә тулды...
«Нарспи»ның татарчасын,
урысчасын да хәтта
эзләү дигән гади фикер
һич килмәде ул чакта.
Без гадирәк юл сайладык
поэмага кермәккә –
Мариана миңа үзе
чуваш теле өйрәтә!..
Бүгеннән фәкать «чывашла»
сөйләячәк барын да,
игътибар да бирмәячәк
«ынланмалла мар»*ыма.
Җомга әнә Робинзонны
өйрәнгән бит аңларга!

Алты класс белем белән
мин киммени аңардан?!
Һәм өйрәнә дә башладым
бар көчемә тырышып...
Тырышлыктан бигрәк миңа
тагын нидер булышты.

Шулай итеп, сиздермичә,
язлар үткән дә киткән,
җәйге каникул көннәре
килеп җиткәннәр икән!
Шундый көтеп ала идем
ел да мин ул чакларны!..
Бу юлы кабынмадылар
куаныч учакларым...
Нарспилы дәресләрем
кисәк кенә бүленде,
мин һәм шатлык арасына
көннәр элде өленге...

Су тегермәне ягына
карыйм җай чыккан саен...
Әнә соры салам түбә,
әнә бөгелгән каен,

әнә юып элгән керләр
җилфердиләр кояшта...
Аларны кем юсын инде
Марианадан башка –
хатынын тегермәнче карт
җирләгән иде былтыр,
Мариана карый иде
Чәргәй пиччәнең йортын.
Бердәнбер улы сугышта
юкка чыккан хәбәрсез...
Беравыктан килеп җиткән
әллә нинди хәтәр сүз...
Кызчык белән калган килен
ун елдан артык түзгән,
аннары кияүгә чыккан...
Һәм былтыр алтын көздә
Чәргәй пиччәнең оныгы –
«зәңгәр күз, кара кашы» –
минем классташым булды,
ташлап китеп Канашын...

Бер-ике атна түздем мин...
Ә йөрәк яна тора...
Киттем су тегермәненә –
дәресләр яңартырга.
Чәргәй пиччә улакларның
ярыгын ямап йөри...
Йөгреп чыкты Мариана,
мине тәрәздән күреп.
Күзләрендә кинәт килгән
шатлыктай ут уйнаклый –
нишләтергә генә белми
көтми көткән кунакны...
«Теге «Нарспи» китабын
дәвам итәргә телим...»
«Чувашча әйт», – ди... Мин әйттем,
вата-җимерә телне...
Алып чыкты «Нарспи»ны...
Ул укый, ә мин тыңлыйм...
Гүя җылы су агышы
колакларымда чыңлый:
«Челтер-челтер су ага
Биек улак буйлата.
Ялтыратып көмеш күк,
Суын кояш нурлата»*.
Ничәнче кат укыйдыр ул?!
Укымый – яттан белә...
Мин дә аңлыйм, ахры! Сизәм:
Сэтнәр буласым килә...
Нарспиның Сэтнәр белән
качуы үз туеннан,
аларның тотылулары
тынгы бирми уема.
Ачуым килә Сэтнәргә:
качтың икән – тоттырма,
ул, урманда йоклап ятып,
бар бәхетен оттырган...

Көнаралаш тегермәнгә
барып дәрес яңартам...

Барган саен йөрәгемдә
кайнарлана янартау.
Төнге урман вакыйгасын
карт таллар ышыгында
укыдык без, су агышы
җырына кушып кына...
Янартау шунда шартлады...
Уты болытка тиде:
«Мин булсаммы, мин булсаммы...
Нишләргә белер идем...» –
дидем мин Марианага,
тешемне кыса-кыса...
«Йә, йә, нәрсә эшләр идең,
әйтик, мин Нарспи булсам?..»
Көтелмәгән бу сораудан
утка әйләнде башым,
әйтерсең маңгай эчендә
ярылды яшен ташы.
Күзләремне йома алмыйм,
иреннәр кургашындай...
Тиле телгә һәйкәл булып
каттым да калдым шунда.
«Мин менә Нарспи булсаммы,
тормас идем интегеп...
Хәзер үк... шушы таллыкта...
Ләкин син Сәтнәр түгел...
Синең әле егет булып
җитәсе көнең алда,
авызың авыз итмәгән
балдан татлырак балдан...
Ул бал, беләсеңме, кайда?..
Әйдәле шуны таты...»
Һәм мине үбә башлады,
өстемә менеп ятып...
Тыннарым буыла язды
көтелмәгән баскыннан.
Елан кебек шуып чыктым
аның кайнар астыннан.
«Нишләвең бу, шашкан?..» – диеп,
авылыма ычкындым...
«Иренеңнән сөт кипмәгән...» –
дип, аркама кычкырды...

Табаннарымны да тоймыйм
аптырау-куркуымнан,
яшел чәчле Су анасы
әйтерсең арттан куа...
Күзләреннән чишмә ага –
мин аркам белән күрәм...
Борылып та карамыйча
йөгерәм дә йөгерәм.
Чалбар балакларымны да
сызганып маташмадым –
ерып чыктым Бола суын...
«Саташкан, саташкан ул,
укый-укый «Нарспи»ны,
аңын каплаган болыт –
күренә башлаганмын ич
мин аңа Сәтнәр булып!»

Чуваш теле дәресләрем
әнә шулай өзелде...
Көннәр көннәргә ялганды,
атналарга тезелде.
Сәтнәр һәм Нарспи калды
мәңгелеккә урманда.
Аларны тотканнар иде –
нишлиләр икән анда?

Нишли икән Мариана?
Сельмагта да күренми...
Күренмәсен лә, ул тиле
авырттырды иренне...
Әллә нинди көч күңелне
һаман кытыклап тора –
су тегермәне ягына
һаман башымны бора.
Юк, юк, бер адым да бүтән
ул якка атламамын –
теләмим теге хәлләрнең
янә кабатлануын...
Шул куркыта, ахры, мине...
Һәм шул канны котырта –
җанымны авырлык белән
урынына утыртам.
Ә ул дулый, һәм мин сизәм:
җаным яклы көрәштә
Нарспи һәм Мариана
бер кешегә берләшә...

Җәйге каникул ник алай
исәпсез озын икән?
Никтер һәрбер көне аның
мине сагышлы итә...
Сагышым уйга әйләнә,
уйлар керә сүзләргә,
сүзләр юлларга тасланып
матурая, үзгәрә.
Язам да кычкырып укыйм –
яңгырый шигырь булып...
Шундый язма белән тиздән
шакмаклы дәфтәр тулды...

Миндәге яңалыкларга
әни игътибар иткән:
«Улым, нигә син боек? – ди, –
йөзеңнең төсе киткән...»
Әниемнең соравыннан
һич югалып калмадым:
«Мин «Нарспи» дигән китап
югалттым», – дип алдадым...
Бер атнадан миңа әти,
әнием сүзен тыңлап,
«Нарспи»ны алып кайтты
Буадагы дустыннан...
Ә китап татарча иде!..
Утырдым, укып чыктым...
Гашыйкларның һәлакәте
бугазга төер тыкты.
Тын алырга бирми төер...

Йөрәгем дөп-дөп итте...
Шакмаклы дәфтәрем алып,
Бола буена киттем –
поэманың азагын мин
үземчә сүтәчәкмен,
Нарспи белән Сәтнәрне
бәхетле итәчәкмен!
Аларны калдырачакмын
Сәтнәрләрнең өендә –
яшәсеннәр тыныч кына
һәм сөенә-сөенә...
Ләкин шулай яшәрләрме,
исән калса Михәдәр, –
байлыкка кызыгып, кызын
кимсетте ул никадәр!
Җәзасын алырга тиеш
әнисе дә шулай ук –
баласын каргаган кеше
үзе каргышка лаек!..
Ләкин уйларым ялганмый...
Аптырап беттем, йөдәп...
Ивановча калсын диеп,
мин кайтып киттем өйгә.
Уңышлы язып бетерсәм, –
зурдан иде исәбем –
Константин Ивановка
тәкъдим итәсе идем.
Ә ул кырык елга якын
ята икән кабердә...
Шушыны белү мизгеле
һәрчак минем хәтергә
килә, берәр яңа китап
алган саен кулыма...
Кереш сүзен укымыйча
кермим шигырь юлына...

Әллә нинди көч күңелне
тагын кытыклап тора –
су тегермәне ягына
һаман башымны бора.
Күрәсе килә керләрнең
җилфердәвен кояшта...
Теге кызны күреп кайтам –
түзеп интекмим башка!
Кабатласа кабатласын
хәтәр кылануларын.
Баллардан да татлы балын
үзем дә кабып карыйм...

Боланың теге ярында
киндераш – биек, куе...
Орлыгын инде уарлык,
уч арасына куеп.
Сөңге очы кебек очлы
тамыры киндерашның...
Сугыш-сугыш уйный идек...
Авырта иде башым...
Ул чакта без белми идек
аның бик хәтәр көчен –
аңнарны томалый торган

үтә исерткечлеген...

Барып җиттем... Чәргәй піччә
тегермәндә он тарта...
Ап-ак тузан аның хәтта
керфекләрен агарткан.
Марианаңы сораштым.
Ул Ялчектә бальниста;
киндераш чәчәк аткач та
башы авырткан, коскан,
хәтта ике-өч мәртәбә
ул аңын да югалткан;
куркуыннан, піччә аны
Ялчеккә илтеп кайткан;
киндераш исе ярамый,
дип әйткәннәр докторлар;
киндераш беткәч тә монда
кайтыр инде дип тора...

Мариана тегермәнгә
кайтмады көз кергәч тә,
кайтмады киндер басуын
ап-ак карлар төргәч тә.
Поэманы миңа беркем
чувашча укымады.
Чуваш телен өйрәнү дә
башланды да тукталды...
Ләкин көчәйде сагыну –
аңлый да алмыйм аны –
әллә гүзәл Нарспины,
әллә Марианаңы...
Шул сагыну дәвам итте
шакмаклы дәфтәремдә,
ауната-ауната хисне
йә балда, йә әремдә...
Хисләргә сүзләр табылды,
сүзләргә – ипле торак:
шигырьдә барлык сүзләр дә
патша кебек утыра!

Күпме генә эзләсәм дә
бүгенге көнгә кадәр,
Мариана турында мин
таба алмадым хәбәр...
Күңеле калкансыз иде,
шигырьдән иде, җырдан...
Каршы тора алды микән
безнең болгавыр чорга?..
Мин исә Марианаңың
йөрәк тибешен тоям, –
күрәсең, җаныма минем
сагыныч булып сыйган!
Сагыныч янәшәсендә
Нарспи атлы гүзәл...
Аның йөрәге януын
кан юлларымда сизәм...
«Шагыйрьлек – сагыну!» дигән
фикер чынлап хаклыдыр –
шушы поэма да, бәлки,

аны эзләү хатыдыр...

Ә кушаматка килгәндә,
кушаматсыз – күңелсез!
Кушамат ул, асылында,
орден кебек саллы сүз.
Кушамат минем исемгә
дәрәҗә өсти, бизи –
ул ике чуваш кызының
йөрәккә уйган эзе!

*18 май, 2008*

# Тәрҗемәләр

РУСЧАДАН

*Гавриил Державин*

ХӨКЕМДАРЛАРГА ҺӘМ СУДЬЯЛАРГА

Калыккан да тиңсез Аллаһ, хөкем итә
Дөньялыкның бихисап күп аллаларын;
Кайчангача, дип әйтә ул, кайчангача
Сез аярсыз яманнарны, усалларны?

Бурычыгыз сезнең – кануннарны саклау,
Көчлеләрнең кемлегенә карамыйча,
Ятимнәрне һәм толларны беркайчан да
Ярдәмсез һәм яклаусыз һич калдырмыйча .

Бурычыгыз сезнең – бәлаләрдән йолу
Гаепсезне, бәхетсезгә терәк булу;
Көчлеләрдән көчсезләрне аралау һәм
Мескеннәрне богаулардан азат кылу.

Ишетмиләр! Күрә торып төшенмиләр!
Бәбәкләрен ришвәт, бүләк томалаган,
Явызлыклар җирнең тәнен тетрәтәләр,
Ә күкләрнең эчен айкый-чайкый ялган.

Патшалар! Сез Аллаһ кодрәтенә ия,
Сезгә һичкем судья түгел сездән элек.
Әмма сез дә нәкъ минем кебек языклы,
Әмма сез дә гүр иясе – минем кебек.

Сулган агач яфраклары өзелгәндәй
Өзелерсез әле сез дә вакыт җиткәч,
Иң әшәке колыгыз үлеп киткәндәй,
Үзегез дә бер үләрсез ахыр чиктә.

Калкын, Аллаһ! Калкын, хаклылар Алласы!
Ишетә күр ялваруларын шуларның:
Хөкем ит һәм җәзала мәкерлеләрне,
Һәм бердәнбер патшасы бул Җир шарының!

*1780 (?)*

## КОШЧЫККА

Бер сайрар кошны тоттылар,
Учларына кыстылар.
Чәрелди кошчык, ә аны
«Сайра!» диеп кыстыйлар.

*1792* яки *1793*

## ШУК ТЕЛӘК

Әгәр сөйкемле кызлар
очсалар мисле кошлар
һәм кунсалар ботакка, –
мин ботак булыр идем,
меңләгән кыз-кыркынны
шунда кундырыр идем.
Утырып җырласыннар,
җайлы оя корсыннар,
балалар чыгарсыннар;
мин һич бөгелмәс идем, –
һәм булыр идем шулчак
мин иң бәхетле ботак.

*1802*

* * *

Вакыт дәрьясы үзенең агымында
алып китә инсан эшләренең барын
һәм батыра онытылу чоңгылында
патшалар, патшалыклар һәм халыкларны.

Әгәр дә ки ни дә булса кала калса
трубалар һәм лиралар тавышы аша,
аларны да мәңгелекнең зур авызы
чәйнәп йотар һәм дә булмас язмыш башка.

*6 июль, 1816*

## ТОНЧИГА*

Үлемсез Тончи! Ишетәмен, син ният
Кылгансың сурәтләргә минем затымны,
Борынгы Гомер йә батыр Аристидны,
Гакыллы Сократны йә кырыс Катонны
Сурәтләгән олы осталыгың белән
Килер буыннарны шаккатырмакчысың;
Чал чәч һәм пеләш балкышы аркылы
Кеше үзе күренеп торырлык булсын.

Пеләш булумы, әллә парик йөртүме,
Әллә тога, әллә кыска, тар мундирмы
Сине бөеккә әверелдерүчеләр?
Һич юк! Фәлсәфәң һәм Музаларың җыры;
Шулар безне шулай данлыклы кылалар.
А! Әгәр дә хаклык рухы торса тиеп
Һәм яктырта калса мине дан нурлары,
бик килешер иде миңа һәрбер кием.

Шулай, фәлсәфәче рәссам! Сурәтемне
Төрле сәер киемнәрдә ясап ал бер,
Белгәнеңчә, ләкин гакыл ияләре
Мәхәббәтлелеген дә беркетеп калдыр.
Бөекләргә әгәр кайбер йомшаклыклар
Хас булсалар, син шуларны да эндәшми-
Нитми миндә чагылдырырга онытма,
Аларга да елмайсын әле көнләшү.

Юк, син мине тупас табигыйлегемдә
Бик һәйбәтләп кенә сурәтләргә тиеш:
Зәмһәрирдә җанына ялкын-ут капкан,
Йонлач бүрек һәм җылы тун кигән килеш;
Табигатьнең әмеренә ияртелеп,
Җил-давыллар җиңеп, тауга менә барыйм,
Һәм күренсен бозлы якта туганлыгым,
Ерак бабам булганлыгы морза Бәгърим.

Хатынымны, дус-ишләремне куркытма,
Мине бераз мөлаем итсәң дә ярый:
Балаларны назга төрим, тик вазифам
үтәгәндә мин кырыс карар чыгарыйм.
Каным минем дөрләгән уттан кайнасын,
Күз нурларым йомшак булсын, сынмасыннар;
Платоник сөюдән генә булса да,
Чибәркәйләр миңа карап уфтансыннар.

## ДАВЫЛ

Каегым диңгездә кайный –
Кара дулкыннар эчендә;
Ян-якта чал таулар шаулый...
Таянам өмет көченә.

Кем ул болытлар ялкынын
Сүндерүче баш очыннан?
Кем кулы ул каегымны
Яшерде таш ышыгына?

Син, Дөньяны яратучы!
Бөртек чәчем дә башымнан
Синсез төшми. Син коткардың
Бу һәлакәт ялгышыннан!

Гомеремне озайттың син,
Рухым синең алда ачык;
Түрәләр рәтенә керттең,
Калканым бул һәм юлбашчым.

## АЛЛАҺ

Йа Син – ирек-иркенлектә иксез-чиксез,
матдәдәге хәрәкәттә җанлы-тере,
вакыт агышында мәңге-бакый булган
өч чырайлы, өчесе дә йөзсез Тәңре!
Һәркайда бар һәм бердәнбер рух-сәгадәт,
Сиңа кирәк түгел урын, һичбер сәбәп.
Асылыңа синең беркем төшеналмас,
Бар нәрсәне үзең белән тутыргансың,

Урагансың, нигезләгәнсең, коргансың,
Һәм исемең телебездән төшми, – Аллаһ!

Океаннар тирәнлеген үлчи алган,
Барлый алган комнар санын, нурлар көчен
Олуг акыл табылса да бу дөньяда,
Сан табылмас, Аллаһ, Сине үлчәр өчен.
Яктылыгың нурларыннан Синең туган,
Синең рухың белән мәгърифәтле булган
Син язганны беркем дә үзгәрталмас.
Уй-хыяллар гына, ашып Синең катка,
Бөеклегең тирәнлекләренә бата,
Мәңгелектә мизгел эрегәндәй, Аллаһ!

Вакыттан да элгәре булган хаосны
Мәңгелекнең төпкеленнән Син чакырттың.
Барыннан да алдан туган мәңгелекне
Син үзеңдә нигезләдең һәм бар иттең;
Үзең белән Син үзеңне төзеп кордың,
Үз нурыңнан үзең нурдай балкып тордың,
Яктылыкка чишмә булып иң-иң элек.
Тик сүз белән бар нәрсәне яралдырдың,
Һәр яңада Син үзеңне иҗат кылдың,
Син бар идең, Син бар бүген, Син мәңгелек!

Сыйдыргансың Син тереклекнең чылбырын,
Асрап тәрбия итәсең өздермичә,
Башлау белән төгәлләүне ялгыйсың Син,
Яшәүгә үлем бирәсең сиздермичә.
Чәчри очкын, берсен-берсе куа-куа,
Һәм кояшлар, шулай чәчрәп, Синнән туа;
Аяз, суык кышкы көндә бозланган кар,
Бәс тузаны ялтыр-йолтыр иткән сыман,
Чиксез күкнең чиксез тирән карасында
Җемелдәшә Синнән аста йолдызлыклар.

Миллионлаган якты җисем күкләр буйлап
Үлчәмсезлек агымында агып бара.
Алар Синең кануннарың хаклылыгын
Терек нурда коендыра һәм сугара.
Ләкин якты утлы шушы лампадалар
Яки алсу кристаллардан хасил таулар,
Яки алтын дулкын чөйгән кайнар күбек,
Яки ургып-дөрләп янган төнге эфир,
Яки якты нурга чумган бар галәм, Җир
Синең янда – көн каршында тик төн кебек.

Диңгезләргә тамган тамчы чаклы гына
Шушы каты катлам Синең алларыңда;
Һәм нәрсә ул мин күзәтә торган галәм?
Һәм мин үзем нәрсә инде Син барында?
Һава океаннарын мин яуласам да,
Дөньяларны миллионга тапкырласам да,
Җөрьәт итмәм – чагыштырып карый алмам –
Чагыштыру мөмкин түгел Синең белән;
Бөтен нәрсә нокта гына, үзем беләм,
Мин дә бер юк нәрсә генә Синең алда.

Бер юк нәрсә! – Әмма миндә Син балкыйсың,
Игелегең бөеклеге агылгандай.
Миндә үзең үзеңне үк сурәтлисең,

Бер тамчыда бөтен кояш чагылгандай.
Бер юк нәрсә! – Әмма мин тормышны тоям,
Һич туймыймын һәм дә, канат какмый, кыям
Бер татырга күк гөмбәзенең тарлыгын.
Минем җаным-тәнем Сине шундый сөя,
Ул уйлана, ул төпченә, фикер чөя:
Мин – бар! Димәк, шиксез Синең дә барлыгың!

«Син бар!» диләр табигатьтәге тәртипләр,
Йөрәгемнең һәр тибеше аңлата гел,
Раслый моны минем төпченгән акылым:
Син бар – һәм мин инде бер юк нәрсә түгел!
Мин – бу бөтен бер галәмнең бер өлеше,
Һәм уйлыймын, Синең сайлау миңа төште –
Иң мөхтәрәм чик-ызанга мине куйдың:
Монда бетә, тәгәлләнә җанварларың,
Һәм башлана шушында ук рух-җаннарың,
Һәм Син миннән бу чылбырга ялгау койдың.

Һәр төштә бар дөньяларга ялганыш мин,
Мин матдәнең иң җитлеккән, биек очы;
Тормыш итү мәгънәсенең үзәге мин,
Илаһилык сыйфатлары башлангычы;
Тәнем чери, көлгә әверелә, бетә,
Ә акылым яшенгә идарә итә –
Мин патшамын – мин кол, мин корт – мин Аллаһмын!
Әмма ләкин булсам да шундый могҗиза,
«Ничек бар булдым?» – дип, уйлап чигәм иза;
Үзлегемнән булалмадым һәм алмамын.

Синең иҗат җимешең мин, Бар итүчем,
Синең акыл, Синең кодрәт йөзек кашы,
И Яшәүләр чыганагы, Игелеклем,
Җаным жаны һәм дә аның Падишасы!
Синең хакны хаклар өчен кирәк булган
Чиксез үлем төпсезлеген кичә алган
Минем үлемсез яшәеш-үзлегем дә;
Рухым фанилык киеме кисен өчен,
Үлем аша кичеп янә килсен өчен,
Атакаем, Синең үлемсезлегеңә.

Аңлату да төшенү дә мөмкин түгел!
Мин беләмен җаным ничек теләгәнне –
Әмма ул да күз алдына китералмас
Һәм сурәтли алмас хәтта күләгәңне;
Ләкин Сине данларга кирәк чакларда
Һәм моңа без фаниларның хакы барда,
Моны эшләр өчен әмәл һич юк түгел:
Безгә кала Синең катка юл аласы,
Аермабыз арасында югаласы
Һәм рәхмәтле күз яшьләре кою-түгү.

## ЛИРАГА

Румянцевка, Суворовка
дан җырларга теләдем;
лирам кылларыннан шаңдау
ялкын-уттай гүләде.
Көнчел язмыш Румянцевны
гасыр артына илтте;

Суворов, гади бәндәдәй,
караңгылыкка китте.
Нәрсә, аларга рәхәтлек
бирерме синең мактау?
Онытылмаслар үлемсез
эшләре исән чакта.
Андый тавышлар кирәкмәс,
кылларны янә җайлыйк:
җыр өчен батырны түгел,
ә мәхәббәтне сайлыйк.

*Ноябрь, 1797*

## ҺӘЙКӘЛ

Мин үземә шундый һәйкәл куйдым – гүзәл, бакый,
Металлдан да ныграк, пирамидадан да биек;
Давыллар да, яшеннәр дә сугып ега алмый,
Вакыт агышы да һәлак итмәс аны, тиеп.

Шулай! – бөтенләем белән үлмәм, зур өлешем,
Фанилыктан бакыйлыкка качып калыр анда,
Һәм даным да, сулу-кибүләр белән килешми,
Артыр славяннар токымын Галәм санлаганда.

Минем хакта хәбәр Ак сулардан Карасына,
Идел, Нева, Дон, Уралга кадәр барып җитәр;
Шундагы сан-исәпсез халыклар арасында
Мин билгесезне менә нәрсә билгеле итәр:

Фелицаның игелекләрен әйтеп салырга,
Аллаһ турында сөйләшергә ачылып китеп,
Һәм елмаеп патшаларга турысын ярырга
Уйнак рус телендә беренче мин җөрьәт иттем.

Йа Муза! хаклы казанышың белән горурлан,
Кем санлашмый синең белән, син дә аны чит күр;
Тәкәллефсез, ашыкмаучан ныклы кулың белән
Маңгаеңа үлемсезлек таңын таҗың иттер.

*1795*

## АРФА

Җәйге эссе көннең җиләс җилеме ул
төшләремдә күкрәгемә рәхәт бирә?
Кыяктагы бәллүр чишмә тавышымы,
үбешүме колагыма чыңлап керә?

Юк ла! арфа: аның тылсымлы тавышы
гөлчәчәкләр арасыннан күтәрелеп,
кайтавазлар булып назлый бик ерактан
җан кылларын чиертеп, аңа бәрелеп.

Син ул шулай, Музаларның якын дусы,
Хаританың кыллар тарткан кулы аша
соклануларыңны безгә җиткерәсең,
башың зәвык алиһәсенә тоташкан.

Күңелле лә синең белән бергәләшеп
тыңлау Ватан турындагы җыр тавышын,

чөнки ул җыр ишеттерә яз килүне
һәм Казанда алтын вакытлар агышын!

Аh, ул минем тәүге көннәрем бишеге!
Саф чагымның, үсмер чакның изге өе!
Кайчан кабат таң нурында коенырмын
элеккечә улың булып сине сөеп?

Кайчан күзем күрер мирас көтүләрне,
Кама буендагы мәгърур иманнәрне?
Җилкән киереп кайчан Иделдә йөзәрмен
һәм кочармын ата-бабам каберләрен?

Яңгыра, арфа, сөйлә Казаным хәлләрен!
Сөйлә, ничек безнең якка Павел кайтты!
Җанга рәхәт туган яктан яхшы хәбәр:
Туган илнең төтене дә хуш һәм татлы.

## МӘХӘББӘТ ИГЪЛАНЫ

Табигать тәмам йокыда,
ә минем гыйшкым уяу;
синең тынынны ишетә,
күз нурын синa коя.

Сүзләремә син колак сал,
һәм уйлан ялгыз чакта;
күз нурларында коендыр,
назың белән кочакла.

Үзеңә үзең җавап тап,
фикерең миңа җиткер;
ике җан кушылудан да
зуррак соклану юктыр!

Шул хозурлыкны күзалла,
шуны татырга ашык;
алиһәләргә тиңләшә
дөньяда ике гашыйк.

## АҢЛАШУ

Изге бәндәгә салынып
һәм күпертеп күлмәгем,
философ битлеге киеп
мин кылана белмәдем;
эчкерсезләрне яраттым,
шуларга ошыйм дидем,
йөрәге, аңы кешенең
булды минем Даһием.
Утлар сирпелде кылымнан,
балкысам сокланудан:
бу – Аллаһ нуры, ә тыштан
җырладым Аллаһка дан.
Патшаларга багышланса
лирам моңнары әгәр,
игелектә Аллаһка тиң
булып күренде алар.
Җиңүче Юлбашчыларга
такыя үрсәм бүләккә –
алар җанын буыннарга

күчерергә теләктән.
Әгәр түрәләр колагын
ярсам дөреслек белән –
илгә, патшага, аларга
дус буласы килүдән.
Әгәр үзем дә бирелсәм
дөнья мәшәкатенә,
яшермим: хатын-кызларга
кол булу рәхәтеннән.
Кыскасы, сөю ялкыны
һәр гасырда да хәтәр.
Таш бәр, хәким, каберемә,
кеше булмасаң әгәр.

## ВСЕМИЛАГА

Нинди аңлашылмаган көч,
иңеп күзең, телеңнән,
буйсындыра, и Всемила?
Син патша күңелемә.

Дөньяга гүзәллек хаким,
йөрәкләр аңа – тәхет.
Патшалар аңа баш ия,
акыллыга ул – бәхет.

Бөекләр тормышын кара,
аңларга шуны тырыш:
батырлыклары сәбәбе –
назга сусау-омтылыш!

Ник елыйсың, и гүзәл зат,
чишмә итеп күзеңне –
патшалар һәм патшалыклар
кулыңда ич үзеңнең?!

«Барысы да хыял!» диеп,
яшең ага ургылып...
Сафлык белән көчле бары
хатын-кыз матурлыгы.

*Александр Пушкин*

## ТИЛЕБАШ

Ике лагерь күз алдында
Үрләрдә атыш бара.
Кызыл киеме тилебаш
Казакның күзен яра.

Тилебаш! Кызган җаныңны,
Алай хәтәр очынма,
Шаяруың эләктертер
Сине сөңге очына.

Һәй, казак! Син дә ашкынма
яу кырына, бул сабыр –

кылычы белән тилебаш
башыңны чабып алыр.

Берсе берсенә ыргылды.
Күрегез шундый эшне –
Тилебаш сөңгедә. Казак...
башы тәгәрәп төште...

* * *

Сөйдем сезне, бәлки, гыйшкым һаман
Сүнеп бетмәгәндер җанымда;
Тик ул сезне башка борчымасын;
Моңлатасым килми тагын да.
Сөйдем сезне сүзсез һәм өметсез,
Куркаклыктан талып, көнләүдән;
Сөйдем сезне шулай – Ходай язсын
Сөелергә башка берәүдән.

## БАРАТЫНСКИГА

*(Бессарабиядән)*

Ошбу тыныч, иркен һәм буш яклар
Шагыйрь җаны өчен изге ул:
Державинның җырларында алар,
Һәм рус даны белән туп-тулы.
Бүгенгәчә Назонның шәүләсе
Дунай ярын эзли бирегә;
Һәм ул оча Аполлонның татлы
Дәшү авазына бирелеп.
Шәүлә белән мин дә бик еш йөрим
Текә ярда, моны ай күрә;
Тик үзеңне җанлы Овидийны
Кочкан итеп кочу ямьлерәк.

*1822*

*Михаил Лермонтов*

## БЕРЬЯЛГЫЗЫМ ЮЛГА ЧЫГАМЫН МИН

1

Берьялгызым юлга чыгамын мин;
Чакматаш юл балкый томан аша;
Төн тын. Бушлык тыңлый Тәңре өнен,
Йолдызлар белән йолдыз аңлаша.

2

Күк гөмбәзе тантаналы, гүзәл!
Җир йоклый күгелҗем балкышында...
Ник мин авырсынам шулай, әрним?
Нидер көтәм... кызганаммы шунда?

3

Көтмим инде тормыштан һичнәрсә,
Үткәндә юк берни кызганасым;
Җанга ирек, тынгы эзлим!.. Килә
Онытылып йокыга таласым!

4

*К.Б.*

Ләкин кабер йокысына түгел...
Шундый мәңгелек йокы телимен –
Яшәү көче, тынып, черем итсен,
Сулу алсын күкрәгем, тилпенеп.

5

Төннәр, көннәр буе татлы тавыш
Сөю турында җыр сузса икән,
Яшеллеккә мәңге керә-керә,
Шауласын иелеп куе имән.

* * *

Мин яшәргә телим! сагыш телим
Сөю-сәгадәткә үч атып;
Акылымны шулар узындырды,
Маңгаемны артык шомартып.
Вакыт, вакыт тынгылык томанын
Кудыртырга зәһәр көлүдән,
Газапларсыз шагыйрь яшимени,
Давылларсыз океан кем күргән?
Газап, зарыгулар исәбенә
Ул яшәргә тели... Аңлы юл...
Ул тавышлар сатып ала күктән,
Дан-шөһрәтне бушлай алмый ул.

* * *

Тыңла әле, без мәңгегә китсәк бергә
җаныбызга суык өргән шушы җирдән,
алдашулар юк бер илдә, бәлки, бик тиз
булырбыздыр син фәрештә, ә мин иблис.
Әй сөеклем, син вәгъдә бир – шундый чакта
җәннәт назын онытырга минем хакка.
Язмыш сөргән кеше сиңа җәннәт булсын,
сине миңа иксез-чиксез галәм кылсын!

*Федор Тютчев*

* * *

Сүзебезнең ни булып кире кайтасын
Бирелмәгән безгә алдан белеп тору –
Бәрәкәт ничек бирелгән булса безгә,
Мәрхәмәт бирелүе дә шулайдыр ул.

* * *

Акыл белән Россияне булмый аңлап,
Үлчәп булмый күнегелгән аршын салып:
Ул үзенә бер бөтенләй башка калып –
Россиягә була бары тик ышанып.

* * *

*К.Б.*

Очраттым да сезне – бар үткәннәр
Туңган йөрәгемдә терелде;
Алтын чорлар искә килеп төште –
Һәм җылыга йөрәк төренде...

Шундый көннәр була һәм сәгатьләр –
Җирдә инде көзнең салкыны,
Яз аңкышы кинәт чыга да, һәм
Нидер куя бездә талпынып, –

Җаным тулы теге елларның мин
Җилләренә биреп үземне,
Күптән онытылган ләззәт татып,
Ала алмыйм сездән күземне,

Әйтерсең лә безне аеры тоткан
Гасыр аша, сихри төш аша
Карыйм сезгә – җаным теге чакта
Сез кабызган хискә тоташа...

Хатирәләр генәмени соң бу,
Тормыш үзе җырлый кабаттан, –
Шул ук балкыш сезне нурландыра,
Шул ук сөю мине яңарта!..

* * *

Хыянәт итә башлагач
Какшый барган көчләребез,
Без яңа килмешәкләргә
Урын бирергә тиешбез, –

Шулчакларда коткара күр,
Мәрхәмәтле даһи, кызып
Әләкләүдән, сүгүләрдән
Үзгәргән тормышыбызны;

Яшерен үчләшүләрдән
Яңарып барган дөньяга,
Анда яңа кунакларга
Табын корган, шәраб ага;

Агымда булмауны сизеп,
Селтеләнеп ачынудан,
Анда башка омтылышлар
Һәм бүтәннәр бара алда;

Һәм башка шундый нәрсәдән,
Чөнки күптән мәгълүм соңы, –
Карт гыйшкыннан хурлыклырак
Бәйләнчек картлык ярсуы.

* * *

Бар нәрсәмне алды җәзалаучы Аллаһ:
Саулык, йокы, ихтыярымны алдырды,
Үзен зурлап гыйбадәт кылдыртыр өчен,
Яннарымда бер сине генә калдырды.

## ДЕКАБРЬ ИРТӘСЕ

Ай әлегә күктә – төннең
Күләгәсе хәрәкәтсез,
Хөкем сөрә, уйламый да
Талпынуын көннең эзе.

Ялкау гына, кыймый гына
Нур арты нур туа анда...
Ә күк әлегә тулаем
Балкый төнге тантанада.

Ике-өч мизгел дә узмас,
Җир өстеннән төн таралыр,
Һәм көндезге дөнья безне,
Кинәт балкып, биләп алыр...

* * *

«Төтене дә Ватанның безгә хуш һәм татлы!» –
Диеп әйткән үткән гасыр шагыйранә.
Безнекендә – эзли талант кояшта тапны,
Сасы төтен белән Ватанын ыслый әнә.

* * *

Уянмаган бу халыкның
Бу томана өеренә
Кайчан килерсең, Азатлык,
Алтын нурларга төренеп?..

Сирпелер нурың, терелтер,
Йокың томанын җилгәрер...
Тик карт, черегән яралар,
Золым һәм үпкә җөйләре,

Җан аздыру һәм йөрәктә,
Һәм аңда бушлык изасы, –
Кем соң шуларны дәвалар?..
Син, Гайсәнең пакь ризасы...

*Владимир Маяковский*

## Ә СЕЗ БУЛДЫРА АЛЫРСЫЗМЫ?

Мин бердән бутадым көннең карталарын
стаканнан буяу сибеп җибәрдем дә;
океанның чыгынкы битендә яңагын
күрсәттем мин бер табак дерелдәвектә.
Тәңкәсеннән калай балыкның укыдым
яңа иреннәр дәшүен, сабырым сынып.
Ә сез
яңгыр торбалары флейтасында
берәр ноктюрн
уйнап бирә алырсызмы?

## МЫСКЫЛЛАУЛАР

Фантазиямне тавис койрыгыдай кабартам да
җанны атам көтелмәгән рифма өере иркенә.
Тегеләрнең –
үзләрен туендырган имән тамырын
танау белән актаручыларның –
гәзит баганаларында ыржайганнарын
яңадан ишетәсе килә.

## ЯЗ

Шәһәр кышкысын салды.
Селәгәен тыймый кар кере.
Тагын да яз. Хәтерләтә салкын,
аңгыра, сафсатачы юнкерны.

## АЙЛЫ ТӨН

*(Пейзаж)*

Ай булачак.
Инде
беленә.
Менә эленде дә тулы укасы.
Аллаһ, ихтимал,
гаҗәеп
көмеш кашык белән
болгатадыр йолдыз ухасын.

## ТЫҢЛАГЫЗЧЫ!

Тыңлагызчы!
Әгәр дә йолдызларны кабызалар икән,
димәк, бу кемгә булса да кирәк?
Димәк, кемдер аларның булуларын тели?
Димәк, кемдер шул төкерекчекләрне
энҗе бөртекләре дип атый.
Һәм, челлә тузаннары давылында
хәлдән таеп,
Аллаһ янына бәреп керә,
соңгардым дип, куркып,
елый-үкерә,
аның сеңерләнеп калган кулларын үбә,
һәрвакыт бер генә булса да йолдыз булсын дип
үтенә! –
Йолдызсызлык газапларын
күтәрә алмаячагына ант эчә!
Ә соңыннан,
тыштан тыныч күренсә дә,
сыза эчтән.
Кемгәдер сүз ката:
«Хәзер сиңа ярыйсы ич?
Куркыныч түгел һич?
Әйеме?»
Тыңлагызчы!
Әгәр дә йолдызларны кабызалар икән,
димәк, бу кемгә дә булса кирәк?
Димәк, бу мөһим эш –
һәр кич
өй кыеклары өстендә
бер генә булса да йолдыз кабыну?!

*Сергей Есенин*

* * *

Тәрәздә тулган Ай. Тәрәзне җил какты.
Яфраксыз тупылкай көмештәй яп-якты.

Бер тальян ялгызы сыкрана ерактан –
Җанымдай кадерле һәм ерак йөрәктән...

Елый да, көлә дә, бәгырьгә дә үтә.
Кайда соң син, юкәм? Йөзьяшәр төз юкә?

Үзем дә кайчандыр бәйрәмдә таң-иртән
Тальянда уйнадым, ишетсен дип иркәм.

Ә хәзер аңарга берни дә түгелмен,
Ят җырга кушылып көләм, яшь түгәмен.

* * *

Гөлләр миңа «Хуш! Хуш!» диләр,
башкайларын тәмам иеп,
аның йөзен, туган ягың
мәңге күралмассың диеп.

Әй, сөеклем, бәлки, бәлки!
Ә мин күрдем, бәлкем, аздыр...
Бу җан чыгу тетрәнүен
кабул итәм яңа наз дип.

Гомер сөрү асылына
җиткәнгә күрә елмаеп,
«Бөтен нәрсә кабатлана!»
дип әйтәмен мизгел саен.

Барыбер ич – килер бүтән,
сагыш күммәс киткән ярны,
яхшырак җыр бүләк итәр
кадерлемә яңа пары.

Сөеклем, җыр тыңлый-тыңлый,
яңа яр белән янәшә,
кабатланмас бер җыр итеп,
искә алыр мине дә, шәт.

* * *

Күл суларына чигелде таңның ал төсе.
Имәнлектәге суерлар җибәрде үксеп.

Кайдадыр шәүлегән елый, куышта ятып,
Мин генә менә еламыйм – күңелем якты.

Беләм ич, кичен чыгарсың юллар аркылы,
Утырырбыз чүмәләгә кибән артына.

Исерткәнче үбәрмен мин, гөлдәй изәрмен,
Кем гаепләр куанычтан сәрхуш исәрне?..

Назга чыдамый салырсың фатаң ефәген,
Таңгача куак төбенә алып китәрмен.

Имәнлектә елый бирсен шунда суерлар,
Таң-шәфәкъ алсулыгында хозур сагыш бар.

*Анна Ахматова*

* * *

Аккош булып йөзде даным,
төтен аша сөзелеп.
Ә син, сөю, һәрчак булдың
минем өметсезлегем.

## ИСЕМ

«Татарское дремучее
Пришло из никуда...»

Татарныкы, каракуе,
Килде беркая яктан,
Һәр бәлага ябышучан,
Үзе дә – бәла хәтта.

## ИКЕ ЮЛЛЫ ШИГЫРЬ

Башкаларның мактаулары – көл генә бары,
Синең яманлавың хәтта – мактаудан ары...

## КАРА ЙӨЗЕК ТУРЫНДА ӘКИЯТ

1

Татар әбиемнән миңа
Бүләкләр бик сирәк тиде;
Чукындырылуым моңа
Үкенечле сәбәп иде.
Үләр алдыннан кызганды,
Хәтта бераз юмартланды,
«Аһ, гомерләр! Оныгым да
Өлгерде», – диеп уфтанды.
Кичерде яман холкымны,
Бүләк итте кара йөзек.
«Аңа килешә! Тормышы
Күңеллерәк булыр, төзек».

2

«Кайгы мулдан, ә бәхет аз», –
Диеп әйттем дусларыма;
«Йөзегемне югалттым», – дип,
Йөз яшереп кулларыма
Чыгып киттем. Алар әйтте:
«Йөзекне эзләдек ныклап
Наратлар үскән аланда,
Диңгез буенда комлыкта».
Дусларымнан бер кыюы,
Аллеяда куып җитеп
Үгетләде: караңгыга
Хәтле монда сабыр итик.
Бу үгеткә исем китте,

Һәм ачуым чыкты бигрәк
Күзләре назлы булганга:
«Ә сез миңа нигә кирәк?
Сез көлә генә беләсез,
Сез маһир мактанышырга,
Монда чәчәкләр ташырга».
Һәм куштым таралышырга.

3

Кайттым якты куышыма,
Ыңгыраштым ерткыч коштай,
Аудым да караватыма
Хәтеремне эшкә куштым:
Кичке ашта утырганым
Күзенә карап-табынып,
Ашамавым һәм эчмәвем,
Күрмәвем имән табынны,
Чиккән эскәтер астыннан
Кара йөзекне сузуым,
Аның күземә каравы,
Чыгып, болдырга узуы.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Килмәсләр табылдык белән!
Ерак җитез көймә эзе,
Җилкәннәре аксылланды,
Алсуланды күкнең йөзе.

*1917–1936*

*Максим Горький*

* * *

Хәрәкәтсез, гамьсез тыныч тынлык
Тауның салкын ташын кочкан мәлдә,
Бөек сергә җаның колак сала
Диңгез дулкынына якын хәлдә.
Кояш дискы диңгезләргә чумган,
Һәм болытлар канлы-кызыл...

*1906–1919*

* * *

...Кояш, Дөреслек – тәңгәл, ди...
Мин кояшта таплар күрәм.
Дөреслек, таплы булса да,
Күңелгә рәхәтлек бирә.

*18 декабрь, 1905*

*Игорь Северянин*

## ХӨКҮМӘТКӘ ПОЭЗА

Бөек шагыйрьләрен ипләп зурламаса,
үзен дә ул үзе хөрмәт итми ласа,
танылуга илткән юлга вето баса,

йөзенә келәймә суга хөкүмәт.

Рәссамнарын пушка янына бастырса,
иңнәренә авыр мылтыклар астырса,
үз баласын палач кулына тапшырса,
жандармны хәтерләтә хөкүмәт.

Мохтаҗлыкка тәмам баткан язучыга
субсидия салмыйча сузган учына,
әдәплеләр алар диеп, бик тә чыдам,
дошманлык кына арттыра хөкүмәт.

Цензура белән янаса хәкименә,
хурлык корымына буялып кимендә
(шигырь белән бу эшкә булышам мин дә),
таратылырга лаеклы хөкүмәт.

Даһиларын җәберләүгә күнә-күнә,
тыныч кына карап торса дүнә-дүнә,
әнә шундый вандаллар хөкүмәтенә
хаклы рәвештә лаектыр җәмгыять.

*Марина Цветаева*

* * *

Ике кояш сүнә – йа Ходаем, кичер, кызган! –
Берсе – күктә, икенчесе – күкрәгемдә, сызлап.

Шул кояшлар – кичерәмме, әллә аз булырмы? –
Шул кояшлар мине акылымнан яздыруны!

Суыналар алар – авырттырмый нурлар агып!
Беренче булып сүнәр аларның кайнаррагы.

*6 октябрь, 1915*

* * *

Әйтерсең лә уң кул белән сул кул,
Синең җаның минем җанга якын.

Кушырылганбыз, җылы һәм рәхәт,
Әйтерсең уң канат һәм сул канат.

Өермә калка – һәм упкын ача
Уңыннан канатның сулынача!

*19 июль, 1918*

*Николай Заболоцкий*

## ЯЛКАУЛАНДЫРМА ҖАНЫҢНЫ

Ялкауландырма җаныңны!
Су төймәсен дисәң киле,
Җан хезмәт итәргә тиеш
Көне-төне, төне-көне!

Каула аны йорттан йортка,
Этаптан этапка сөйрә,
Такырга, чытырманлыкка,
Кар көртенә керә-керә.

Таң йолдызы яктысында
Аунатма аны түшәктә,
Тот иренчәкне күбектә
Тезгененнән урап шәпләп!

Беразга эштән бушатып,
Үзсендермәк булсаң аны,
Синең соңгы күлмәгеңне
Кызганмыйча йолкып алыр.

Иңнәренә аның ябыш,
Интектер – күрсен күрәсен,
Кабат кешечә яшәргә
Ул синең белән өйрәнсен.

Ул колыңмы, ул патшаңмы,
Ул оланың, хезмәтчеңме,
Ул хезмәт итәргә тиеш
Көне-төне, төне-көне!

*Ярослав Смеляков*

## РУС ТЕЛЕ

Синең фәкыйрь бишегең янында
чак ишетеп хәтта үзләрен,
Рязань хатыннары җырлаганнар,
тамызганнар энҗе сүзләрне.

Корымланган лампа яктысында
кабак өстәленә иелеп,
тулы чәркәсенә кагылмыйча,
ямчы йоклап киткән, сыенып.

Ватык тоякта да атладың син,
яндың староверлар утында,
лакан, бадьяларда юылдың син,
чикерткәдәй мичтә утырдың.

Төн карасы сеңгән болдырларда,
кичке нурга куеп йөзеңне,
син Кольцовның балдагын юнәттең,
Курбскиның алдың йөзеген.

Авыр чагыгызда, ата-бабам,
изге ликны онлап артык сез,
ул узгынчы татар телен салып,
рус тегермәнендә тарттыгыз.

Немецтан да бераз алдыгыз сез,
күбрәк булганда да яраган,
аңа гына эләкмәсен өчен

гыйлем халык дигән шөһрәт-дан.

Син бурсыган сарык тиресе һәм
әче куас исле дә булдың,
күмерләнгән чыра, ап-ак аккош
кавырсыны белән язылдың.

Син үлчәүдән, бәяләрдән өстен
кырык бердә, соңра кыелып,
кадак белән немец зинданында
дивар известена уелдың.

Хөкемдарлар юкка чыга торды,
эзләре дә җирдә калмыйча,
рус теленең асылына тигәч,
аны-моны абайламыйча.

*Арсений Тарковский*

* * *

Төнлә вакыт акрын бара узып.
Кәбисә ел бетә, төкәнә.
Карт нарат тамырлары янә
Тоялар сумалалары бозын.

Миңа көнлек мәшәкатьләр җиткән,
Башка бәхет миңа кирәкми.
Беләм: анда койма терәтеп,
Кемдер елы җиткән ахыр чиккә.

Беләм: яңа урман калкып бара,
Безнең наратларга тоташып.
Тамырлары белән укмашып,
Үз нәүбәтләрен алар тоялар.

*Михаил Львов*

## СЕЗНЕҢ КҮЗЛӘР

Туганнарым, азиатлар,
Аңлый алмыйм мин һаман:
Учаклар төтәгәнгәме
Күзегез кысык калган,
Йә яшен-укларыгызга
Чыдамасын дип калкан
Җәя тартканга мәңгегә
Күзегез кысык калган...

*Станислав Куняев*

* * *

Дәшмибез, эшлибез, җырлыйбыз,

Яшибез сагышлы мәзәктә,
Сугар да сәгате – һәм килер
Бер давыл һәм салыр газапка:
Сугышмы, башка бер афәтме
Җандагы гамьсезлек тынчуын
Болгатыр, актарыр, чайпалтыр –
Күрсәтер намусның чын суын.
Һәм шулчак без мәҗбүр булырбыз,
Шар ачып җаныбыз капкачын,
Расларга: без чынлап – гүзәллек
Һәм кырыс хакыйкать яклаучы.

*Эдуард Балашов*

* * *

Бернәрсә дә аңламыйча,
Үз-үзеңне кочаклыйсың.
Ничаклы яратсаң аны,
Аңлыйсың да шулчаклы син...

* * *

Барсы да бар: җеп һәм болын.
Җеп сапларга, дускай, җитеш;
яз килде, аңа болында
син матур чәчәкләр чигеш.

*Иван Переверзин*

* * *

Вакыт сагындамы, әллә
юкны бушка төйисеңме –
язмыш үзе әйтеп бирә
чынлыгын шигъри хисеңнең.

Мөһим түгел, ничә тәүлек,
ничә еллар сәях булып
аңа таба сукмак ярдың,
татлы хыялга омтылып.

Шигырь юлың сөекләңнең
дулкынландырса йөрәген –
шунсы мөһим, шунсы дәва,
шунсы бәхетең терәге.

## КАЕН ЫШЫГЫНДА

Син янымда! Күз яшьләре...
Яңадан элеккечә.
Алтын каен ышыгында
бүген безне төн коча.

Сүзләр түгел, ә иреннәр,
куллар дәртне котыртсын,

тормыш кабахәтлегенең
агуын оныттырсын!

* * *

Яшәү булам, үлем булам,
бөтен нәрсә була алам,
хәтта дәртле кайнау булып,
поэмага тула алам.

Бирә алмам кайнар төннәр
дәртен бары сиңа гына,
чөнки син эредең инде
былтыргы кара кар сыман.

Яшәү белән бәхәсләшмим
яшәү мәгънәсе хакында,
чөнки үлем саклап тора
бер адымда... бик якында...

* * *

Кичә генә җан ышана иде –
аңа бүген берни кирәкми.
Синең яктың булмаганга күрә,
хата күмгән булган йөрәкне.

Яктылыгың хәзер күзләремнең
карасына кереп кипмәкче...
Яшен ташы булып өтсәң өт син,
тик сөюдән мәхрүм итмәче!

* * *

Ир һәм хатынмы без, сөяркәме?
Икесе дә! Шуңа – аңладым –
хәтта төньяк бураннары безне
аерып-каерып ташлый алмады.

– Җанкисәгем, сине шундый сөям! –
дип әйтәм дә җавап ишетәм:
– Ахырзамангача минем җаным
синең йөрәгеңне иш иткән!

* * *

Хуш! Мин китәм! Көнчелегем
ишекне тыштан япты...
Шәһәр. Кырлар. Төннәр. Таңнар.
Көннәр. Караңгы. Якты.

Тукталдым. Карыйм: Россия
буйлап адашып йөреп,
мин кабат бире кайтканмын,
безнең җәннәтне күреп, –

синең миңа «Сөям!» дигән,
«Мин дә!» дигән урынны...
Елга вокзалы түтене
шулчак җанга орынды,

күмде ярларны, урманны,

биләде гомеремне.
Ни әйтсәм дә – сагыш булыр.
Канатта – моң сөреме.

* * *

Урман-таулар аръягында узды гомер.
Күкрәктә суыклар исе.
Алдашмыйк ла мәхәббәтебез исән дип.
Артта калды аның хисе.

Каш астыннан карап, берьялгызым йөрим –
үз-үземә урын тапмыйм.
Күкләргә бик биек, җырларга бик ерак,
ә үлем чалгысын таптый.

Чалгыгаябышсам, учларым киселсә,
коена калсам канымда...
Түгел лә! «Мин сөям!» дигән сүз үлемне
кертмәс минем җаныма.

* * *

«Юк!» дигәнең иң суык суыктан ныклы,
ул болыт булып каплады яктылыкны.

Тик бер йолдыз миңа Җирдә юламандыр...
Юлым минем... мин Себергә юл саламдыр.

Аю түгел бу дәһшәтле үкерүче,
бу – бураннар иясенең яман көче.

Елдан елга, юлдан юлга... Җиңел түгел –
ак карларга егыл да үл, егыл да үл!

Һәм үлгән дә булыр идем инде мин, шәт,
«Тор инде!» дип, караңгыдан кызым дәшә...

## КОШ

Аһ, дускаем, тагын миңа җәфа
чигәсе дә икән чигәсе:
күзләреңне – дала-диңгезләрне –
каргыйсы һәм... янә үбәсе!..

Кулга ияләшкән коштыр диеп
уйладым мин сине – ялгыштым...
Буйсынмыйсың, үлеп яратсаң да.
Син ирекле, азат – күк кошы.

Син таңнарда сөю җимнәреннән
татырга дип килеп кунасың,
кометадай, күкләр кочагына
ыргыласың һәм юк буласың.

* * *

Кара кургаш кебек кап-кара төн.
Хисләр дөньясында җәй үткән...
Мин-җанлыга килеп сыендың да
этәрелдең миннән-мәеттән.

Җан өшеткеч курку тавышыннан
челпәрәмә килде өебез,
һәм таркалды бергә җыйган бәхет,
һәм өзелде матур көебез.

Өнсез, сүзсез калды фани дөнья,
суык йөрде ике арада...
Һәм көзгеңнән чаларган һәм шашкан
карт бер карчык сиңа карады.

## МӘРМӘР

Ефәк иңнәреңнән ефәк күлмәк
шуып төшкән чаклар... Сагынам...
Куеныңда йоклап китә идем
һәм уяна идем сабыйдай.

Кымшанмыйча карап ята идем
чигәңдәге миңнәр сурәтен,
керфегеңнән күзне аерырга
җитми иде минем куәтем.

Тире астындагы кизләүләргә
лаек икән нинди гомерләр?!
Һәм кулларның дәртле бөҗраларын
ниндидер көч өзә-җимерә...

Гәрәбәдәй иртә түшәгендә,
тыңлый-тыңлый буран әргәнен,
тораташтай катып калабыз без,
әйләнәбез кинәт мәрмәргә.

Ә идәндә зур аю тиресе
хатирәләр булып кочаклый.
Безнең исә җып-җылы сыныбыз
йөрәк аша чатный шулчакны.

Аһ, мәхәббәт! Мәрмәр астында да
турылыклы калыйк без аңа...
Үземнекен сызланмыйча бирдем,
ә синеке миндә сызлана.

*Евгений Семичев*

## «БҮРЕ КОЯШЫ» ЦИКЛЫННАН

* * *

Тешләремне кысам – һәм дә ләм-мим.
Кем ул тәрәз тирәсендә йөри?
Соры бер йомгактан көтмәгәндә
үсеп чыкты чып-чын ата бүре.

Кайчандыр ул көчек кенә иде,
күзләре дә сары, ваемсызлар,
койрык – алка, очлы колаклары
тырпайганнар, ләкин тынгысызлар.

Төннәрендә, мыштым гына килеп,
тәпиләрен биткә ышкый иде.
Йокы аралаш ул ыңгыраша,
тулган Айга карап шыңшый иде.

Сулдан көрәп салмак кына килә,
терәлә дә миңа, кала тынып...
Шулчак мине ул ярата иде,
хәзер карый менә бүре булып.

Ул ышанмый миңа бер тамчы да.
Күзләрендә явыз нурлар уйный.
Аның белән хәзер хәтта төштә
очрашмавың хәерле дип уйлыйм.

* * *

Өерем тибәргән яралы бүре мин,
беләмен, беләмен рәт-юнен шигырьнең.

Төннәрен йөрәгем сызлана нәрсәдән?
Йөрәгем янында сыкранган ядрәдән.

Түгел бу саташу, аң-акыл ду итү:
үлем һәм яшәүнең бәхетле дуэты.

Мин Айга юнәлтсәм сызлауның кайберен,
һәм ике тавышка улаша шул бүрем.

Тавышым көйлимен мин аның җырында –
йөрәгем, ишетәм, йөрәккә орынган.

Йөрәктә бу дуэт яңг(ы)раган чакта мин
оргач та орылып бетмәгән... шагыйрьмен.

* * *

Умрау сөягемә типте йөрәк,
суык чымырдатты канымны.
Төшкә кергән ана бүрене мин
күзләреңә карап таныдым.

Яраларны ялап дәвалауның
ул өйрәтте төрле-төрлесен...
Без уралган томаннан да хәзер
аңкып тора синең сөт исең.

Биек, текә ярда, папиросның
төтенедәй, Ай да сүсәрде...
Салкын күктә йолдызлар җемелди,
әйтерсең лә бүре эзләре.

Мин таныдым сине, ана бүре,
утлы, кысык күзең нурыннан.
Ә ул нурлар миңа Ходай биргән
таң балкышы булып орына.

* * *

Туйдырды ла – өем почмакларын
буйдак күз яшьләре чылата.

Йөрәгемне төпсез чоңгылыңа
көчек итеп аттым-югалттым.

Бурлы айгыр булып, гөмбәз буйлап
йөгерер Ай, юртып аз гына...
Ә төн бүре тиреләре сыман
ятар синең аяк астыңда.

Күзләреңдә якут нурлар уйнар,
яшен кебек тетрәр кашларың,
бүре җиләгенең серле төсен
син каныма куша башларсың.

Сине, каракүзне, үбә-үбә,
күзен кагылдырмый ятларның,
азиат түшләр арасында, урда,
бүре баласыдай ятармын.

Бүлешермен кыска төнеңне һәм
бүре җаны сыман сагышны
ядрә очкан кебек тиз, хайвани
шатлык хисабына алышып.

* * *

Күз карашың тирән кое кебек,
якты көндә кояш күренми.
Якты көндә ләкин Ай күренә,
күз караңа керсәм иренми.

Мин тын өрсәм сузып, «Диана...»* дип,
океаннарда вулкан уяна,
көмеш тузан итеп сибә көлен –
диңгез төпкелендә Ай яна.

Галәм упкынына ташлый Аллаһ
шау чәчәкле чия ботагы,
һәм «Киек Каз Юлы» пәйда була,
кошлар оча гамьсез буталып.

Кометалар зәһәр бүре кебек
улап үтә, йолдыз коела.
Томанлыкка кереп, күз нурлары
адашырлар кебек тоела.

Ә рус ирләренең карашында
лачын күзендәге үткерлек.
Күзләрдәге канлы яшьләр аша
бүре кояшын да күрерлек.

* * *

О, шәрыкнең зәһәр мәхәббәте,
бүре авызы күк хәтәре!
Зинһар, язмыш, миңа каты булма
һәм югалтма мине хәбәрсез.

Гыйш-гыйшрәтле утлы карашыңда
ерткыч тамагының эңгере...
Тиккә түгел, кореяле бабаң
эт ашауның шактый өлгере.

Телгәлисең минем йөрәгемне...
Ә соңыннан, уңайсызланып,
моңлы Айга карап улыйсың син
сагышыңнан, ахры, сызланып.

Ә йолдызлар, сарык көтүедәй,
гөмбәз болынында утлыйлар.
Ә илаһи хиснең дулкыннары
текә рус ярында туктыйлар.

* * *

Үле бүре күзен күрсәм,
җанны үкенеч ашый.
Каерылган теш казнасына
типми ботинкам башы.

Гыйнвар көртен кайнар канга
буяса да кемнәрдер,
ул – бүре башы астына
күкнең салган мендәре.

Ул бүген дә, иртәгә дә
куркыныч түгел инде.
Ерткыч җаны күкләрдәге
тыныч ояга менде.

Агачлар селки ботагын,
хушлашып салкын кичтә...
Ышаныгыз, кыргый ерткыч
кызганыч түгел һич тә.

Ә аучы менә кызганыч, –
акылданмы, хистәнме...
Тегеп кигән бүре бүрек
аңа акыл өстәми.

* * *

Куркак ялагайлар тавыш-тынсыз.
Азиядә бер ил сытылган.
Кремльнең тешле диварлары
бүре авызыдай – кызыл кан.

Россия, син – имезүче бүре.
Ачлык шакылдата тешеңне,
Һәм ияргән сиңа ундүрт көчек,
башкарасың изге эшеңне.

Ана исен тоеп бара алар.
Имин алар синең ис барда.
Танауларын гарепкә боралар
артык сөтне шунда косарга.

Синең каның алар венасында.
Уйнап, алар җилкә тешләшә.
Имчәгеңнән суверенлаша да
сиңа өрә, сиңа телләшә.

Ә комсыз күз туганлыкны таный,

борын сизә кардәш кан исен.
Синең өер алар, һәм ерткычча
сине сөю хисе, җан хисе.

* * *

Әй, Россиям, империям минем!
Янып беттең тәмуг утында.
Державалы* алтын тәлинкәңнән
көйгән кырыйлары куптылар.

Дулкыннары бүре сыман чапкан
диңгезләрең синнән чигенде...
Акыл булмаганга, баш эчеңдә
ватыкларың гына чыңгылдый.

* * *

Туган ил һавасы – яз һавасы –
серле шифа итеп сулыймын.
Җиргә кунган мәләккә әйләнеп,
җәннәт багларын мин буйлыймын.

Ул канымда минем уттай кайный,
мең ярчыкка яра йөрәкне.
Шул һаваны тәүге сөю итеп
сулау серен бүре өйрәтте...

Тын алуны кичектереп булмый –
шатлыкмы ул, әллә хафамы...
Беркемнең дә, бугазы көйсә дә,
сулап туйганы юк һаваны!

*Равил Бохараев*

* * *

Инеш тә чишмәләренә –
кирегә акмый-түгелми.
Куанып әйтәм, Ходаем,
беркемнеке дә түгел мин.

Кабат туган ил булырмы,
ят илләргәме юл тотам,
үз-үземә чит илнеке
булып калам, кичер, Ходам.

Телсезлеккә дучар итеп
яңабаштан үз-үземне,
хокук алам аңламаска
ике дистә тел сүзен мин,

ачык әйтелә алсын дип
кан саркыган, изгелексез
сүзләр белән зәһәр итеп,
тегенди түгел, мондый сүз.

*2000*

* * *

Көчлеме, юкмы көчәнү, –
эш аның белән үлчәнми.

Көчсез шагыйрь булмавыңны
казаныш түгел дип таны.

Руда хакына күпме таш...
Юллар – тоташ уалган таш...

Тик гамәлен кыла кеше...
Ә калганы – Аллаһ эше...

*1992*

* * *

Җанымны җибәрче иреккә.
Беркая китәргә базмамын.
Бу мескен, бу юеш бакчада
булды бит язмышка язганы.

Мондагы бар шәүлә, бар тавыш,
бар сукмак күңелгә береккән.
Даны да, газап та кирәкми –
җанымны җибәрче иреккә.

Бары тик теләнче иреген
теләнә аламын оялмый.
Мин күрдем сызлану балкышын
һәм моннан беркая киталмыйм.

Күктәге кырларга юл тапмам –
мин кичә алмамын чикләүне.
Иреккә җибәрче җанымны.
Мин инде беркая китмәмен.

*1989*

* * *

Көненә йөз үлә алам:
җиттем чиккә.
Тирәмдә туганнар кайный,
ләкин читләр.

Мин юанам – тормыш әйбәт!
Менә сере!
Җан үләргә әзер икән,
димәк, тере.

## ЯҢАРЫШ

Беләм катгый хакыйкатьне.
Язмышында язылганның
үтә трагик камиллеге
кристалл кебек ачык аның.

Әмма сәнгатьтә һәрвакыт
бер яңарыш хокук эстәр:
мин һәр сүздә үләмен дә

туам яңадан һәр хистә.

## ТӨНГЕ ТӘРӘЗӘ

Мин капладым агачларны, юлны, Айны,
күпер чатын, каршыдагы теге йортны –
тәрәзәгә ябышкан чагылышыма
үземнең үк күз нурларым сеңде-йокты.
Көндезләрнең көзгеләрен урап йөреп,
төннең манзараларына берекмичә
тәрәздәге Ай-йолдызлы дөньяларга
сурәтемне өстәдем мин әллә ничә.
Күзең белән тәрәз чиген ватып кара!
Өсте – күкне,
асты җирне кисеп куя,
уң якка да, сул таба да юллар ябык,
чарасызлык авыр хистән сүзләр коя.
Ничаклы сүз инде шаулап агып китте,
бугазымда ләгънәт тора, җанны ашап...
Ыргылырга йолдызлы күк киңлегенә,
бәреп чыгып пыяла һәм үзем аша!

*Наталья Астафьева*

* * *

Үрентечек,
Яфракчыгым,
Җып-җылы бөрем...
Бәлки, кыздыр,
Бәлки, улдыр –
Белми дә йөрим.
Минем җаным,
Тамчы каным,
Таң йолдызчыгым,
Әле яшерен
Куанычым,
Күм-күк бозчыгым.
Туфракка бөртек төшкәнгә
Беренче атна.
Тәнемдә бәләкәй кояш
Җылытып калка.

*Николай Рачков*

## «СЛАВЯН КЫРЫНДА» ЦИКЛЫННАН

* * *

Төтен аша утлар балкыймы ул,
канап туа мәллә яңа таң?
Безне тагын саттылар, Россия,
без берьялгыз калдык яңадан.

Бәхәсләр һәм үпкәләшләр бетәр,

чакыр да син безне берләштер –
искә төшсен Минин, Пожарский
һәм аларның изге көрәше.

Өметебез бары Богка гына,
хаклык эше мәңге бозылмый.
Россиянең аның үз язмышы,
Россиянең аның үз юлы.

Чит-ят көчләр безнең өчен хәтәр,
җиңелмәбез хөрлек рас көйгә.
Улларыңны бердәмлеккә чакыр,
ишетәсеңме безне, Россия?

* * *

Коточкыч суешлардан соң
йөздән бер исән калган
сугышчы күк, үр иңендә
кан-кызыл миләш калкан.

Әремле ярларда таңда,
тузган җилән сүсәртеп,
кипкән аир* бу дөньяга
карап тора гусар күк.

Кичүләрдә, утлы суда
кырылган, ярда калган
солдатлардай, үлән, яфрак
салкын йокыга талган.

Һәм шулай, хушлашкан кошлар
иңрәүләренә тарып,
табигать кайчак искәртә
тарихын халыкларның.

## ИЛЬЯ МУРОМЕЦ

Утырдың утыз һәм тагы өч ел, Илья,
ялангач кирпечтә, зарланмадың иллә.

Утыз һәм тагы өч ел эшсез яттың син,
иртә-кич тәрәздән карап юл яктысын.

Сөрер дә идең ич, урыр да идең ич,
тик мичтән төшәргә таба алмадың көч.

Ишетәмсең – күкләр гөлдери? Тизрәк син
православча чукын – рухыңны төзәтсен.

Тустаган тутырып, син чишмә суы эч!
Сизәмсең – көч керә? Көч җирдән керә ич.

Баһадир куәте уйныйдыр каныңда,
тояклап җир казый атың өйалдыңда.

Хак-кылыч та әнә! Илья, ал кулыңа.
Соловей мәлгуньне юк ит ил юлыннан.

Тирә-юньне талап, мактана ул кансыз:
өч кенә сызгырам – калачак Русь намсыз.

Хисапсыз батырлар салдылар башларын,

авыллар, шәһәрләр үчтеләр – таш бары...

Ятимнәр елыйлар, сыкрана туган җир,
вакыт бит: явызга тиешле җавап бир.

Чык инде син, Илья, ихатаңны ватып,
Һәм коткар җиреңне.
Гөлдери күк.
Вакыт!

## СВЯТОГОР

Не подняться из гробного склепа
Святогору во веки веков...
*Иван Бунин*

Юк, үлмәде, бүген дә ул тере –
мәрте генә шулай озак аның.
Сәгатең сукты. Уян, Святогор,
кадерле булса сиңа Ватаның.

Ниемә син таш табутка яттың
ил язмышыннан йөзең чөереп?
Дуслар елады, дошман елмайды.
Хәзер ташланды ерткыч өере.

Һәм Русь сыкранды... Фетнә утлары
киметмәделәр яулы көннәрне.
Безгә сузыла бүгенге көннәр
кыпчаклары һәм печенегләре.

Уян! Күтәрел! Таулар, болытлар
артыннан калык, күрен дошманга!
«Святогор исән... Һәм безнең козырь
басылды!» – дип, ул булсын пошаман...

## ПЕРЕСВЕТ СӨҢГЕСЕ

Яу тынлыгын
яшен шавы булып тишеп,
Пересветның изге сөңгесе дан алды –

дошманының аркасыннан
килеп чыгып,
яктылыкның аргы ягына кадалды.

Күкрәк тотып
үкерделәр җен-шайтаннар:
аны кире чыгармакчы була алар.

Юк андый көч –
Куликово кырындагы
ул сөңгене йолкып алыр өчен тагы!

## КУЛИКОВО КЫРЫ

Явыз дошман оя кора алмас монда.
Непрядвада ярлар – бугазларга сөяк.
Бар Россия – инде Куликово кыры,

канга күпме батты ласа туган төяк.
Күпме батты канга...
Кем ул кырда янә?

Куеп күкрәк, юлын бүлеп без,
сызлану һәм дан кырыбыз аша
беркем, беркем үтеп чыга алмас –
салдырмабыз яңа канлы эз.

* * *

Нинди генә урдалар кунакка
килмәделәр, кылыч тотып, Мәскәү!
Бүре сөякләрен ерып-тишеп,
чүп үләннәр әтрафында үсә.

Әллә кая уйлап чыгарылган
яшерен пружиналар басымы
канлы куллы табыш осталарын
өстебезгә өстерде, бассын дип.
Коллар! Табыш! Дан һәм Хакимият!
Соңгы тын һәм... сузылды аягы...

Кая гына бакма – анда канау,
кая төкермә – шайтан таягы.

* * *

Яңа цезарь* биредә
һәм яңа яшь брут**.
Кемдер яңа сатылган,
кемдер саткан яңадан.
– Син кем белән? – дип
улый алар торып
һәм тоталар якадан.
Минем җавап гелән:
– Үз җирем белән,
үз халкым белән...

* * *

Йа, җанны үзгәртеп кору,
хәтәр көпчәкле вакыт!
Күпме халыкны бәладән
Россия алды тартып,

үстерде, тәрбияләде.
Ә бүген исә алар,
вакыт гыйбрәтен онытып,
аны ук мыскыллыйлар.

«Югал, и явыз Держава,
хөкемгә аны!» – диләр.
Ә үзләре аның сөтен
имгәннәрен белмиләр.

Акыл эстәргә өндәмим...
Оятсызлан, көл әйдә...
Сизмисең – аяк астында
зур упкын булды пәйда.

Юк, без үпкә тупламыйбыз, –

Вакыт кануны әрсез.
Күпне кичтек һәм кичәрбез.
Карарбыз,
син нишләрсең?!

* * *

Сагышлы җиңүләр өчен
этиләрне хөкем итмә.
Дөрес юлны Ведалар да
әйтеп бирә алмый күптән.

Үткәнебез-кичәбездән
көлмә син оятсызланып –
анда безнең кабатланмас
моң, бәхет, өмет, сызлану.

Кайдан алдан белмәк кирәк:
безнең шатлык-кайгыларга,
көннәребез үтеп киткәч,
оныклар ничек карарлар...

Дулатмагыз айгырларны –
бөтен барлык тапталачак.
Йолыкмагыз тамырларны –
корыячак бөтен агач...

## ОНЫТМА

Тишкәләнгән, канга һәм тузанга
баткан безнең кызыл әләмнәр.
Без миллионнар идек, ә Җиңүгә
барып җиталмадык, адәмнәр.

Ярты гына көрәк тирәнлектә
медальоннар безнең яталар...
Әйе, без ул танкларда яндык,
әсирлектә башны ваттылар.

Әйе, безне астылар, кистеләр,
шартлап әверелдек тынлыкка...
Ләкин без ул, без ул пьедесталда!
Без җиңдек ул! Шуны онытма!

## СЫКТАУ

Бәлки, аракыдандыр ул –
йокладым, чәнчелегез...
...Диңгез уртасында каек –
ни кыймылдау, ни бер эз.

Бер урында, бер ноктада
әйләнә дә әйләнә.
Тирәсендә дулкынлана
моңлы чәчәк бәйләме.

Иксез-чиксез бу киңлектә
төш күрәмме, батаммы?..

– Тсс! Минем йөрәгем елый...
Төптә ята –
Ватаным.

*Валерий Шамшурин*

* * *

Барлык йолдыз сиңа балкыганда,
хөкем – бары илһам һәм сәләт.
Күреп алулары сине – әйбәт,
әмма хәтәр – күккә чөйсәләр.

Юк, андый эш һич шаяру түгел,
бәла агуына бал кушу.
Иң гайрәтле кайнар елларыңны
тончыктырыр даның балкышы.

Кыямәт көн җиткәч уянырсың...
Чик узылган, кире юл ябык...
Һәм үзеңнән үзең көләрсең син,
елый алмаганга, көч табып.

Шулвакытта сине юатырлык
беркем, берни булмас катыңда:
туган йортың, бакчаң кәлиткәсе,
ап-ак чәчле сөйгән хатын да...

* * *

«Бәлки, һич тә кирәкмидер
җен көлдереп дан алырга», –
дип кычкырам алгарышның
дуамал хуҗаларына.

Җаннары ишетсен диеп!..
Яктылык һәм караңгылык,
кое төбендәге кебек,
кушылды куркыныч булып.

Эшләр барып җитте шуңа:
акыллылыгың бәласен,
бәхәссез зарурият дип,
йөрәк түреңә аласың...

* * *

Әллә нинди вакыт килде әле...
Арынып булмый кара сагыштан,
әйтерсең без – туган җирдә качак,
үзебезгә үзебез яу-дошман.

Кем әле без?
Нинди эшләр өчен?
Нинди шатлык, бәхет хакына?
«Птица-тройка»* ягалайлап үтте,
кыңгыраулар тынды артында.

Һич югында, әрем бассын иде –
чүп-чар күмә көннәр, кырларны.

Көтү-көтү козгын оча, көтеп
безнең чәйнәшүләр корбанын.

* * *

Таныш моңнар колакка җитәләр,
иске җырлар кебек иркәләп.
Агачларның яшел кыңгыравы
дала өсләп шаңдый-тирбәнә.

Ни турында хәбәр сала бу шау,
борчу, сагышларны таратып?
Яфрак гөмбәзләрне җилләр чайкый,
агачларның җырын яңартып.

Имәнлекләр шавын тыңлау рәхәт,
күрү шатлык чалгың чабынын...
Артка карыйм – күрмим гомер башын,
алда күрмим бетәр чагын мин.

* * *

Тырышуым медаль өчен түгел,
язам сөеп, уйдан бүзәреп,
шигырь укысыннар диеп түгел,
укысыннар диеп үзләрен.

*Вадим Кузнецов*

СҮЗ

Океаннар саега,
диңгезләр үзгәрә,
йөз потлы якорьлар
калай күк күгәрә.

Уала сарайлар,
таудан тау аерыла.
Күзләргә тоз булып
утыра кайгылар.

Хаклыкка булышкан
сүз генә саклана.
Ел саен ныгый ул,
көн саен сафлана!

Утырам таңгача
кәгазьгә күз текәп,
йөрәктән кәгазьгә
иңәчәк сүз көтәм.

Диңгезләр гәрәбә
чыгарган шикелле,
вакытлар чайпалып,
миңа да сүз килер.

САЛ

Акрын,
акрын,
акрынрак тын ал –
Чиремештә* черем итә бер сал.

Кара төндә ап-ак бер төш
күрәдер, мөгаен:
имештер, ул – яңадан урман:
нарат, имән, каен.

Имештер, ул язга чыккан,
тора яфрак ярып...
Имештер, ул гомумән белми
Җирдә балта барын.

Имештер, сут уйнап ага
яфракка тамырдан...
Туган җирдә төшләр тәмле.
Тик... тиздән агарга...

Акрын,
акрын,
зинһар, акрын,
акрынрак тын ал...

## СМОЛЕНСК ДИВАРЛАРЫ ЯНЫНДА

Бу диварлар итәгенә
күмелгәннәр арасында
бер генә рядовой да юк –
полковниклар барысы да!

Таш өстендәге гөлләрдән
искән җилләр нидер эзли...
Әй, кадерле полковниклар,
гаскәрегез кайда сезнең?

Кайсы курганнар астында
ята алар тавыш-тынсыз,
танышырга да өлгерми
һәлак булган дусларыгыз:

яшьләр, картлар, урта яшьләр,
кара чәчле, сары чәчле...
Барысын сугыш җир буйлап
исемсез үр итеп чәчте.

Кабер ташыгыз өстенә
бер яфрак шәүләсе ятты...
Ял итегез, полковниклар,
намусыгыз тапсыз, якты!

Солдатларыгыз белән сез
кергәндә суга, ялкынга,
уйламадыгыз дәрәҗә,
данлы бүләкләр хакында!
Шөһрәт кушкан өчен генә
йә булмаса җиңел кулдан

сипмәдегез, полковниклар,
солдат башын уңга-сулга!

Җавап тотулардан куркып
качмадыгыз таш кабергә –
сезнең язмыш ахыргача
солдатныкы белән бергә!..

Мәңгелек утның ялкыны
җылыта таш диварларны...
Шәүләсе ташларга төшә...
Батырларны ялкын барлый!

* * *

*Николай Старшиновка*

Каенның яшел чәченнән
чал-сарысын өз!
Борчылма!
Бар да тәртиптә –
бусагада көз.

Җырлагандай яшәдек, көн
тезгенен тотмый.
Әйләнеп баксак –
күкләрдә
торналар сыктый.

Карасак,
авыл артында
кибәннәр үскән.
Карасак, алмагачларда
алмалар пешкән.

Күрми дә калганбыз,
дустым,
көннәр узганны.
Күктә, торналар янында
вакыт тузаны.

Үткәргәнбез гомер җәен
шаяру катыш.
Көзләр безне гафу итсә,
гафу итмәс кыш...

## КАЗАХЧАДАН

*Олжас Сөләйменов*

## КУЫП ТОТ!

Куып җит мине, егет,
атың күбек ит, егет,
әгәр мине чынлап сөйсәң,
куып тотарсың кебек.
Сине яратам, егет,
куып җит тә
ал үбеп.
Оялудан тавышым

тамагыма ябышты.
Мине җил куып уза,
ул билемә кул суза.
Аһ, егет артка калды,
атымы әллә талды.
Үчекли мине Ай-кыз,
мин ялгыз,
Айдай ялгыз.
Кулларым инде талды,
атымның сырты канлы.
Эх сез, усал кешеләр,
сез бит миннән көлгәнсез:
шундый батыр егеткә,
шундый матур егеткә
туры чаптар урнына
хәлсез ишәк биргәнсез!..

* * *

Поездлар соңгаралар.
Яшел семафор – харап.
Мәтәлде сары йолдыз –
самолётлар соңгара.
Мәрхәмәтле гасырның
хакиме каш җыера –
күзеннән аккан нурны
керфек тоткарлап тора.
Барыбер лә: ни ялвар,
ни ачу белән эндәш –
чыбыркы озынлыкка
соңгара синең киңәш.
Киләчәкнең шәүләсе
портретның төсен казый,
сөеклем, ничә елга
соңгара синең назың!
Клавишлар буйлата,
Листка* ярдәм дип уйлап,
дастаннан ирләр кайта,
соңгарып
өч йөз елга...

## АРГАМАК

Әй сез, кыпчак далалары,
данлы ат көтүләре!
Кипкән үлән яңгырында
айгырлар утлап йөри.
Бир миңа яшь аргамакны –
уйный җан тамырларым,
шәһәрен дә, даласын да
җилим бер, җилен ярыйм.
Аргамакның кайнар канын
җил өреп ялкын итәр,
тояк
очырган
очкыннан
үләннәр янып китәр.
Аргамакның аңына да
һөҗүм тәме
иңәр бер...

Куркак
сукмаклар
йөзенә
тояклар шавын бәрик!..

* * *

Думбырасын чиртә-чиртә,
бер карт акын
бик күптән
җырлый мәхәббәт турында,
инде карлыгып беткән.

Ялпәк йөздән, мыеклардан
хасил җанлы түгәрәк...
Юртага ишәк ышкына...
Атлар эткә тибәләр...

Кемнәрдер моңга кушыла...
Акын белә җырлавын.
Юртага
сөялгән килеш
йоклый сөңге урманы.

## УКРАИНЧАДАН

*Тарас Шевченко*

* * *

Кәккүк күкелдәп җибәрде
Яшел имәнлектә.
Кыз бала елап җибәрде
Сөелмәгәнлектән.
Ә кызның матур еллары
Заяга үтәләр,
Дулкындагы чәчәк кебек
Агалар-китәләр.
Әти-әниләре исән,
Хәллерәк тә булса,
Табылыр иде сөюче,
Әйбәт яучысы да.
Шулар юк шул. Берьялгызым
Үк-кадерсез генә
Гөл кебек сулып сынармын
Бер читән төбендә.

## БЕЛОРУСЧАДАН

*Микола Метлицкий*

* * *

Илһам килгән чакта мин – шагыйрьмен.
Хәтта Вакыт кире якка ага.
Үзе гүзәл, үзе аңлаешсыз
дөнья минем күзләремә бага.

Иминлеккә хезмәт итә-итә,
таң күренә, җилле ялын изәп...

Мин дә гүзәллекләр эшлим, җанны
нурлы кояш җиле белән бизәп.

Юк бернинди хәвеф-хәтәр эзе.
Җан шатлана – күз генә тимәсен.
Илһам килгән чакта мин шагыйрьмен –
тормыш гимны, аның мәдхиясе.

* * *

Борыннан ук Русьта шулай булган –
туганына кул күтәргән туган.

Хәтта җил дә, моңа гәепсенеп,
елый-елый искән, җиргә сеңеп.

Һәм козгыннар туй иткәннәр шунда
каберләрнең бөкре сыртларында.

Һәм бүген дә, кулда наган кысып,
киллер көтә кебек, чатка посып.

Йә тарихтан, яки изге күктән –
Русьта шундый нәрсә бик тә күптән.

* * *

Ерагая көннәр афәт вакытыннан*,
акрын гына алар онытыла бара.
Каракура арасында шигырьләрем
һаман шыта. Алар кайгы төсле кара.

* * *

Монда атом-төш хәтергә төшә –
агулы үлән шым булып яткан.
Ләкин чабырның исерткеч исе
никтер соклану хисе уята.

Арчан яңадан зәңгәр чәчәктә!
Моны күреп җан имәнеп китә:
агулы бушлык эчендә һаман
яз хасияте патшалык итә...

*Рыгор Бородулин*

## ХАТЫН-КЫЗ

Хатын-кызны
изге үк итмәгез –
ул тормыштан,
гүя алмагач.
Давыллансын,
җанын дәваласын –
хәсрәт урып,
бала табалгач.

Төнге сагыш,
көндезге күз яше

болыннарның тыныч чыгында.
Чәнечке дә,
иң назлы бизәк тә,
йолдызлы җан да ул
чынында.

*Микола Чернявский*

* * *

Йортка кеше кереп тулды.
Салам, чүпрәк-чапракта
йокларга
күнегеп барам –
өем тулы качаклар.

Ихтыярсыз, төннәр буе
мин дога укып чыгам...
«Кунаклар»ның кулларында
йә граната,
йә пычак.
Берсе гашиштан тилерә,
кайсы – рэкет паханы,
кемдер – героин көендә.
Себерке астына поскан
тычкан мин үз өемдә...

Бүрегә дус булмасам да,
бүре холкын көрим мин:
абайлыксыз,
гранатасыз
һәм сакчысыз
йөремим.

* * *

Шаулап үтте, койды чәчәген,
тик юаныч калды хәзергә...
Нидер булды, нидер булмады –
кайтаваз да әйтмәс, хәтер дә.

Еллар очып кына үттеләр.
Нинди байлык калды күңелдә?
Кара икмәк
һәм юл тузаны,
карлыгачлар
күктә җемелдәп.

Шаулап үтте, койды чәчәген,
тик юаныч калды хәзергә.
Миндә мине нәрсә саклады –
кайтаваз да әйтмәс, хәтер дә.

*Леонид Голубович*

* * *

Шигырь, синең изге көч-куәтең –

Гомерем биреп тапкан тупланыш...
Кинәт жанны көең телеп үтте –
Бердәй акты шатлык һәм сагыш.

Үлем генә бүләр кол хезмәтен –
Халык жанын кılә тыңлыйсым
Һәм язасым килә,
            фронтлардан
соңгы тапкыр язган хат сыман.

* * *

Төнге өй, караңгы дивар.
Тышта кара җил улый.
Күңелем, күз дә йоммыйча,
Төкәнмәс уен уйлый.

– Нидән мәңгелек сызлавым?
Кайлардан теләк көче?
– Корбан булудан.
– Нигә дип?
– Дөньяны аңлар өчен.

– Дөньяда нине аңларга
тырышыр идең элек?
– Үземдә – үземне. Аннан
Стихияне, җилне.

– Ә нәрсәне белми калу
хәерле дисең, өзеп?
– Җан-күңелнең ятимлеген
һәм сүзнең телсезлеген...

*Дмитрий Морозов*

* * *

Аң-акыл тотылган заман,
Караңгы җанда да бик:
Ишетелми Аллаһ сүзе...
Ә син тот та иген ик!

Җилсезлек һәм черү чоры,
Шайтани хис кайный тик.
Дөньяда хаклык табылмый...
Ә син тот та иген ик!

Гөнаһлардан чистардым, дип,
Кыямәт көннән элек,
Икейөзле бәндә сөйли...
Ә син тот та иген ик!

Үзгәрүчән стихиядән,
Җүләр җилләрдән көлеп,
Игелекле йөрәкләргә
Ә син тот та иген ик!

МЕТАМОРФОЗА

Ике көч йөретә кешене –
Яхшылык белән Явызлык...
Алар тамырын үзеннән
Кеше яна-яна эзли.

Якынлашкач бөек сергә,
Тынлык назлый җанга тулып,
Һәм яңадан үсеп чыга
Үлән, башак, бөре булып...

* * *

Бик күптәннән төшкә әни керми...
Көз. Төкәнмәс авыр яңгырлар.
Кем уятыр җанда музыканы,
Нинди көйләр анда яңгырар?

Зыкы басты гыйбадәт йортларын –
Көнләшүләр җанны яндыра...
Бик күптәннән төшкә әни керми...
Көз. Борчулы, салкын яңгырлар.

*Юрий Сапожков*

## РӘХМӘТЕМ

Гомер мунчала шикелле
Тетелгән... Заман кырыс.
Шулай да чиксез башламның
ахыры – үргән тырыс.
Ә шулай да язмышыма
үпкәләмим... Ул – нурлы...
Тамчыдай яхшылык өчен
Рәхмәтем дөнья зурлык.

* * *

Парктагы сукмакларга
Көз җәйде ап-ак җәймә –
Крахмалын кыштырдатып,
Ят әйдә, ауна, җәйрә,
Оялган булып кыланма.
Ә парк бераз кызарды...
Беренче булып өрәңге
Өс-башын салып бәрде.

## КОЗГЫН

Карт, кызганыч козгын,
Җитте, бик күп очтың.
Күңелең санамый
Елларыңның очын.

Атылганың булды
Чебешләргә уктай.
Хәзер үләксә дә
Аш – башкасы юкта.

Каткан ипи, кипкән

Сөяк, сасы чүплек...
Ә тормышта әле
Шундый шатлык күпме!

ЧУВАШЧАДАН

*Пётр Хузангай*

* * *

Ялганмын учларымны кысып учлап,
«Якты дөнья – минеке ул!» дигән кебек.
Ә үлгәндә ике учым да ачылыр, –
Байлык булмас анда хәтта сыңар бөртек.

Мин ачмаган, минем белән бетмәс йола:
Каберемә биш тиенлек ыргытырсыз.
Ә аннары, и дусларым, җырлап-җырлап,
Биеп-биеп төрле якка таралырсыз.

* * *

Урманнарга кердем, менеп акбүз атка,
Сагышларым салдым куе каенлыкка.
Кайгы-хәсрәтләрне башта саклап йөртсәң,
Әйләнү ихтимал шыр тиле-ахмакка.

Чирмешән буйларын байкадым-айкадым,
Бер генә уч колмак та җыя алмадым.
Шушы чиккә җиттем, васыятем итеп
Тапшырырга, дуслар, берни дә калмады.

Дөньялары – чиксез, җире йомры икән,
Гомер сәкесе дә иркенәеп беткән.
Шушы чынбарлыкның серен ачар өчен
Бер кеше гомере артык кыска икән.

*Яков Ухсай*

МИНЕ ТАТАРГА САНЫЙЛАР

Мине татарга саныйлар,
кыстыйлар: «Чәйләп алыйк!»
Һәм түбәтәй кидерәләр,
чак кына кыңгыр салып.

Охшаган икән – охшаган!
Чуваш нигә тансын соң:
миндә татар кыяфәте
тумыштан ук анысы!

Зур күзләр, татар күзләре,
нык тупсалы киң яңак...
Татар белән аралаштык
гасырлап кына санап.

Мәҗит Гафури белән без
Уфада күп көрештек...

Зур шагыйрь булырга шулчак
хыялланды бу кеше.

Мин, сагынып, өенә дә
килә идем кайвакыт.
Каршылый иде ул җырчы,
самавырын кайнатып.

«Шундый шагыйрь булсаң икән!»
дип өметләндем күпкә.
Каурый төрткән канатларым
тарттылар мине күккә.
Әле бер билгесез шагыйрь,
унҗиде яшь ул чакта,
татар җырлары җырладым,
үз-үземне кочаклап...

Ошарга теләдем аңа –
гаҗәеп шагыйремә.
Шуңадыр шигырьләремдә
гафурилык күренә.

Һич тә ерак тарих түгел,
ул көннәр якын, тере, –
Муса Җәлил балкып миңа
Мәскәү күрсәтеп йөри.

Мусаның җан яктылыгы
йөрәгемдә чагылды.
Шуңадыр да инде, бәлки,
миндә татар чалымы.

Казанда еш була идем.
Җәлилсез дә күп киләм.
Шуңадыр чуваш Ухсайны
татарлар яхшы белә.

Яшьлекне искә төшереп
барлыйм урамнар рәтен,
ә янымда Хәсән Туфан –
минем чал ахирәтем.

Аның җаны якын миңа –
ачам бар серләремне.
Аяк асларында ташлар
йомшаклар, мендәрмени!

Туфанча язарга теләп,
үзәкләрем өзелә.
Шуңа күрә дә татарлык
саркыгандыр йөземә.

Чын күңелдән үгетлиләр:
«Түбәтәеңне салма!»
Әйтерсең мине түбәтәй
чын татар итә ала.

Охшаган икән – охшаган!
Чуваш нигә тансын соң:
миндә татар кыяфәте
тумыштан ук анысы.

*Геннадий Айги*

## КЫШ ТАМГАЛАНГАН*

ак һәм якты икенче белән
ял итә ил

өстәл янындагы караңгылыкка сәбәп булган
һәм үзе өчен тынлык тудыра-тудыра
кемгә һәм кайда бүләк иткәнен абайламыйча

һәм Аллаһ якынлаша үзенең барлыгына
һәм ул үзенең табышмакларына
рөхсәт итә инде кагылырга

һәм шаяртып сирәк кенә
безгә чак-чак суынган
һәм яңабаштан аңлашылган
тормышыбызны кайтара

## ЮЛ

Безне беркем дә яратмаганда
без
әниләребезне ярата башлыйбыз

Безгә беркем дә язмаганда
без
иске дусларны төшерәбез искә

Һәм сүзләребезне дә
эндәшмәү куркыныч булганга
хәрәкәт хәтәр булганга гына кулланабыз

Ә соңыннан – каралмаган очраклы паркларда
кызганыч трубалардан
кызганыч оркестрлардан елыйбыз

*Порфирий Афанасьев*

## ҖИҢҮ КӨНЕ

Бемим, әллә күрдем, әллә әни
сөйләгәне генә хәтердә:
керде күрше...«Сугыш бетте!» – диде...
Сискәнде өй... Тетри хәзер дә...

Яраланып, ике атна элек
кайткан әти басты аякка.
Калтырады ул таянган өстәл,
култыгыннан төште таяклар.

Шулчак әти мине күреп алды.
Күтәрде дә чөйде югары –
әйтерсең лә ул баһадир егет,
авыр яралары юк аның!..

Йөгереп чыкты якты урамга ул,
баш өстенә мине күтәреп...
Шуннан бирле мин иректә коштай
иңлим илнең азат күкләрен...

## ДУСЛЫКНЫҢ НИГЕЗЕНДӘ

Йөрәгем чатнап китте дә,
мин түзмәдем, инәлдем:
«Тизрәк килеп җитә күрче!..»
«Вакытым юк!..» димәдең.

Миңа якты шатлык иңде.
Аңа синсез тимәдем.
«Тизрәк килеп җитә күрче!..»
«Вакытым юк!..» димәдең.

Күңелне бүлешә алу
дуслыкның нигезендә...
...Ә мин килә алырмынмы
чакырган мизгелеңә?..

* * *

Юк, булмады инде... Зинһар, кичер.
Чаткы чатнамады күңелдә.
Хатларымны минем тәмам оныт –
алар башка кызга иделәр.

Һәм кочма да. Барбер җылысы юк.
Калтырата... Салкын җилмени...
Көзге агач сары яфрак ябып
җылыталмый инде күңелне...

## СУ ЭЗЛИБЕЗ

Җир чокыйбыз – су эзлибез.
Көн эссе. Сынды чыдам...
Бәлки, шушы катламнан соң
чишмәсе бәреп чыгар?!

Су табылмас бу төштә –
төкерик лә бу эшкә...
Юк! Ярамый! Эзлик, эзлик!
Хурлык ич ташланган эш.
Аркаң таш булып катса да,
тагын бераз казып төш!

Алдым берне батырып –
Ур-ра! – чишмә ялтырый!

Су эзлибез – су табабыз!
Зуррак шатлык бармы соң?!
Сусаганнар! Су эчегез,
сусыныгыз басылсын!

*Юрий Семендер*

## ИДЕЛ ТАВЫШЫ

Дулкыннар ярга яталар
чылбыр-чылбыр.
Тавышлары колагымда:
«Юл бир, юл бир!»

Идел, синең юлың бар ич –
ашкын, ашкын!
Салларың бар, ак пароход –
ташы, ташы!

Су түгелдер ярларыңда –
көчтер, көчтер.
Шуңа күрә дә таләбең:
«Эш бир, эш бир!..»

## КАРТ СОЛДАТНЫ КҮМҮ

Дүрт сугышта ничә окоп
казыган ул, биргән көчен.
Җир аны үлемнән йолган
кыю, эшчән булган өчен.

Һәм ветеран дөнья куйды...
Җирдән тагын шул ук кадер! –
Окоплар дәвамы итеп,
яшьләр казый аңа кабер.

## ӘНИ

Сине кояш йөрәк диләр, әни.
Кояш кебек, җиргә кунасың.
Кояш нурын йөрәгеңә туплап,
иртән кабат кояш буласың.

Сине юкә чәчәгедер диләр,
баллы телең өчен, яратып.
Өй катында үскән юкә кебек,
син көтәсең безне һәрвакыт.

Сине язгы шәүлегәндер диләр,
җырлавыңны кошка тиңләптер...
Күңелеңнең гүзәл чиксезлеге
галәм киңлекләрен иңләрлек.

* * *

– Тынычлыгың тәрәзәдән очтымы,
иртән-кичен, әни, кая карыйсың?
Чыклы таңдай бүзәрмә, әни, алай,
урынында шәрык, гареп – барысы...

– Ландыш төсле чыклар, улым, чирәмдә,
кошлар китәргә җыена түгелме?
Күптән киткән әтиең дә көтәдер,
аңа минсез бик кыендыр тегендә...

– Йөрәгеңне, әни, алай кузгатма,
сандыгыңнан киемен ала-ала...
Ашыкма да, юксынма да... Дәшәрләр
вакыт җиткәч... Ә хәзер тамак ялга.

– Киленкәем, кабартмаң кояш төсле,
ашар иде этиегез дә тәмләп...
Чиркәү чаңы – Җир һәм Күк ризалыгы,
бераз гына шул чаңны көтик мәллә?

– Әбекәем, уч астыннан карап, син
торналарның очышын күзлисеңме,
әллә инде йолдызлар арасыннан
мин очасы юлны да эзлисеңме?

– Әй, оныгым, орлыгым-чувашчыгым,
үс, күтәрел, йолдызлар коча-коча...
Мин ерактан сиңа теләк теләрмен,
аккошлар төркемендә оча-оча...

## КАРЛЫГАЧ БАЛЛАДАСЫ

Карлыгачкай очты ерактан-ерактан,
зәңгәр Нил диңгезгә ашыккан бер яктан.

Очты җил-яңгырда, сәмумнар үткәрде,
язның ул җып-җылы сәламен күтәреп.

Исенә төшерде әнисе сайравын,
ояда аңарга урын-җир җайлавын,

мамыгы каурыйга әйләнгән чакларын,
беренче мәртәбә канатын какканын...

Һәм менә Сыр суы, һәр авыл – тал-тирәк.
Чувашстан, син кабат чибәрдән чибәррәк.

Тирә-юнь – яшел шау, эш шавы – таң аткач...
Исәнме, әй туган авылым Анаткас!

Кайта да карлыгач, ни күрә – өе юк,
баз гына ыржайган... Төшә ул коелып...

Кабергә озаткач карчыкны, кайтканнар
шәһәрдән уллары, йортларын сатканнар...

## КОРАЛЧЫ КАЛАШНИКОВКА

Автоматлар иясе Калашник агай,
Исемең дә, эшләрең дә синең данлы.
Лаеклы рәвештә алган мактауларның
белмисеңдер инде хәтта төгәл санын.

Кайчакларда ләкин сискәнә торгансың,
кинәт килгән утлы уйларга уранып,
ничә күзнең нурларын сүндергәндер дип
якты аңың тудырган үлем коралы...

* * *

Елтыр-елтыр йолдыз-чылтыр
чәчрәп төшеп урнашты
Цивиль-су ярында яткан
авылына чувашның.

Һәм бу авыл шулвакыттан
хикмәтләргә бай булды...
Тәүгесе – ат абзарында
йолдыз-кашка тай туды...

## НУЖА

– Сине нәрсә ат җигәргә өйрәтте?
– Нужа.
– Сине нәрсә ерак юлда сөйрәлтте?
– Нужа.

– Ялкаулыкны синдә нәрсә сындырды?
– Нужа.
– Ә кулыңа нәрсә калач тоттырды?
– Нужа.

* * *

Алло!
Россиянең ике очы
кочак булып шулчак кавышты.
Элемтәнең тылсымы ишетте
ике мәхәббәтнең тавышын.

Элемтәнең тылсым көче бирде
ерак тавышларга яңгыраш...
Алло!
Ләкин сүзләр яңг(ы)рамады –
елый иде чөнки гашыйклар...

## ӨЧ СОРАУ

1

Телче, азат лачын сыман
оча синдә туган тел.
Беләсең аның чишмәсен,
саф тотасың аны гел.
Телебезнең бар тылсымын,
серен белүче кешем,
сүз төрләнешендә бармы
бездә СӨЮ килеше?

2

Пәйгамбәр, изге хаклыкны
урнаштырдың йөрәккә.
Намусны саклаган хәлдә,
шул яшәргә өйрәтә.
Мин фатиха сорыйм синнән
башым иеп, бөгеп бил...
Әйтче, булырмы берзаман

Мәхәббәттән бер Инҗил?

3

Президентым, гүзәллекне
син игелек санадың...
Хыял якты, җир яшәрә,
яңгырый җыр, соната.
Матурга омтылу көчле,
ул ныклы ярдәм сорый:
ә хөкүмәттә булырмы
мәхәббәт министры?

## КӨЛТӘ БӘЙЛИМ

Язның сихәт үләннәреннән,
бодайны сайлап берәм-берәм,
көлтә бәйлим.

Кояшның тере нурларыннан,
йолдызның моңлы кылларыннан
көлтә бәйлим.

Кайнар мәхәббәт гөлләреннән,
нәфрәт янгыны көлләреннән
көлтә бәйлим.

Өметләремнән, уйларымнан,
меңләгән шигырь-җырларымнан
көлтә бәйлим.

Халкымның олы кибәненә –
киләчәгенә дигәненә –
көлтә салам.

# ЮКӘ ЯФРАГЫНА ЯЗГАННАРДАН

* * *

– Дустым, антология төзиләр,
урын алсын кайсы җырың?
– Иң тирән шигырь юлларым –
маңгаемдагы дүрт сырым.

* * *

Татлы белән ачы... Алар һәрчак
бер-берсенә каршы, асылда.
Ләкин бик еш, ачы капкач кына,
безнең авыз тәмле ачыла.

* * *

Кар киткәнне без ничек әйтә алыйк,
ул елый дип, буйсынуга гарьләнеп...
Күренә ич: беравыктан шул ук кар

язның чуар япмасына әйләнер.

* * *

...Һәм үкәлчә*...Сәлам, шәүлегәннәр!
Мин авылга керәм биредән.
Яшьлегемне аңа биреп тордым,
ничек алыйм икән киредән?

* * *

Барыбер лә: базмы шунда, нәүрәпме,
салам түшәлгән шалашмы, булмаса, –
коесына чылбырланган чиләктәй,
мин янында булыр идем, ичмаса...

*Валери Тургай*

## ЯШӘҮ ҺӘМ ҮЛЕМ

Өй төзергә җыеналар...
Урыны кирәк –
Ава имән, ава тирәк.

Өй төзергә җыеналар...
Яшәргә теләп...
Үлә имән, үлә тирәк.

## МИН

Ә син бик катлаулы кеше.
*Бер танышым сүзе*

Мин,
чыннан да, төрле-төрле –
һәм беркатлы,
һәм мәкерле...

Мин,
чыннан да, төрле-төрле –
һәм гап-гади,
һәм бик серле...

Мин,
чыннан да, төрле-төрле –
һәм бик күндәм,
һәм бик кире...

Мин,
чыннан да, төрле-төрле –
һәм бик сүлпән,
һәм бик тере...

Мин,
чыннан да, төрле-төрле –
борыч телле,
баллы телле...

Шулай тудым,
шулай яшим –
сезгә бәхет
тели-тели!..

## РӘШИТ ВАҺАПОВ ҖЫРЫ

Һай җырлады!.. Һәм тавышы аның
Дулкынлатты җанны, тибрәтте!
Талгын яңг(ы)рап, йөрәгемә үтеп,
Ут-ялкынын аның дөрләтте.

Булса булыр икән шундый сөю!..
Андагыдай якты моң кайда?!
Шуның хәтле татлы сызлану бар,
Кояш та бар анда һәм Ай да...

Уза икән, уза икән гомер,
Теләсәң генә лә нишлә син...
Шуңа күрә йөрәк әмер бирә:
«Яшә һәм сөй, сөй һәм яшә син!»

Төшләреңә сылу булып кереп
Йөдәтә бит һаман яшь хисең.
Син сөйдең һәм һаман сөясең дә –
кеше булып, димәк, яшисең!

Булса булыр икән шундый сөю!..
Андагыдай якты моң кайда?!
Һай җырлады!.. Төне буе гүя
агып торды кебек нур Айдан!..

## ДУСЛАРГА

Файдаланыгыз сез миннән,
Дуслар, файдаланыгыз!
Йөрәгем ялкыннарыннан
Җылы алып калыгыз!

Тартынмагыз! Иренмәгез!..
Ташыгыз кайта-кайта!
Мин сүнеп салкынайганчы
Алып калыгыз файда...

Файдаланыгыз сез миннән!
Мин кирәк сезгә – беләм!
Мин яшим дә сезнең өчен,
Шатлыгым бүлә-бүлә...

Файдаланыгыз, дусларым,
Тартынусыз һәм шиксез!
Сезгә кирәклегем белән
Мин бәхетлемен чиксез!

* * *

– Яратып туймадыңмы әле?..
– Яратып туймадыммы?
Мин

Ярату тәмен менә эчтем.
Яңа туган сабый ич мин.
– Көрәшеп туймадыңмы әле?
– Көрәшеп туймадыммы?
Мин
Көрәшү хисен яңа эчтем.
Яңа туган сабый ич мин.
– Тормыштан ялыктың мәллә?
– Тормыштан ялыктыммы?
Минем
Яшәргә теләгем көчле.
Яңа туган сабый ич мин...

## БЕЗ – ЧУВАШЛАР...

Без – чувашлар – кызганмыйбыз
Беребезне беребез.
Көчсезләрне кызганганны
Күреп, белеп йөрибез...

Без бит көчле! Һәр чувашта
Уйныйдыр Алып каны.
Айкый алабыз галәмне,
Чайпалтабыз Волганы.

Һәм кызгана да беләбез...
Менә кемнәр кызганыч:
Алып батыр кавеменә
Тотучылар кара үч...

Кем хәлсез, шуны җәллиләр.
Әйдә көчле булыйк без!
Без – чувашлар – яратабыз
Беребезне беребез!

* * *

Әй, мунчачы! Кызган ташка эссе сал!
Каен себеркесен тизрәк пешеклә!
Бүген артык кызганма да син мине –
Җанның кышын эретәсем бик килә.

Әй, мунчачы! Бүген мине кызганма –
Җанның карын эреткәнче чап әле.
Язмыш, шатлык бирәсене онытып,
Күбрәк кайгы-хәсрәт биргән чак әле!..

Язмыш мине аямый ич барыбер.
Күбрәк кайгы-хәсрәт эчәм нигәдер.
Эссе җитми, эссе җитми... Өстәче –
Тәнем тоймый парның карга тигәнен...

Һаман пар аз... Өстик әле тагын да.
Тәнем аша эссе үтсен пешереп,
Җанымдагы салкын кышны эретеп,
Кар астына яз сулары төшереп...

## МИНЕМ ҖАНЫМ

Йә ашасың биекләрдән биеккә,
Йә төшәсең упкыннарга капланып.
Йә кояштай балкыйсың син, нур чәчеп,
Йә каласың бер очкында саклanып...

Нәрсә соң син?.. Һавамы йә очкынмы?..
Бармы соң син?.. Булсаң әгәр, кайда син?
Күз кырыем белән генә булса да
Килә сине барып-күреп кайтасым.

Кайчакларда, тәнемә генә түгел,
Син сыймыйсың хәтта галәм эченә.
Син – ирекле. Ләкин Ходай каршында
Син җаваплы минем барлык өчен дә.

...Мин аз беләм... Моны һич тә яшермим.
Сизенәмен синдә олы аң барын...
Аңлат әле: минем яшәү – нәрсә ул?
Ни көтә мине тегендә... аннары?..

Аңлат әле: үлем, үлем – нәрсә ул?
Булдыралсаң, өйрәт тормыш мазасын,
Өйрәт: бүген нишлим, соңгы ноктама
Барып җитәр өчен бәла-казасыз.

Нәрсә соң син?.. Һавамы йә очкынмы?..
Бармы соң син?.. Булсаң әгәр, кайда син?
Һәм син, бәлки, бары хыял гынадыр...
Ә хыялга сорау бирү файдасыз...

## ШАГЫЙРЬ

Бик эшлекле кеше янында ул
Һич эшлекле булып күренмидер.
Йолдызларга – чәчәк, чәчәккә йолдыз
Өләшергә менә иренмидер.

Һәрберебез йөргән җирдән йөри,
Нәкъ безнеке кебек тормыш кора.
Һәрбер шатлык аның җанын назлый,
Һәрбер хәсрәт чәнчеп авырттыра.

Һәр кеше күк ул да хаталана,
Түнә-тора сөйри үз газабын...
Ләкин никтер ул бераз үзгәрәк...
Ләкин никтер шигырьләр яза ул...

Ни өчендер Аны сүзләр сөя
Һәм, буйсынып, Аңа башын ия...

## КАҺАРМАННАР

Җиңү тәмен татучылар,
Яу кырында үлә-үлә,
Көнләшмиләр, чөнки алар
Җиңү бәһасен дә белә.

Җиңеп булмый көрәшмичә.

Көрәш утында янганнар
Җиңүчене олылыйлар,
Чөнки җиңеп караганнар!

Каһарманнар мактанмыйлар.
Җиңү сөйми мактанчыкны.
Җирдә күпме мактанчыкның
Инде яманаты чыкты!..

Каһарманнар көнләшмиләр
Икенче бер каһарманнан.
Бер-беренә баш ияләр
Җиңү яулап караганнар.

## ЭҢГЕР-МЕҢГЕР. ӨЧӘҮ

*Әниемә*

Урамдагы бүрәнәдә
Өч карчык утыралар.
Бу өч карчык – өч ахири,
Дөньяны тутырганнар.

Берсен-берсе сыйлый алар
Яңа хәбәрләр белән:
Мэтринең казы табылган,
Чебиен алган тилгән...

Весьелис оныклы булган,
Көтеп бер гомер узгач...
Ә тимерче Еликсейлар
Яңа мунча торгызган.

Бу болыты, әйтсәм әйтим,
Таралмый да, яумый да.
Нишлисең бит, күккә хуҗа
Без түгел, Ходай гына...

Илдә дә тәртип-мазар юк.
Ни генә кыланмыйлар!..
Шул тиле визер дигәнне
Бер дә тыя алмыйлар...

Кем яхшы яши? Караклар!..
Бер-берсен ата-ата...
Алар илне, бездән урлап,
Әллә кемнәргә сата...

Пинсе акчасын бүген дә
Китермәделәр әле.
Ай Тур-Тур!* Инде дәүләтнең
Шунлык та юкмы хәле?!

Шәһәр ничек яши икән?
Бездә әле түзешле:
Ите дә бар, сөте дә бар,
Сыерыбыз да күши...

Тикмәгә түгел – шәһәрләр
Авылга кучә һаман.

Безнең авыл да шәһәргә
Әйләнәчәк берзаман.

Безме ул кайгы күрмәгән
Һәм тормыш иләгәнне?!
Ай-тур-тур! Никтер... шулай да
Яшисе килә әле!..

Урамдагы бүрәнәдә
Өч карчык утыралар.
Уйлары, сүзләре белән
Дөньяны тутыралар...

*Раиса Сарби*

ЯЛВАРУ

И, Кояш-атам, яндыр Аны – әйләнсен көлгә!
И, Җир-анам, йот син аны барлык эзе белән!
Ул бит сезнең аккоштай кызыгыздан көлә...
Ул бит сезнең аккоштай кызыгызны
тиңләштерә йолкыш тавык белән.
Кояш-атам, синең утың,
Җир-анам, синең горурлыгың
кызыгызның күкрәгендә
әверелде янартауга...
Хурлыгыннан кызыгыз сезнең
йолкый чәчен,
күзләреннән канлы елга булып
ага яше...

И, Кояш-атам, көл ит Аны, көл ит!
И, Җир-анам, йот син Аны берүк!

Кояш-атам, син кара төнне күрә алмагандай
күрә алмыйм Аны!
Җир-анам, син кайнар җилне күрә алмагандай
күрә алмыйм Аны!

...Йа, Тура! Кемнең аһы күкрәде күк гөмбәзендә?
Йа, Тура! Кем шәүләсе төшеп китте җир ярыгына?
Сөеклемнең тавышы түгелме соң?
Сөеклемнең шәүләсе түгелме соң?
Аныкы ич! Әйе, Аның тавышы!
Аныкы ич! Әйе, Аның шәүләсе!

Йа, Кояш-атам, утта тотма Аны!
Йа, Җир-анам, йотма, йотма Аны!
Мин Аны сөям,
мин Аны сөям,
мин бит Аны үлеп яратам!

*Марина Карягина*

* * *

Уйна, уйна, ачулы җил,

гүлә, гүлә.
Дөрләп яна кисәү башы
көлә-көлә.
Көлүләре сызлаулы да,
күз яшьле дә.
Җанын ала, назлы кочып,
җәйге җилдәй.
Таңнарга дымлы кызыллык
шуннан килә.
Дөрләп яна кисәү башы
көлә-көлә.

АВАРЧАДАН

*Расул Гамзатов*

ТОРНАЛАР*

Канлы яу кырларыннан кайтмый калган
солдатлар кайчак килә уема,
туфрак булмаган алар, ак торнага
әверелгәндер кебек тоела.

Әлегәчә аларның шул заманнан
килгән өненә колак салабыз.
Шуңа түгел микән без еш, моңаеп,
күкләргә карап тынсыз калабыз?

Арыган кыйгач төркем сафы оча –
кичке шәфәкъ нурына орынып.
Һәм шул сафта бер кечкенә ара бар, –
бәлки, ул ара минем урындыр!

Килер дә бер көн – шул торналар белән
чумармын мин дә күксел томанга,
күк йөзеннән кош булып эндәшермен
сезгә мин, җирдә калган туганнар.

Канлы яу кырларыннан кайтмый калган
солдатлар кайчак килә уема,
алар туфрак булмаган, ак торнага
әверелгәндер кебек тоела.

*Магомед Ахмедов*

## «КӨЗ ЭЛЕГИЯЛӘРЕ» ЦИКЛЫННАН

* * *

Хатирәләр күк киңлеге кебек...
Шигырь яза-яза җан талды!
Еллар яфрак койган урман сыман...
Ничек саклыйк? Нинди җай калды?

Сүзләрдән дә алтыннары куба,
күп ноктада – уйлы чиксезлек...
Еллар белән уйлар коелалар...
Ничек саклыйк? Киңәш бир, көзем...

* * *

Шәраб һәм күз яше, сугышлар һәм ачлык –
туймас тамак заман җиту көндәй ачык!

Яшәү мөмкин түгел, үләргә дә оят,
рифма шигырьләрдән баш тартырга кыя.

Элек җайлы иде, җаным рәхәт чикте –
яхшыны мактадым, ә яманны сүктем.

Хәзер мине камый, кыса төрле яктан
фәкать тилелек һәм шаккатыргыч ялган.

Өстемдә әйләнә афәт козгыннары –
күчәреннән тайган, күрәсең, Җир шары!

* * *

Көз чишенә – урман
фәкыйрьләнә бара.
Моң-сагышка сәбәп,
әйтик, моңсу кыр...
Самимилегемнең
күзләрендә күкнең
зәңгәрлеге бетте –
хәзер мин сукыр...

Нинди генә сүрән
булса да көз, анда
сиңа гына дигән
алтын йолдыз бар.
Бөтен Галәм сиңа
кырын караса да,
шул йолдызның нуры
җаның дәвалар.

Шигырь көзгесенең
эчендәге дөньям –
көзге яфрак өчен
яшәү урыны.
Хәзер мин карт малай,
түбәм ап-ак карда
һәм дә йолдызларга
тора орынып.

* * *

Тауга тау үрелгән, сыенган,
алардан өстәрәк – бөркетләр.
Балачак хыялым бар иде –
йолдызлар чүпләргә бөртекләп.

Ә алар биектә, еракта!..
Мин көзге тынлыкка батканмын.
Йөрәктә яктылык, рәхәтлек,
әйтерсең лә хаждан кайтканмын.

* * *

Рус вечесы кебек шаулы ватан!
Яшәү хәтәр – аңлыйм барсын да...

Үз хатама үзем җавап тотам.
Мин гөнаһсыз синең каршыңда.

Сөюемнән сине исердем мин,
синең алда бурыч – айнытты.
Язмыш бүләк иткән тау кызларын
гына кочтым – хисләр баеттым.

Эләккәләү булды тозакларга,
суын гиздем, типтем кыясын.
Җиде ятлар, якын туганнардай,
коткардылар мине риясыз.

Синең алда, борынгылар кебек,
тез чүгәмен, күкне колачлыйм.
Ватан, ватан, мизгел саен кипкән
шагрень күне* генә булмачы.

* * *

Ач, ялангач калып авыйм аусам,
хәер сорашмамын – күтәрмим.
Туган илнең юлы кыек чакта
нигә мактыйм әле күкләрне?

Онытылу белән яный вакыт.
Моны белеп тапкан бит анам.
Көн белән төн арасында туган
шәфәкъ көнен итсен тантана.

Дәшмә, шагыйрь! Табигать сөйләсен.
Сүзсез торыйк. Бу таш – теп-тере...
Астына без азатлыкны күмдек...
Һәм мин аңа чәчәк китердем.

* * *

Дөньяны ник матәмгә урарга?
Китсәм, кайгырырлар бик әзләр.
Сез алыгыз мине, ак болытлар,
дулкын итеп диңгез-гөмбәзгә.

Дуслар миңа тәгам сондырдылар...
Чорлар чиратлашты бу илдә.
Егерменче гасыр, синең белән
гади кеше басты дуэльгә.

Урап кайткан болыт сыман, мин дә
Дагыстанга кайттым әйләнеп.
Хәлдән килсә, Аллаһ, көз фасылын
куяр идем тауга бәйләп мин.

Мин канатсыз идем. Төшләремә
керә иде мәгърур очышлар...
Һәм бәдәнем җир куенына кергәч,
җаным күкләр белән кочышыр.

* * *

Чуерташ та түгел, кургаш та,
күкрәктә йөрәк ул – дөп тә дөп.
Оятсыз җыр җырлый бер хәсис,

Ахмедов кушылыр, бәлки, дип.

Кабул итми җаным хәсисне –
мин талант җырына күнеккән.
Иҗатчы бриллиант эзләми,
сүз эзли электән-электән!

Без, энҗе эзләүче кемнәр күк,
чумабыз хакыйкать артыннан.
Намуска омтылган күпләрне
хәсисләр контрольләп аттылар.

Һәм мин дә, янартау шикелле,
йөрәктән ядрәләр аттырам, –
дөньяда хәсисләр бетсен дип,
контрольләп атарга хакым бар.

* * *

Булачакның исем-аты булмый...
Язмыш юлын искә төшереп,
көзге карлар хатирәләр булып
аяк асларыңны пешерә...

Боек пыялага рәссам-суык
йолдыз бизәк сипкән арада,
үтә күренмәле ераклыкта
синең профилең ярала.

Гомер уза – оча, оча гына...
Һәм кичәге синең назларың
учка төшкән карлар булып эреп
искә төшерәләр язларны.

Нигә кирәк мондый рәхәтлекләр:
бозлы җилләр кисә йөзеңне,
һәм, ямансу ялтырап, кар астыннан
карап тора синең йөзегең...

* * *

Бакчаларның көзге җимешләре
балкый кәрзин чыбыклары аша.
Хисләремнең иске сукмаклары
яңа мәхәббәтләргә тоташа.

Күңел исә хушлашулар чоры
артык ерак калмаганны сизә.
Мин – Көз!.. Минем каләм кыштырдавы –
җилнең көзге көйләренә бизәк.

Куе томаннарны ерып киләм,
кошлар моңлануын тыңлый-тыңлый.
Матур әкият кебек серле ялган
колагымда чыңлый, бер дә тынмый.

Хәтеремне сәгать итеп борам...
Ә сәгатем теле көздә тора.

БАЛКАРЧАДАН

*Кайсын Кулиев*

* * *

Мин яшәдем һәрбер кеше кебек,
батмаенча данга, язынка,
гөл үстердем, курыктым үлемнән,
кышын ала идем язлыктан.

Мин яшәдем һәркайсыбыз кебек,
мин кече дә булдым, олы да,
ипи кабып чишмә суы эчтем,
яз да, көз дә төште юлыма.

Егылдым да, көлдем, еладым да,
һәм куркытты картлык сукмагы,
мин даһи да, каһарман да түгел,
«Мин – җирдән!» дип күкрәк сукмадым.

Мин яшәдем һәрбер кеше кебек,
язмыш жирәбәсен сүкмәдем,
яшермимен, кыңгыр да сөйләдем,
намусымнан ләкин чикмәдем.

Башкалардан начар булмадым мин
һәм өстен дә – әйтәм кычкырып.
Ә җырымны күңел төпкеленнән
мин кош итеп язга очырдым.

Кемдер өнәмәде, кемдер сөйде,
ә мин башкалар күк – бер кавем.
Тормышка мин һәрчак гашыйк идем,
аерылудан хәзер куркамын.

* * *

Кара еллар төннәрендә
күргән булды алтын төшләр.
Һәм аларның кайберләре,
көткәнгәме, ашты эшкә.

Канлы сугыш көннәренең
күренми дә иде чиге,
дәһшәтне читкә тибәреп,
төшкә керә иде Җиңү.

Чит якларда шактый озак
яшәгәндә нигез корып,
керде төшкә туган җирләр
һәм өн булып кавыштырды.

Һәр кешенең дә төшенә
керсен аңа лаек эшләр,
һәм аннары юшка чыксын
бәхеткә юраган төшләр.

* * *

Мәет белән хушлашканда кайчакларда
Мәгънәсездер сүзләр әйтү – нигә аңа
Җан җылысы сеңгән сүзләрне без үзе
Исән чакта әйтеп кала алмаганда?

Бик еш кына безгә җылы сүзләр җитми,

Җаның туңып боздай каткач... Шулчагында
Тылсым көче белән сугарылган сүзләр
Җылыталар безне кизил учагыдай.

Җае җитми, шытып чыкмый хәтта бөртек –
Туфракның ул алсын әүвәл җылы көчен!..
Чакма кебек йөрәккә дә җылы сүзләр
Кирәк була, чатнап чаткы бирсен өчен...

*Әхмәд Созаев*

ЯЗ

Яз килде, яз!
Гасыр кичкән тирәк,
йота-йота җылы җилләрне,
тыңлый-тыңлый кошлар сайрашканны,
янә яфрак ярып җибәрде
һәм биеде яшел ботакларын
җилфердәтеп, ихлас сөенеп...
Бу язда да шәп башкарды тирәк
үз картлыгын җиңү биюен.

* * *

Мин шәһәргә,
кырлар, болыннардан җыеп,
кочак-кочак чәчәк китердем, –
бүләк булсын, дидем, җиремнән.

Мин шәһәргә,
басу-бакчалардан төяп,
төрле җиләк-җимеш китердем
һәм күчтәнәч итеп өләштем.

Мин шәһәргә,
кәрзиннәргә өя-өя,
уңдырышлы туфрак китердем, –
теләгәнең утырт, үстер син!

Миңа шәһәр,
иңнәремнән сөя-сөя,
күңел сүзен болай җиткерде:
«Үзер нәрсә генә китер син!»

## БИРҮ АЛУДАН ХӘЕРЛЕРӘК

Бирүче кул алучы куллардан
абруйлырак булды – данланды.
Моны белеп, аңлап яшәүчене
беркайчан да кайгы алмады.

Дөнья буйлап мин үземчә атлыйм,
үз каләмем яза көнемне.
Мин кулыма бирүче булуны
йөкләдем һәм моңа үкенмим.

## ГАИЛӘ НИГЕЗЕ

Хатын-кызсыз тормыш корып булмый,
нигезе ул аның, мәгънәсе.
Хатын-кызның чын исеме – Ана,
аңа бәйле Җирдә һәммәсе.

Ана булу – бөек, изге гамәл!
Җирне Аллаһ шулай төзегән.
Һәм бу – Җирдә иң тормышчан канун,
яшәвебез, димәк, өзелмәс.

## БАШСЫЗ

Югарысы катгый боерык бирә,
түбәнрәге бирә киңәшен.
Кабул итәсең син – нигә кирәк
бәхәсләшү, каршы эндәшү?!

Анысын да шәпләп башкарасың,
бусына да ипләп ярыйсың...
Ә үз башым бармы икән диеп,
килмимени тотып карыйсың?

* * *

Ай-һай дорфа сөйләштең син,
чәнечкеләр белән чактың.
Мин, сүзләшеп тормый гына,
һөҗүмеңне кире кактым.

Буш, зәһәр сүз ысылдады
чытырмандагы еландай.
Кешелеген жуя-жуя,
караланды синең чырай.

Хәтта кояш та оялды
яла тыңлап тора-тора,
һәм баеды – синдәйләргә
бирмәс өчен сыңар нур да.

* * *

Кылдай нәзек безнең шатлыклы чагыбыз.
Өзәр өчен аны җитә кискен тын да.
Хәсрәт килсә, кысып ала ян-ягыбыз,
әйтерсең лә без бер хәнҗәр кынысында...

## ПАКЬЛӘНҮ

Каек булып таңга йөзеп керәм,
тормыш гөрли ишкәк суыдай,
үләннәрне сәйлән чыклар төргән,
ә йөрәкне сагыш суыта.

Әкрен генә мин зиратка киләм.
Атам, анам анда... Якында...
Яшем белән мин җанымны юам
изге ике кабер янында.

## АЛЛАҺКА ЯЛВАРУ

Бер өйнең дә куаныч яктысын
киметмә Син – үзеңнекен өстә.
Балаларга баккан чакларда да,
Синең нурың булсын безнең күздә!

## КӨЧЕҢ ҖИТӘРМЕ, ҖИРЕМ?

Булды тау елгасы булып
тынлык үкергән чаклар,
явыз ташкыннан йотылды
халык чаклы халыклар,

кешеләрнең сыктауларын
тиран көй дип тыңлады.
Ә Җир түзде, кешелекне
үзенә ят кылмады.

Җирем, түздең, кайгырсаң да,
ташып чыкмадың ярдан...
Көчең җитәрме соң, Җирем,
алдагы давылларга?

## ШИГЫРЬЧЫГА

Гөл тамырын
сугарырлык булмаса,
ялагай телен
тешләтерлек булмаса,
сүзең юлга хәстәрләмә,
чыгарма –
өйрән чыдарга!

Таң нурына
җыр өстәрлек булмаса
йә бәладән
бер искәртү булмаса,
сүзең юлга хәстәрләмә,
чыгарма –
өйрән чыдарга!

Бөркетләргә
көч бирердәй булмаса,
үч йодрыгын
ачтырырдай булмаса,
сүзең юлга хәстәрләмә,
чыгарма –
өйрән чыдарга!

## ЯҢА БУРАЗНАГА ЯҢГЫР ЯВА

Яңа буразнага яңгыр ява сызып...
Сабый кебек ике кулын алга сузып,

карт игенче исәнләшә язы белән...
Учларына сеңеп калган назы белән

сыйпап ала эшләп талган үгезләрне –
кайнарланган инде дымлы мөгезләре...

Чәчәк кадап чытланмаган таулар сирәк,
тау битендә әнә сылу яшь тал-тирәк

чакрып тора «Тирәк типсү» әйләненә,
чишмәдән дә чылтырап тора сәйлән генә.

Табигать тә шат язларга керүенә –
безне яшәү дәрте белән төрүенә.

## АКСАП КАЙТТЫ ТАВЫШЫМ

Син бик оста кача алдың миннән
һәм кайдадыр кереп югалдың...
Ә тавышым, сине табарга дип,
төнге юллар буйлап юл алды.

Куып тоталмады сине тавышым,
төшалмады качкын эзеңә,
арып-талып, тәмам аксап-туксап,
чак-чак кайтып җитте үземә.

## МАРИЧАДАН

*Дәүләт Исламов*

## КӨЗГЕ РОМАШКА

Көзге ромашкалар чыдам –
Хәтта котып тыны килгәч,
Үзенең ямен югалтмый,
Кояш кебек, һаман көләч.

Тамыры җылы булганга
Ала алмый аны кырау...
Карасаң, бәсле кырларда
Ак нур чәчеп ут утыра.

Ул – минем гомер чәчәгем.
Күңелем аңа сыена,
Ә ак нурлары, коелгач,
Чигәләремә җыела.

* * *

Соңгы яфраклар коела –
Күлдәвектә алтын төсе.
Томаннардан аңкый кайчак
Килә чыккан буран исе.

Кошларның китәсе килми
Ят якларга, еракларга.
Аларның моңлы өннәре
Никтер йөрәкне актара.

Шушындый сүрән көннәрдә

Туган якларга ашкынам –
Минем күңел халәтемне
Аңлыйдыр китәр кош кына...

Күпкә түзгәч, азга да түз,
Туган җирем, кайтам язын!
Сагындырды былбылларың,
Урманнарның тыныч назы.

Бураннарның, суыкларның
Киртәләрен тибеп ишеп,
Буа буендагы йортка
Йөрәк белән шакыйм ишек.

Менә ул ачылып китә...
Анда әни... Мине күрә...
Сүрән күзләр мине шулай
Татлы хыялларга төрә.

* * *

Ашлык амбарлары тулды...
Яңгырлар булыр... Карлар...
Тракторларның фар(а)лары
Яктырта кырда парлап.

Ашкыналар, ашыгалар,
Ерталар кара көзне...
Тракторлар бер-берсенә,
Ярышып, байрак изи.

Сменалар алмашына:
Төнне алыштыра таң,
Тракторлар уты сүнә,
Кояш чыга офыктан.

ЛАКЧАДАН

*Әфәнди Капиев*

* * *

Арылды.
Эзләрдә чал картлык,
Сөякләр яман көн сизенә...
Һәм кипкән күлләрдән чүлләргә
Торналар төркеме күченә.

* * *

Хәнҗәрдәге язу кебек,
Кашкайларың карадыр.
Шул хәнҗәрдәге кан кебек,
иреннәрең янадыр.

* * *

Үлеп гашыйк булганга
Һич юк безгә игелек...
Йөрәкләр аеры булгач,

Карлы тау башлары күк.

Тоташтырасы иде
Икебезнең йөрәкне,
Бер мылтык көпшәсендә
Дары белән ядрәдәй.

Үлеп гашыйк булганга
Якты юк безгә көннән,
Тәннән тән ерак торгач,
тау һәм диңгез өсте күк.

Тоташтырасы иде
Тәннәребезне безнең,
Мисыр хәнҗәре тыгыз
Кынысына кергәндәй...

## ИНГЛИЗЧӘДӘН

*Уильям Шекспир*

### 109 НЧЫ СОНЕТ

Ялган икән димә моның йөрәгендә,
Кайнарлыгын гына алган кавышмаулар.
Минем җаным яши синең күкрәгеңдә.
Үз җаныңны китеп буламыни ташлап?

Мәхәббәтем куышы – син. Кайда-шунда
Йөрсәм дә, мин сиңа илткән сукмак таптым,
Һәм һәрвакыт җанымны синең каршыңда
Дәваларга шифа-бәлзәм алып кайттым.

Кайчакларда буйсынсам да, бирелсәм дә
Гыйш-гыйшрәтләр давылына, ышанма син
Мин синеке түгел дигән вәсвәсәгә,
Җаны моның югалтты диеп намусын.

Нәрсә соң ул синсез хәтта дөнья-галәм?!
Тик син кирәк миңа, назлы роза гөлем!

*(Җырлау өчен)*

Минем йөрәкне алдакчы димә,
Аерылыктан ул бераз суынса да.
Үз җаныңнан китеп буламыни,
Җаным синең җаныңа сыенганда.

Син – сөюем яши торган йортым.
Китсәм дә кайттым, юлны юлга ялгап.
Һәм һәрвакыт гаҗәп бәлзәм таптым,
Җанымны сафлар өчен синең алда.

Дәрт утына шактый буйсынсам да,
Языклардан каным кайнап бетсә дә,
Хыянәтче диеп мине уйлама син,
Намусым белән җаным садә.

Якты дөнья миңа нигә кирәк,
Синең хакка типмәгәндә йөрәк.

ТӨРЕКЧӘДӘН

*Назыйм Хикмәт*

## КӘРАМ* КЕБЕК

Һава кургаш кебек авыр.
Акырам,
акырам,
акырам,
акырамын...
Йөгерегез,
кургаш
эрет-
мәгә чакырамын...
Ул әйтәдер миңа:
– Син үзең дөрләп көл булырсың, әй!
Кәрам
кебек
яна-
яна...
«Газап
күп,
чара
юк»,
йөрәк-
ләрнең
колак-
лары
саңгырау...
Һава кургаш кебек авыр...
Һәм мин әйтәм аңа:
– Көл булырмын,
Кәрам
кебек
яна-
яна.
Мин янмасам,
син янмасаң,
без янмасак,
ничек
чыгар
караңгылыклар
яктылыкка...
Һава туфрак кебек җитешкән.
Һава туфрак кебек авыр.
Акырам,
акырам,
акырамын.
Ашыгыгыз,
кургаш эретергә
чакырамын...

## ЕГЕРМЕНЧЕ ГАСЫРГА

– Хәзергә йокыга талыйк,
йөз елдан соң уяныргбыз, сөеклем...

– Юк, гасыр үзе мине куркытмый,
мин качак түгелмен.
Гасырым мескен,
гасырым йөзкызарткыч,
Гасырым кыю,
бөек
һәм каһарман.
Дөньяга иртәрәк килдем дип уфтанмадым һичбер заман.
Мин егерменче йөзнеке,
шуның белән горурланам.
Миңа гасырымда
алдынгы сафта булу,
үзебезнең тарафта булу,
яңа бер дөнья өчен көрәшү дә җиткән...
– Йөз елдан соң, сөеклем...
– Юк, бернигә дә карамый, күпкә элгәрерәк.
Һәм үлгән, һәм туган,
һәм соңгы көннәрендә гүзәл киләчәге булган
    егерменче гасыр
(газапланып, яшь коеп таң тудыручы минем төнем),
синең күзләрең күк, Хәдичәм,
кояшлы булачактыр...

ПОЛЯКЧАДАН

*Юлиан Тувим*

* * *

Яшәү асылы ни бирсә дә барыбер түгелмени –
Җанныкынмы әллә тәннекенме?
Мине көтә бары бер генә мәңгелек...
Аз, бик аз, әйе бит?!

*Мария Ясножевская*

ДАВЫЛ

Күк кара ярсуда.
Гүләүләр. Болытлар.
Агачлар бәхетле!
Туйганчы шаулыйлар!

*Юзеф Озга-Михальский*

НИЧЕК МӨМКИН

Ничек мөмкин мәхәббәтнең
субстанциясен үзгәртү,
яфракның күләгәсенә генә,
диңгезнең шавына гына,
хатын-кызның уена гына гашыйк булу?

Ничек мөмкин болытларның
асылын белү –
бер тапкыр да

иреннәрең белән
тотмыйча яңгыр тамчысын?

## ЧЫЛТЫРАП БӘРЕЛӘ

Чылтырап бәрелә –
җил пыялага,
ай кара төнгә,
һава канатка,
табан ташка.
Чылтырап бәрелә –
елга ярга,
балдак тугрылыкка,
һәм иң авыры:
йөрәк – намуска...

## МИН КҮРДЕМ

Кем күргән
бокалны шәраб
исерткәнне,
ә яраны
калкан салганны?
Көннең
сыйдырмавын яктылыкны,
ә төннең
сыйдырмавын эңгерне?

## ТЕЛИМ

Розадай чәнчәсең –
чәнчелергә телим,
елгадай йотасың –
батарга телим,
ялкындай көйдерәсең –
көл булырга телим.
Син – төн, мин исә
күмер булырга телим.
Син – алмагач,
бәр миңа алмаң белән...

## ХЫЯНӘТ

Мин башканы очраттым,
бүләк иттем синең тавышыңны,
күзләреңнең төсен,
үзгәртеп ясадым йөзен,
үптем кашларыннан,
бу – син, дидем.
Үзем дә шуңа ышандым
һәм аны –
нәкъ менә синең кебекне
яраттым.

## ИСПАНЧАДАН

*Гарсиа Лорка*

## БӘЛӘКӘЙ МАДРИГАЛ

Синең бакчаңда –
дүрт анар агачы.
(Минем яңа йөрәгемне алчы.)

Бакчаңда синең –
дүрт кипарис агачы.
(Минем элекке йөрәгемне алчы.)

Кояш, Ай.
Аннары –
ни бакча, ни йөрәк...

## ТУГРЫЛЫКСЫЗ ХАТЫН

Әйе, мин елга буена
алып төшкән идем аны
сафтыр диеп, ә ул башка
берәүнең хатыны икән.

Сант-Яго бәйрәме иде,
үзеннән-үзе булды бу,
фонарьлар инде сүнгәчтен,
чикерткәләр җыр кабызгач.
Бер караңгы тыкрыкта
йоклаган түшләргә тидем.
Ак жасмин тәлгәшләредәй
алар миңа ачылдылар.
Ас итәге крахмалы
колакларны чыңга күмде –
шыгырдап торган ефәкне
әйтерсең ун кайчы кисә.
Агачлар үсеп киттеләр,
очларын күккә яшереп;
аръякның ерак офыгы
йөзләгән эт булып өрде.

*

Кара бөрлегән шыгында*,
елга буенда, камышта,
аның авыр толымнарын
юеш комга җәеп салдым.
Ефәк галстугымны салдым.
Һәм ул да күлмәген салды.
Мин – кәмәрне, револьверны.
Ул – барлык дүрт корсажын да.
Энҗедән дә, лаләдән дә,
пыялага тамып кипкән
көмеш ай балкышыннан да
нәфис иде шома тәне.
Шуып-таеп качкан итте,
аның ап-ак аяклары
ятьмәгә капкан балыктай
бәргәләнде, тыпырчынды
айның салкын нурларында.
Дөньядагы иң шәп юлдан
перламутр бия өстендә

төн буе җилдем, онытып
тезгенне һәм өзәңгене.
Ир-ат буларак сер итеп
саклыйм нәрсә әйткәннәрен.
Мөмкин хәтле тыйнаграк
булырга куша акылым.
Үбеп комга батырып бетереп,
аны шәһәргә кайтардым.
Ә төнбоек яфраклары
җил белән алыша калды.

Ә мин тиешен эшләдем.
Чын чегәнчә. Бүләк иттем
чигүләр салырга тартма,
зур тартма, җирән ефәктән,
ә гашыйк булып тормадым:
ул бит башканың хатыны,
үзе «мин саф» дигән булды,
елгага төшеп барганда.

## ДӨРЕС БУ

Сине минем кебек сөю –
Аһ, гаҗәп батырлык!

Хәзер миңа бөтен нәрсә –
Һава, йөрәк
Һәм сомбреро –
Сызланулар сәбәбе.

Кем алыр икән тасмамны
Һәм сагышым мамыгын,
Эрләгән җебем яулыклар
Булып тукылсын өчен.

Сине минем кебек сөю –
Аһ, гаҗәеп батырлык!

## КАЯ ЙӨГЕРӘСЕҢ СИН, ЕЛГА?

Кая йөгерәсең син, елга?

Йомшак улак буйлап йөгерәм
ерак диңгез ярларына таба.

Ә син, диңгез, кая?

Томанлы офыкта күзем.
Мин бер тыныч култык эзлим.

Тополь, син ни әйтерсең?

Берни дә әйтеп тормыйм.
Мин... калтырыйм!

*Мигель Отеро-Сильва*

* * *

Музыкада сугыш гөрелтесе,
шигъриятькә дары сөреме сеңгән,
руханилар вәгазендә ачу селтәсе,
галимнәр коточкыч формулалар тудыра.
Ни өчен дисез? Билгесез.

Ир-ат берсен-берсе сәбәпсез суя,
игенченең канын студент коя,
эшче мылтыгы шагыйрьгә төбәлә.
Ни өчен дисез? Билгесез.

Киленнәр килгән көннәрен оныткан,
сөяркәләр күзеннән ага толлар яше,
аналар почтальон тавышыннан куркып яши,
түтиләр бишекләрне чүплеккә ата,
ә балалар барысын да күреп тора,
барысын да ишетеп тора.
Ни өчен дисез? Билгесез.
Билгесез.

Җиңелүчеләр – Христослардай –
башларында канлы чүпрәк,
йөзләрендә куркуның теш эзләре,
иреннәрендә борынгы догалар дерелдәве,
каһкаһәле көлү
һәм кулга ялгыш килеп кергән барабан
аларның җиңелү хәбәрен җилгә тарата.
Ни өчен дисез? Билгесез.

Җиңүчеләр канәфер чәчәкләреннән, оркестрлардан,
җилфердәгән чуар яулыклардан
хасил боламыкны ера-ера,
урам бәйрәмнәренең канатларын каера-каера
атлыйлар.
Паладиннарның* йөрәкләрен,
калай медальләр астыннан табып алып,
Газазил теткәләп бетергән.
Аларны уңыш баткаклыгы йота бара.
Ни өчен дисез? Билгесез.

Очкычлар гөрелтесе,
көтелмәгән курку базында
бәргәләнгән безелдәү.
Күз карасын кислота булып ашаучы
Аңламау... Аңлашмау...
Ни өчен? Билгесез.
Билгесез...

* * *

Алтын кайчылар кайраучы,
булат хәнҗәр үткерләүче,
корыч кылычлар очлаучы
Олы Көн,
салкын төндә,
таң канаты булып җилпенеп,
син күк үзәгенә үк менеп җитәчәксең.
Син китәчәксең!
Һәм нәкъ шулай итә-итә

барлык нәрсә китә –
ә яшен ташы
алмаштырырмы соң
төннең мәңгелек кояшын?

Кояш сыман балкып Җирдә мәхәббәт яна,
сүнми яна.
Мәхәббәт җәннәт кошы сыман –
мәңге яңа!..

## ЧЕХ ТЕЛЕННӘН

*Витезслав Незвал*

### БИЛГЕ

Төн күбәләге, шигырьләрем кулъязмасына
Төшкәндә очып,
Яктылыкка очамы ул, караңгылыккамы?

### УФТАНУ

Төссез китаплар өчен
Урман кызганыч,
Кипкән ботаклар өчен
Кояш кызганыч,
Дәһшәтле диңгезләр өчен көймәләр кызганыч,
Начар адәмнәр өчен күз яшьләре кызганыч.

### ПЫЧАК ОЧЫНДА

Өзелеп төшәр дә тагын бер яфрак –
көз булыр инде бу.
Каты булып тоелыр алма тешкә –
картлык булыр бу.
Тагын бер гомергә картаям да –
мине беркем танымас.

## ВЕНГРЧАДАН

*Карой Чех*

### АЛТЫН-КӨМЕШ

Түбәнең буй-буй шиферы
зәңгәр күккә кадакланган кар көртләре кебек.
Сентябрь иртәсендә
үгез селәгәенең җепләре көмешләнә.
Әмма
аста әле җете балкый
карга миләшенең
куе тәлгәшләре.

Трибуна кебек кәпрәйгән үрдә
бер бала басып тора –
үзе Библиядәге җиде елдай ябай –

үлү-үчүне инкяр итеп
дөреслек балкышының,
көнбагышның алтын тажы сыман,
мәңгелек булуы хакында хәбәр бирә.

ЭЧТӘЛЕК

**Сәгать борганда**

Сайрау вакыты ...............................
Кырык берләр ................................
Сандугачлар тынган вакыт .........................
Уятса иртәләр ................................
Сискәнәсе килә ...............................
Бирешергә ярамый .............................
Фронтовиклар ...............................
Ветеран дәфтәрләр .............................
Җиңү байрагы ................................
Сезгә күчсен Җиңү җыры ..........................
Сагыныч ..................................
Тиле без... .................................
Берсе калсын иде .............................
Әнием искә төшә .............................
Дөньясына юк үпкә! .............................
Җиңелмәс куәт ...............................
Көзен агач утыртасың ...........................
Үле намус тере тәндә ............................
Җәлил кардәшләре .............................
Янә бер көнем яна .............................
Елларны санамыйча ............................
Кызыкмагыз ................................
Тамыр һәм чәчәк ..............................
«Нинди йолдыз булсам да мин...» ....................
Кытай теле .................................
Төпчек ...................................
Сандугач кунып кына ............................
Гаиләсенә җиһанның ............................
Тукай – үсмер аксакал ...........................
Тукай «Фауст»ны тыңлагач .........................
Ике обелиск ................................
Шәрык клубы ................................
«Сиңа хисләрнең җылысы...» ........................
Симметрия .................................
Үзебезгә кирәк догалар ..........................
Бер газәл ..................................
Россия ...................................
Син бит бу! .................................
Татар энциклопедиясенә .........................
«Сәләт» ..................................
Нәрсә йоттым? ...............................
Июль ....................................

Мин *(Триптих)* ................................
1. Харис ...............................
2. Мәгъсум ..............................
3. Ренат ...............................
Эш башкача ................................
Атлап барышым ...............................
Акыл керү .................................
Ычкындырмыйм ...............................
Рәхәт ирексезлек ..............................
Күз нурлары шигырь яза ..........................
Кем кушкан? ................................
Яз тойгысы .................................

«Хисләреңә буйсынмыйча...» .........................
Гомер сәгатьләрдән тормый .........................
Тез асты ...................................
Сүзсез шигырь ................................
Мактау турында ..............................
Бер туңам, бер янам ............................
Акылыңнан артка калгач ..........................
Көзгә яума .................................
«Әгәр сиңа туры килсә...» ..........................
«Кайчакларда мин янартау булам...» ...................
Әзер ....................................
Ачыйм мәллә? ................................
«Эчке җиһан кояшы да...» ..........................
Фанилык турында ..............................
Төн күзе ..................................
«Көз гөлләрдән башлана да...» ......................
Озынборын ................................
Ә сораулар көчле үлемнән .........................
Бәхетлеләр арасында ...........................
Хатыньда ..................................
Үлгән авылларга ..............................
«Мин, әлбәттә, бөек шагыйрь түгел...» ..................
Һәм мин әйтәм ...............................
Чикле мин .................................
«Тулышып килгән елга өстеннән...» ....................
Акыл газаплана ..............................
«Көннәр узган саен, юл кыскара...» ....................
«Иң алсу таң үтәчәк...» ...........................
Кире кайтмас идем .............................
Җитмеш яшьлек юлчы ............................
Нинди мәхәббәттер .............................
Орып бәрәбез ...............................
Тар ояда ..................................
Уй һәм кодрәт ................................
Без бар! ..................................
Ничә үрдер Шупашкарда ..........................
Илһам Шакиров ..............................
Камил Зыятдинов ..............................
Берәүнең юбилееннан соң .........................
Соңгы ут ..................................
Көнчелек турында ..............................
Урам ....................................
«Суладык та, су да алдык...» ........................
Сез күрсен дип... ..............................
Без әле һаман узаман ...........................
Композитор Ключарёв ...........................
Яндыргыч катнашма .............................
Казан – җилкән киргән кораб .......................
«Хатын-кызсыз өйләр – тәм-тозсыз...» ...................
Сәгать борганда ..............................
Кемдер чаба ................................
Мәйдан эзлим ................................
«Ижминсу» ..................................
Ике отыш ..................................
Сергей Есенин ................................
Очкын ...................................
Ике Такташ ................................

Казанда алтын көз .............................
Тулпарның хикмәте .............................
Намус яралу .................................
Рецепт ....................................
Алай карама миңа .............................
Яшерен почмак ...............................
Базмыш ...................................
Тар тамак ..................................
Ялагайлык этабы ..............................
Грюнвальд ..................................
Сәер легенда ................................
Парижда ...................................
Замокта ...................................
Истанбулда ................................
Карловы Вары ...............................
Яра – горурлык ...............................
Формула ..................................
«Гөнаһ» ..................................
Футбол ..................................
«Караңгы төн җиттисә...» ..........................
Тел һәм Хәтер ................................
Бусага ....................................
Кичәге көн тарих түгел ...........................
«Юмарт диеп мактатырга теләп...» ....................
Озын юл ...................................
Әнием хатирәсе ..............................
Сине күргәннән бирле ...........................
Казанда – Универсиада! .........................
Буа җыры ..................................

ӘЛМӘТ МОЗАИКАСЫ
Күп икәнен генә аңлыйм ..........................
Сөю Шагыйрәсе ..............................
Урсал-тау белән аңлашу ..........................
Келәм ....................................
Гамил Афзалларда кунакта .........................
Аларны яклыйсы килә ............................
Зәй белән Зөя ................................
Нефтьчеләргә ода .............................
Урамнан репортаж .............................
Тыелган сүз ................................

БАКЫЙ УРМАНЧЕ ТАШЛАРЫ
Урманче күзләре ..............................
Урманче кулы ................................
«Кол Гали» .................................
«Мәрҗани» ................................
«Тукай» ...................................
«Галимҗан Ибраһимов» ..........................
«Сөембикә» ................................
«Муса Җәлил» ................................
«Каюм Насыйри» ..............................
«Фатих Әмирхан» ..............................
«Габдулла Кариев» .............................
«Дәрдемәнд» .................................
«Шәехзадә Бабич» .............................
«Шамил Усманов» .............................

«Сагыш» ...................................
«Язгы моң» ..................................
Урманче тезләре ..............................

**Сонетлар**
Үзгәрешләр сонеты .............................
Чиксезлек сонеты ..............................
Реформалар сонеты ............................
Җавабы юк сорау сонеты .........................
Хата һәм игелек сонеты ..........................
Тулган Ай сонеты ..............................
Көн һәм төн тигезләшү сонеты .......................
Күләгә сонеты ................................
Плетцензее сонеты .............................
Маяксызлык сонеты .............................
Шикләнүләр сонеты ............................
Йомшак тәртип сонеты ..........................
Пушкин сере сонеты ............................
Аваз сонеты ................................
Ихласлык сонеты ..............................
Җәлил каны турында сонет ........................
Аның күзләре турында сонет ........................
Ак кәгазь сонеты ..............................
Казма зираты сонеты ............................
Кёнигсберг сонеты .............................
Аралык сонеты ...............................
Тиле сорау сонеты .............................
Дога турында сонет .............................
Яшь саны сонеты ..............................
Елау турында сонет .............................
Вак-төяклек сонеты .............................
Караңгылык сонеты .............................
Ялгыш тиңләү сонеты ............................
Аңларга тырышу сонеты ..........................

**Лирик пейзажлар**
Кодрәт тавышы ...............................
Тарих елгасы .................................
Ике сер ..................................
Күз буяр өчен ................................
Дулкынлана белмәгәч ...........................
Галәмнең күз карасы ............................
Кызлар су керә ...............................
Яшел өмет .................................
Түгәрәк күл .................................
Ходай эзендәге су ..............................
Тәҗрибә, тәҗрибәсезлек ..........................
Миләш һәм кырау ..............................
Балыкларга ялварыйк ............................
Салкын учаклар ...............................
Суга егылган тирәк .............................
Әлсерәгән көн ...............................
Күләгә кагылудан да... ...........................
Имән ботагында – карга ..........................
Кыргый алмагач ...............................
Кара көз карасы ..............................
Кем күзе? .................................

Кояш байый кызарып ............................
Зөя ярында тудым ..............................
Суның даһи көзгесе .............................
Әкиятемне сынамыйм ...........................
Күзләремнән кызганма ...........................
Шагыйрь көз ................................
Җырчы карлар ...............................
Ваемсыз җәй ................................
Кар баскан өй ................................
Шар эчендә учак ..............................
Туган җирем ................................
Соры көн ...................................
Таш җитә ...................................
Каләмдә кара туңды ............................
Боз астында җәй тавышы ..........................
Галәми хәтер ................................
Тукай бакчасында ..............................
Көмеш парча юрган ............................
Төсле карлар ................................
Оялчан инеш ................................
Шәрә таллар ................................
Әзерләнү ..................................
Әбиләр чуагы ................................
Күл буенда учак эзе .............................
Җиләс таң ..................................
Киселгән чәчәкләр .............................
Җил өрде ..................................
Салкын акылдай алтын ...........................
Зыкылы юллар ................................
Бәхетле мәшәкатьләр ............................

**Поэмалар**
Кадрия ...................................
Нарспи эзе ..................................

**Тәрҗемәләр**
РУСЧАДАН
*Гавриил Державин*
Хөкемдарларга һәм судьяларга ......................
Кошчыкка ..................................
Шук теләк ..................................
«Вакыт дәрьясы үзенең агымында...» ...................
Тончига ..................................
Давыл ...................................
Аллаһ ...................................
Лирага ...................................
Һәйкәл ...................................
Арфа ....................................
Мәхәббәт игъланы .............................
Аңлашу ...................................
Всемилага .................................

*Александр Пушкин*
Тилебаш ..................................
«Сөйдем сезне, бәлки, гыйшкым һаман...» ................
Баратынскига ................................

*Михаил Лермонтов*
Берьялгызым юлга чыгамын мин .....................

«Мин яшәргә телим! сагыш телим...» ...................
«Тыңла әле, без мәңгегә китсәк бергә...» .................

*Фёдор Тютчев*
«Сүзебезнең ни булып кире кайтасын...» .................
«Акыл белән Россияне булмый аңлап...» .................
«Очраттым да сезне – бар үткәннәр...» ..................
«Хыянәт итә башлагач...» ..........................
«Бар нәрсәмне алды җәзалаучы Аллаһ...» ................
Декабрь иртәсе ...............................
«Төтене дә Ватанның безгә хуш һәм татлы!..» ..............
«Уянмаган бу халыкның...» .........................

*Владимир Маяковский*
Ә сез булдыра алырсызмы? ........................
Мыскыллаулар ...............................
Яз ................................... ...
Айлы төн ..................................
Тыңлагызчы! ................................

*Сергей Есенин*
«Тәрәздә тулган Ай. Тәрәзне җил какты...» ................
«Гөлләр миңа «Хуш! Хуш!» диләр...» ....................
«Күл суларына чигелде таңның ал төсе...» ................

*Анна Ахматова*
«Аккош булып йөзде даным...» .......................
Исем ....................................
Ике юллы шигырь ..............................
Кара йөзек турында экият .........................

*Максим Горький*
«Хәрәкәтсез, гамьсез тыныч тынлык...» ..................
«... Кояш, Дөреслек – тәңгәл, ди...» ....................

*Игорь Северянин*
Хөкүмәткә поэза ...............................

*Марина Цветаева*
«Ике кояш сүнә – йа Ходаем, кичер, кызган!..» ..............
«Әйтерсең лә уң кул белән сул кул...» ...................

*Николай Заболоцкий*
Ялкауландырма җаныңны .........................

*Ярослав Смеляков*
Рус теле ..................................

*Арсений Тарковский*
«Төнлә вакыт акрын бара узып...» .....................

*Михаил Львов*
Сезнең күзләр ................................

*Станислав Куняев*
«Дәшмибез, эшлибез, җырлыйбыз...» ...................

*Эдуард Балашов*
«Бернәрсә дә аңламыйча...» ........................
«Барсы да бар: җеп һәм болын...» .....................

*Иван Переверзин*
«Вакыт сагындамы, әллә...» .........................
Каен ышыгында ...............................
«Яшәү булам, үлем булам...» ........................

«Кичә генә җан ышана иде...» ........................
«Ир һәм хатынмы без, сөяркәме?..» .....................
«Хуш! Мин китәм! Көнчелегем...» .......................
«Урман-таулар аръягында узды гомер...» .................
«Юк!» дигәнең иң суык суыктан ныклы...» .................
Кош .....................................
«Кара кургаш кебек кап-кара төн...» ...................
Мәрмәр ...................................

*Евгений Семичев*
«БҮРЕ КОЯШЫ» ЦИКЛЫННАН
«Тешләремне кысам – һәм дә ләм-мим...» ................
«Өерем тибәргән яралы бүре мин...» ....................
«Умрау сөягемә типте йөрәк...» .......................
«Туйдырды ла – өем почмакларын...» ....................
«Күз карашың тирән кое кебек...» .....................
«О, шәрыкнең зәһәр мәхәббәте...» ....................
«Үле бүре күзен күрсәм...» .........................
«Куркак ялагайлар тавыш-тынсыз...» ....................
«Әй, Россиям, империям минем!..» ....................
«Туган ил һавасы – яз һавасы...» ......................

*Равил Бохараев*
«Инеш тә чишмәләренә...» ..........................
«Көчлеме, юкмы көчәнү...» .........................
«Җанымны җибәрче ирекккә...» .......................
«Көненә йөз үлә алам...» ..........................
Яңарыш ...................................
Төнге тәрәзә .................................

*Наталья Астафьева*
«Үрентечек, яфракчыгым...» ........................

*Николай Рачков*
«СЛАВЯН КЫРЫНДА» ЦИКЛЫННАН
«Төтен аша утлар балкыймы ул...» .....................
«Коточкыч суешлардан соң...» .......................
Илья Муромец ................................
Святогор ...................................
Пересвет сөңгесе ..............................
Куликово кыры ................................
«Нинди генә урдалар кунакка...» .....................
«Яңа цезарь биредә...» ...........................
«Йа, җанны үзгәртеп кору...» ........................
«Сагышлы җиңүләр өчен...» ........................
Онытма ...................................
Сыктау ....................................

*Валерий Шамшурин*
«Барлык йолдыз сиңа балкыганда...» ....................
«Бәлки, һич тә кирәкмидер...» .......................
«Әллә нинди вакыт килде әле...» ......................
«Таныш моңнар колакка җитәләр...» ...................
«Тырышуым медаль өчен түгел...» .....................

*Вадим Кузнецов*
Сүз .....................................
Сал .....................................

Смоленск диварлары янында .......................
«Каенның яшел чәченнән...» ........................

КАЗАХЧАДАН
*Олжас Сөләйменов*
Куып тот! ..................................
«Поездлар соңгаралар...» .........................
Аргамак ..................................
«Думбырасын чиртә-чиртә...» .......................

УКРАИНЧАДАН
*Тарас Шевченко*
«Кәккүк күкелдәп җибәрде...» .......................

БЕЛОРУСЧАДАН
*Микола Метлицкий*
«Илһам килгән чакта мин – шагыйрьмен...» ...............
«Борыннан ук Русьта шулай булган...» ..................
«Ерагая көннәр афәт вакытыннан...» ...................
«Монда атом-төш хәтергә төшә...» ....................

*Рыгор Бородулин*
Хатын-кыз .................................

*Микола Чернявский*
«Йортка кеше кереп тулды...» .......................
«Шаулап үтте, койды чәчәген...» ......................

*Леонид Голубович*
«Шигырь, синең изге көч-куәтең...» ....................
«Төнге өй, караңгы дивар...» ........................

*Дмитрий Морозов*
«Аң-акыл тотылган заман...» ........................
Метаморфоза ...............................
«Бик күптәннән төшкә әни керми...» ....................

*Юрий Сапожков*
Рәхмәтем ..................................
«Парктагы сукмакларга...» .........................
Козгын ...................................

ЧУВАШЧАДАН
*Пётр Хузангай*
«Яралганмын учларымны кысып учлап...» .................
«Урманнарга кердем, менеп акбүз атка...» ...............

*Яков Ухсай*
Мине татарга саныйлар ..........................

*Геннадий Айги*
Кыш тамгаланган ..............................
Юл .....................................

*Порфирий Афанасьев*
Җиңү көне .................................
Дуслыкның нигезендә ............................
«Юк, булмады инде... Зинһар, кичер...» .................
Су эзлибез .................................

*Юрий Семендер*
Идел тавышы ................................

Карт солдатны күмү .............................
Әни ....................................
«Тынычлыгың тәрәзәдән очтымы...» ....................
Карлыгач балладасы ............................
Коралчы Калашниковка ..........................
«Елтыр-елтыр йолдыз-чылтыр...» ......................
Нужа ....................................
«Алло! Россиянең ике очы...» ........................
Өч сорау ...................................
Көлтә бәйлим ................................
ЮКӘ ЯФРАГЫНА ЯЗГАННАРДАН
«–Дустым, антология...» ..........................
«Татлы белән ачы...» .............................
«Кар киткәнне...» ..............................
«...Һәм үкәлчә...» ...............................
«Барыбер лә: базмы шунда, нәүрәпме...» ................

*Валери Тургай*
Яшәү һәм үлем ................................
Мин ....................................
Рәшит Ваһапов җыры ............................
Дусларга ...................................
«–Яратып туймадыңмы әле?..» .......................
Без – чувашлар... ..............................
«Әй, мунчачы! Кызган ташка эссе сал!..» .................
Минем җаным ................................
Шагыйрь ..................................
Каһарманнар ................................
Эңгер-меңгер. Өчәү ............................

*Раиса Сарби*
Ялвару ....................................

*Марина Карягина*
«Уйна, уйна, ачулы җил...» .........................

АВАРЧАДАН
*Расул Гамзатов*
Торналар ..................................

*Магомед Ахмедов*
«КӨЗ ЭЛЕГИЯЛӘРЕ» ЦИКЛЫННАН
«Хатирәләр күк киңлеге кебек...» .....................
«Шәраб һәм күз яше, сугышлар һәм ачлык...» ..............
«Көз чишенә – урман...» ..........................
«Тауга тау үрелгән, сыенган...» ......................
«Рус вечесы кебек шаулы ватан!..» ....................
«Ач, ялангач калып авыйм аусам...» ....................
«Дөньяны ник матәмгә урарга?..» .....................
«Чуерташ та түгел, кургаш та...» ......................
«Булачакның исем-аты булмый...» .....................
«Бакчаларның көзге җимешләре...» ....................

БАЛКАРЧАДАН
*Кайсын Кулиев*
«Мин яшәдем һәрбер кеше кебек...» ...................
«Кара еллар төннәрендә...» ........................
«Мәет белән хушлашканда кайчакларда...» ................

*Әхмәд Созаев*
Яз .................................... ...
«Мин шәһәргә...» ..............................
Бирү алудан хәерлерәк ..........................
Гаилә нигезе .................................
Башсыз ...................................
«Ай-һай дорфа сөйләштең син...» .....................
«Кылдай нәзек безнең шатлыклы чагыбыз...» ...............
Пакьләнү ...................................
Аллаһка ялвару ................................
Көчең җитәрме, Җирем? ..........................
Шигырьчыга .................................
Яңа буразнага яңгыр ява ..........................
Аксап кайтты тавышым ...........................

МАРИЧАДАН
*Дәүләт Исламов*
Көзге ромашка ...............................
«Соңгы яфраклар коела...» .........................
«Ашлык амбарлары тулды...» ........................

ЛАКЧАДАН
*Әфәнди Капиев*
«Арылды. Эзләрдә чал картлык...» .....................
«Хәнҗәрдәге язу кебек...» ..........................
«Үлеп гашыйк булганга...» .........................

ИНГЛИЗЧӘДӘН
*Уильям Шекспир*
109 нчы сонет ................................

ТӨРЕКЧӘДӘН
*Назыйм Хикмәт*
Кәрам кебек .................................
Егерменче гасырга .............................

ПОЛЯКЧАДАН
*Юлиан Тувим*
«Яшәү асылы ни бирсә дә барыбер түгелмени...» ............

*Мария Ясножевская*
Давыл ....................................

*Юзеф Озга-Михальский*
Ничек мөмкин ................................
Чылтырап бәрелә ..............................
Мин күрдем .................................
Телим ....................................
Хыянәт ...................................

ИСПАНЧАДАН
*Гарсиа Лорка*
Бәләкәй мадригал ..............................
Тугрылыксыз хатын .............................
Дөрес бу ...................................
Кая йөгерәсең син, елга? ..........................

*Мигель Отеро-Сильва*
«Музыкада сугыш гөрелтесе...» .......................
«Алтын кайчылар кайраучы...» ........................

ЧЕХ ТЕЛЕННӘН
*Витезслав Незвал*
Билге .....................................
Уфтану ...................................
Пычак очында ................................

ВЕНГРЧАДАН
*Карой Чех*
Алтын-көмеш ................................

Литературно-художественное издание

**Харис** Ренат
(**Харисов** Ренат Магсумович)

КОГДА УМОЛКАЮТ СОЛОВЬИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Харис** Ренат
(**Харисов** Ренат Мәгъсум улы)

САНДУГАЧЛАР ТЫНГАН ВАКЫТ

Мөхәррире *Л.Ә.Гыйззәтуллина*
Рәссамы *Ф.Ш.Хәсьянова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.М.Галимова, Г.Г.Гарифуллина*

Китапта *А.Ф.Хәсьянов фотолары файдаланылды.*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.04.2011.
Форматы 70x100 $^1/_{32}$. Шартлы басма табагы 21,45.
Тиражы 2000 д. Заказ Р-585.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.